КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№4
11 август
1995 ел

1995 елның июленнән
башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

5 ҮГЕНГЕ САНДА:

2 *Радик ФӘИЗОВ.* Бу дөньяда күрше белән күрше, хәтта туган белән туган тату яши алмый.

4 *Венера АЛИӘКБӘРОВА.* Мәдәният учагына... утын кирәк.

7 *ЗӨЛФӘТ.* Илне уйлыйм — тулган аңа юеш баз исе...

9 *Заһид МӘХМҮДИ.* Йөрәкне алыштырып була. Ә намусны?

16 *Динә ӘХМӘТОВА.* Хатын-кыз рәссам — бездә сирәк күренеш, талантлысы — бигрәк тә.

23 *Хәбибрахман ҺАДИЕВ.* Гимназия нигезенә үлән үскән...



ЯҢА ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ БАРА

Далаларда үскән уйлы күра
әверелгән безнең „Үел"ларга...

МИН ƏЙТТЕМ

Радик ФƏИЗОВ

Явызлык каян килə?

Совет чоры кинофильмнары, əлбəттə, бар иде аларның төрлесе. Əмма бар иде без бик яратып караганнары, чын сəнгать əсəре буларак, əле дə хəтердə саклана торганнары. Тик аларның барысына да хас бер «кимчелеклəре» булган икəн: əлеге фильмнар безгə бу тормыштагы матурлыкны һəм яхшылыкны, кешелеклелек, шəфкатьлелекне генə чагылдырганнар. Ə менə кешедəге явызлыкны, мəкер, ялган, хыянəт, имансызлык, комсызлык кебек нəрсəлəрне күрсəтмəгəн алар безгə. Өйрəтмəгəн, өндəмəгəн алар безне явызлыкка! Кешедəге иң тискəре, хайвани, түбəн сыйфатлардан алар безне саклаган, моның ишə гайрə табигыйлектəн югары булырга, чирканырга чакырган.

Ə соң хəзер? Əнə, биргəненə шөкер!.. Өйгə кайтып, телевизорны тоташтырып җибəрдең исə анда атыш, үтереш, көчлəү, хыянəт — җир күтəрə алмаслык явызлыклар. Əгəр дə сез адым саен хыянəткə, тешлəрне ыржайтып, күзлəрне акайтып əрлəшүгə, тагын əллə никадəр хəсислеклəргə өйрəнергə телисез икəн, рəхим итегез! Инде еллар буе барган Америка телесериалы «Санта-Барбара»ны гына карагыз. Анда барысы да бар, һəммəсе тулып ташыган. Сез бəрни эшлəмичə байлык туплау, кешелəрне физик һəм рухи яктан юк итү, заложниклар алу һəм тагын хисапсыз шундый явызлыкларга ия булырга телисез икəн, əнə, Италиядəн кергəн фильмнарны гына карагыз. Тагын кайсы чит илнеке кирəк? Хəтта, хəзер бик сирəк чыксалар да, үзебезнекелəр дə кимен куймый инде. Шул ук тоташ явызлык, тоташ секс. Əле күптəн түгел генə без кайчандыр бик ихтирам иткəн Аркадий Райкинның улы, шулай ук билгеле артист Константин Райкин телевизор экранында шыр ялангач калып, гаурəтен юри күрсəтеп, шамакайдай чабып йөрде. Аның өчен без оялдык.

Əлбəттə, тормышның төрле яклары булуын, матурлык, инсафлылык белəн янəшəдə төрле имансызлыклар, явызлык кебек нəрсəлəр яшəп ятканын без элек тə белə идек. Беркем дə аны аңламаслык тинтəк түгел бит əле. Əмма үз заманында безгə бу «нигъмəтлəрне» беркем дə таратмый иде. Ə хəзер, əнə, пропагандалыйлар һəм ачыктан-ачык. Белəсезме, һəртөрле сөйлəү, хикəялəү, экранда күрсəтүлəр кызыктырып өндəүгə, чакыруга өйлəнə бит ул. Нəкъ бер йогышлы авыру шикелле. Телевизорда күрсəтелгəн əлеге имансызлыклар экранда гына торып калсалар, хуп яхшы иде дə. Алай түгел шул. Бу бозыклыклар һич кичекми җəмгыятькə йога. Шəхсəн менə миңа, сиңа иярə. Аларның балаларга, яшьлəргə нинди көчле тəэсир иткəнен, нинди тискəре йогынты ясаганын əйтергə дə куркыныч.

Җанашларым, нəтиҗəсе күз алдында бит! Соңгы ике-өч ел эчендə генə дə безнең җəмгыятьтəге, кешелəр арасындагы үзара мөнəсəбəт — нинди кискен үзгəрде. Кызганычка каршы, дөү адымнар белəн начар якка. Инде дəлиллəр китереп торуның да кирəге юк. Моны һəркем үз тормышында көндəлек рəвештə татый: җəмəгать урыннарында, урамда, кибетлəрдə, транспортта... Көн дə очрашып торабыз, Аллаһынның биргəненə шөкер.

Хəзер əйтəсе килгəн төп фикергə якынлашыйк əле. Минемчə, монда пропаганда, кинофильмнар, сəясəт кенə дə гаепле түгел шикелле. Əйдəгез, бер мəлгə бик тə беркатлы, наив кешелəр булып карыйк əле. Акыл иялəре əйтүенчə, кайчак нəкъ менə беркатлы наив фикер хакыйкатьне табуда ярдəм итə. Шулай итеп беркатлы сораулар бирик. Каян килə бу адəм баласына явызлыклар — үзара дошманлык хисе, үзара ачу саклау. Ник əле бу дөньяда күрше белəн күрше, хəтта туган белəн туган үзара килешеп, тату гына яши алмыйлар? Уйлап карасаң, бу бит еракка китə. Иллəр белəн иллəр арасында үзара канлы сугышларның, халыкны күплəп юк итүлəрнең башлангычы да шул гомуми дошманлык хисеннəн түгел микəн əле? Нигə бу кешелəр, хəтта инде үзлəрен иң югары гуманистлар дип санаган коммунистлар да, үтерү коралларын күплəп җитештерделəр, хəтта яшерен рəвештə агулы матдəлəр дə ясап ятканнар? Ник əле, əйтик, адəм баласы бу дөньяда үзара дошманлык, үтерешлəр, сугыш-кырышларны һəм башка шундый коточкыч гамəллəрне бөтенлəй дə бəлмичə генə яши алмый?

Бу беркатлы сорауларга, минемчə, җавап бер генə: Кешенең рухи дəрəҗəсе, рухи үсеше бик түбəн. Нəкъ менə шушы сəбəп аерым гаилəлəрдəн алып бөтен-бөтен җəмгыятьлəргə кадəр төрле тетрəнүлəргə китерə. Инде төзелеп килгəн, хезмəт иялəренə никадəрле хокуклар биргəн, күпмедер дəрəҗəдə аларны наданлыктан, изелүдəн тартып алган социализм бинасының дөбердəп җимерелеп төшүенə нəрсə сəбəп булды дип уйлыйсыз? Һаман да шул бер нəрсə: Кеше рухының җитлекмəгəн, түбəн булуы. Иң әүвəле барысы да диярлек югары белемле, җитəкче түрəлəр нəфескə, бернинди чиклəрне белмəүгə, беркем белəн хисаплашмауга бирелделəр, үз сүзлəре белəн əйтсəк, рухи яктан череп таркалдылар. Аларга, берсеннəн икенчесе уздырып, вак түрəлəр иярде. Аннан инде бу шаукым халык диңгезенə таралды... Хəзер инде, əнə, шул гавамның нилəр кылганын үзегез күреп торасыз. Кайберəүлəре хəтта «коммунизм — кешелекнең үсеш тарихында иң начар, иң түбəн форма», дип, əкият сатуларга кадəр барып җиттелəр. Исегезгə төшерим, кичəге коммунистлар болар... Менə ул — рухның җитлекмəгəн, түбəн булуы!

Бəлки төрле явызлыкларны, имансызлыкларны тормыш сəрешеннəн, аның кануннарыннан килə, дип аңлатырга омтылучылар табылыр? Минемчə, бу алай түгел. Явызлык — кешедə патологик күренеш, ул аның табигатенə салынган. Мондый сыйфат гасырлар буена килгəн һəм алга таба да дəвам итəчəк. Бу фикер минеке генə түгел, ул матбугатта, зур галимнəр авызыннан да ишетелгəли. Урта гасырлардан бирле генə дə инде фəн һəм техника никадəр алга китте, шуның белəн кеше матди яктан ничек баеды, аның мөмкинлеклəре никадəрле артты бит инде. Болар ярдəм итсə, кешелəр инде фəрештəлəр булырга тиеш иде. Ə чынлыкта ничек? Рухи яктан күтəрелү хакында сүз алып барырга җирлек кайда?! Хəзерге көндə исə рухиятнең гомумəн түбəн төгəрəве турында фикерлəр ишетелə. Хəтта Галəмнəн килгəннəрнең дə, кешелекнең шул начар холкыннан шүрлəп, безнең белəн бəйлəнешкə керүдəн тыелып торулары турында гөман кылулар бар. Кем белə тагын, бик ихтимал.

Хəзер матбугатта Җир шарындагы кешелекнең, ягъни безнең цивилизациянең бетү куркынычы хакында да хəбəрлəр күренгəли. Аллаһым сакласын, моның бит, чыннан да, булу ихтималы бардыр. Бəлки ул җирдəге хисапсыз имансызлыклар өчен Тəңре тарафыннан җибəрелгəн җəза булыр.

Əмма без алай юрамыйк əле. Җир шарында кешелек бетмəс, Аллаһ боерса! Зур бəла-казалар, һəлакəтлəр дə булырга мөмкин анысы. Алары аның Җир шарында моңарчы да булып торган.

Болардан чыгып, соңгы сорау: адəм баласы үзендəге бу явызлык, хəсислеклəрне бер җиңеп чыга алырмы? Һəртөрле һəлакəт һəм тетрəнүлəрдəн соң Кешелек җəмгыяте бөтенлəй икенче, яңа юл белəн китеп бармасмы? Үзендəге дошманлык хисеннəн тəмам арынып, бернинди хыянəтсез, үтерешү һəм сугышларсыз юл белəн. Əй Аллаһым, нинди яхшы ничек һəйбəт булыр иде бу!

Җəмəгать, ə бит моның, чыннан да, булуы ихтимал! Безгə дип əйтмим инде; килəчəк буыннарга...

ЛИТЕРАТУРНАЯ ГАЗЕТА

Казан. Бауман урамы, 19
«Мəдəни җомга» атналык газетасы редакциясе, Зиннур МАНСУРОВка

Кадерле каләмдəшлəр! Яңа мəдəни басманың тууы безне шатландыра. Əлеге вакыйга уңаеннан җөмһүриятегез язучыларын, иҗат əһеллəрен ихлас котлыйбыз. Татар əдəбиятын үстерүдə, Россия Федерациясенең күпмиллəтле мəдəнияте белəн бəйланышларны ныгытуда сезгə уңышлар телибез. Өйлəребез имин булып, бер-беребез белəн йөрешеп, дустанə яшик.

«Литературная газета»ның баш мөхəррире А.УДАЛЬЦОВ.

ГАЗЕТА ҺƏМ УКУЧЫ

Дəрəҗəсен саклагыз

«Мəдəни җомга» газетасын алып укыгач, сезгə чын рəхмəтемне җиткерəсем килде. Газетагыз бик тирəн эчтəлекле һəм кызыклы. Алга таба да аның дəрəҗəсен төшермəгез. Сезгə уңышлар юлдаш булсын.

Имаметдин ГƏРƏЕВ,
Россия Федерациясенең атказанган социаль тəэминат хезмəткəре, Югары Утəр балалар йорты директоры. Саба районы.

Зур вазифа йөклəнə

Ниһаять, яңа басма пəйда булды. Татарны татарга «əверелдерү» өчен бу газетага бик зур вазифа йөклəнə.

Дөрес, мин бары тик пенсионер укучы гына. Тик шулай да əдəбият белəн мəдəният минем өчен дə иҗат итəлə ич. Шулай булгач, минем фикер дə читтə калмаска тиеш.

Татарны төрки халыклар белəн якынлаштыру өчен безгə кириллицадан тизрəк арынырга кирəк. Беренче чиратка, үзебезнең яңалифегə безгə кайту да ярап куяр иде. Яңа басмага моны исте тотарга, тормышка ашыруда үз хезмəтен куярга кирəк булачак.

Рашат СƏЛƏХОВ,
пенсионер. Зəй шəһəре.

ҖИДЕГӘН вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар 5 6 7 1 2 3 4

Казанда «Мөстәкыйльлек көне» ничек уздырылачак?

Татарстанның мөстәкыйльлеге турындагы Декларация кабул ителүнең 5 еллыгы уңаеннан үткәрелә торган халык җыены 30 август көнне Ирек мәйданында иртәнге сәгать 10 да башланачак. Анда Татарстан шәһәр һәм районнары, республикадан читтәге татар милли оешмалары вәкилләре катнашачак; күренекле сәясәтчеләр, әдипләр, милли хәрәкәт җитәкчеләре, сәнгать әһелләре чыгыш ясаячак. Шуннан соң митингта катнашучылар Беренче Май мәйданына юл алачаклар. Көндезге сәгать 12 дә митинг Казан Кремле янында дәвам итәчәк. Анда хакимият вәкилләре, парламент әгъзалары чыгыш ясарлар дип көтелә.

«Мөстәкыйльлек көне» алдыннан Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты Татарстан мөстәкыйльлегенең биш еллыгына багышланган фәнни-гамәли конференция үткәрүне күздә тота.

«Комсомольская правда» газетасының 8 август санында басылган «Александр Лукашенко Россия Президенты булырга тели» исемле язманы укыган милләттәшләребез, мөгаен, бер мәлгә өнсез калганнардыр. Ник дигәндә, Беларусь Президенты үз илен Рәсәйгә кушып, чыннан да империянең яңа хакиме булырга хыялланa икән бит, җәмәгать. Хәер, аның газетадагы сурәте дә шуны җөплап тора түгелме соң? Президент дигәнебез заманында Явыз Иван тарафыннан урланган «Казан бүреге»н киеп алырга да өлгергән лабаса! Ә бит өлеге «баш савыты», бик беләсегез килсә, 1552 елның 2 октябренә кадәр Казан патшасының таҗы булган. Иван Дүртенче исә аны Россия империясенең көч-куәт һәм явызлык тамгасына әйләндергән.

Бүген шушы «бүрек»не урысларның якын тугане, белорус дустыбыз А.Лукашенко үзенең башына үлчәп маташа. Кем әйтмешли, бүреге булгач, башы да табыла шул, шайтан алгыры.

Казан — Мамадыш — Салагыш... Пекин

«КамАЗ-Мастер» командасының «Париж — Мәскәү — Улан-Батыр — Пекин» халыкара автомарафонында катнашу өчен Франциягә китүен хәбәр иткән идек инде. Бу автомарафон Татарстан җире аша да үтәчәк. Бүген, 11 августта, сәгать ун белән унике арасында Казан — Чаллы юлының Мамадышка хәтле булган өлешенә якында гына әлеге автомарафонда катнашучы машиналар бәйгесен тамаша кылырга мөмкин булачак. Ә аңарчы машиналар шул ук көнне иртән Казанның 1 Май мәйданына — Кремль янына киләчәкләр. Автоспортчыларны Татарстан җитәкчелеге кабул итәчәк.

Татар җыры Аурупада яңгырый

Татар музыкасы әсәрләре, республика чикләрен үтеп, Аурупа музыка сөючеләренең дә колагына барып ирешә. Узган ел Швеция радиосы татар композиторлары һәм халык музыкасы турында инглиз һәм француз телләрендә 5 тапшыру бирде. Бу — сөенечле хәл. Тапшыруларны әзерләүче һәм оештыручы — Швеция радиосы хезмәткәре Матс Эйнарссон. Ул быел да игелекле эшен дәвам иттерергә булган һәм, шул максаттан, яңадан Татарстанга килеп чыккан. Бу юлы, үз халкын татар халык музыкасы белән тулырак таныштыру ниятендә, ул 7 тапшырудан торган яңа цикл әзерләргә җыена. Үзе белән бергә Финляндиядә туып-үскән татар зыялысы Төркәр Соукканны да алып килгән. Ә Төркәр әфәндене Казанда инде дуслары да бар икән: моннан дүрт ел элек Ислам җәмгыяте чакыруы буенча Рабит Батулла Финляндиядә татар халкы тарихы турында лекцияләр укыганда ул аның белән дуслашып калган.

Швеция кунаклары Казанга Татарстан Язучылар берлеге чакыруы буенча килгәннәр. Бу юлы алар нигездә керәшен татарлары фольклоры белән һәм Татарстанда яшәүче башка халыкларның да музыкаль мирасы белән кызыксыналар. Чаллыда һәм шул тирәдәге керәшен авылларында йөреп, алар керәшен җырларын, йола-уеннарын, җырлы бию, фольклор әсәрләрен язып алганнар. Чаллы төбәгендә яшәүче татарларның кунакчыллыгын яратып кайтканнар. Башкалага кайткач алар, консерваториядә музыкантлар һәм музыка сөючеләр, шулай ук профессор М.Нигъмәтҗанов белән очраштылар.

Чит ил кунакларының татар музыкасына тартылуы куандыра: мәдәни офыкларыбызның киңәя баруы — яхшы фал. Һәрхәлдә, Швеция журналисты Матс Эйнарссон Татарстанны, Казанны, республиканың ачык йөзле, кунакчыл кешеләрен яратып, үз иленә сәфәр тотты.

ҖОМГАДАН — ҖОМГАГА

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Кремльдә Америка галиме, Халыкара мөнәсәбәтләр һәм фон үзәге директоры, Гарвард университетының демократик институтларны ныгыту программасы җитәкчесе, АКШ оборона министры киңәшчесе Грэм Аллисонны кабул итте.

Татарстан Премьер-министры урынбасары Равил Моратов Әлмәттә «Татнефть» акционерлык җәмгыяте җитәкчеләре, көньяк һәм көньяк-көнчыгыш районнар хакимият башлыклары белән көзге кыр эшләре өчен ашлама һәм үсемлекләрне саклау препаратлары кайтару мәсьәләләренә багышланган киңәшмә үткәрде.

Югары Ослан районының Печищи авылында яңартылган туган як музее (Янка Купала дәүләт музееның элеккә филиалы) ачылды.

Рәсәй Дәүләт Думасының «Тотрыклылык» депутат төркеме, шул исәптән депутатлар Константин Панферов һәм Азрет Акбаев Казанда, Мәдәният министрлыгында булып киттеләр.

Хөкүмәт карары белән Минзаһит Исламгир улы Җиһаншин Татарстан Республикасының Гадәттән тыш хәлләр буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары итеп билгеләнде. Ул элек Министрлар Кабинетының административ-хокук саклау органнары бүлегенең баш референты булып эшләгән.

Казанның «Ак барс» хоккейчылары Америка, Швеция һәм Финляндия командалары арасында үткәрелә торган турнирда катнашу өчен Суоми иленә китте.

«Тигез хокуклылык һәм законлылык» блогы Рәсәй Дәүләт Думасына декабрьдә булачак сайлауларда депутатлыкка кандидатлар итеп Иван Грачев белән Валентин Михайловны күрсәтте.

Мәскәүдә Премьер-министр Фәрит Мөхәммәтшин һәм «Газпром» акционерлык җәмгыяте идарәсе рәисе Рэм Вяхирев Татарстан район-авылларына газ кертүне тәгәлләүне максат итеп куйган килешүгә кул куйдылар.

«Татар-информ» агентлыгы «Труд» Урта Иделдә» дигән реклама-мәгълүмат кушымтасы әзерләп чыгара башлады.

Казанда А.Туполев исемендәге техник университет нәшриятында «Право и политика» исемле журналның беренче саны дөнья күрде.

Беренче яртыеллыкта Татарстанның салым полициясе хезмәткәрләре республика бюджетына 105 миллиард 300 миллион сум акча кайтарып бирделәр.

Азнакайдагы Актүбә поселогының «Акчишмә» лагеренда районнардагы барлык гарип балалар катнашында бәйрәм булып үтте.

Фарфор — агачта үсми, тик... аның серен кем ачар?..

Саксонияне без тарих китапларыннан укып беләбез: Аурупада беренче булып фарфор ясау серен ачкан һәм бу сәнгә бер генә дәүләткә дә, бер генә илгә дә ачарга теләмәгән төбәк.

Ә менә хәзер Саксония эшмәкәрләре, бу илнең дәүләт эшлеклеләре безгә — Татарстанга килә, безнең белән сәүдә элемтәләре турында килешүләр төзи.

2-4 августта бездә Түбән Саксония җиренең Премьер-министры Г.Шредер килеп китте. Ул җөмһүриятебез Президенты М.Шәймиев һәм Премьер-министр Ф.Мөхәммәтшин белән сөйләште, Татарстанның хәл-халәте, табигате белән танышты. Кунагыбыз Казан дәүләт университетында булды, Моторлар төзү берләшмәсе, «КАМАЗ» акционерлык җәмгыяте хезмәт коллективы белән очрашты. Г.Шредерның бу сәяхәте нәтиҗәсендә, чит телләрдә коммюнике дип аталган килешүдә ике як та фәнни, мәдәни һәм дә икътисади, сәүдә элемтәләре белән кызыксынуы ачыкланды. Ике дәүләтнең дә башкаласында хезмәттәшлек вәкилләкләре булдырылачак.

Килешүләр, шулай ук, «ЭКСПО-2000» күргәзмәсендә — Ганновер шәһәрендә — киләсе елда Татарстанның халыкара ярминкәдә катнашуын да билгеләде.

Ә инде фарфорның төп серен кем ачар, анысы — Саксония белән Татарстан эше!

Зөлфирә ТУГАНОВА.

Күренекле драматург министрда кунакта

Татарстан Мәдәният министры Марсель Таишев Мәскәү кунагы — күренекле драматург Виктор Розов белән очрашты. Анда сәнгать һәм мәдәният турында сөйләшү булды. Министр бу өлкәдәге мәсьәләләрне хәл итүнең барышы, татар, Татарстан халыкларының мәдәниятен торгызу һәм үстерү, бу эштә дәүләтнең ярдәм итүе турында сөйләде.

В.Розов бу авыр заманда да Татарстан сәнгатенең үсешенә, театр һәм башка мәдәният учакларының сүнмәвенә, министрлыкның уку йортларын, мәдәният оешмаларын нигездә саклап кала алуына канәгать булуын белдерде.

Сәнгать җанлы эшмәкәрләр

Дөнья сәнгатендә шундый тәртип тә бар: автор үзенең әсәрен башкаручыларны шәхсән үзе билгели. Америка драматургы А.-Р.Герни да «Мәхәббәт хатлары» исемле пьесасын (Россиядә) сәхнәләштерү хокукын фәкать Г.Товстоногов исемендәге С.-Петербург академия зур драма театры актерлары — Андрей Толубеевка һәм Екатерина Марусякка гына биргән. Яшьтән үк бер-берсен яратып, изге хисләрен гомер буена күңелләрендә йөртеп тә чәчләрен чәчкә бәйли алмаган гашыйклар турындагы бу әсәр буенча куелган спектакльне казанлылар да карый алдылар. Тамашалар «Казан» милли-мәдәни үзәге сәхнәсендә булды. Спектакльләр С.-Петербургтагы «Оптика» берләшмәсенең Казандагы «Невская оптика» салонының матди булышлыгы белән үтте. Их, безнең дә шундый сәнгать җанлы эшмәкәрләребез булса, татар артистлары да ерак төбәкләргә гастрольләргә йөрерләр иде.

«Туган тел» галимнәрне җыя

Татарстан Республикасының мостәкыйльлек турында Декларация кабул итүенә тиздән биш ел тула. Шул уңайдан Мәскәүдәге «Туган тел» җәмгыяте (рәисе Рифкать Галимов) Татарстан Фәннәр академиясе академигы Әбрар Кәримуллинны очрашуга чакырды. Анда галим-якташыбыз Татарстан алып барган сәясәт һәм аның бүгенге вазгыяте турында сөйләде. Әбрар Кәримуллин һәм Мәскәүдә яшәүче татар зыялылары: Мәскәү археография институты профессоры Әгъдәс Борһанов, Россия Фәннәр академиясенең хокук һәм дәүләт фәнни-тикшеренү институты профессоры, Дәүләт Думасында хокук мәсьәләләре буенча киңәшче Рәис Тузмөхәммәтов очрашуда катнашучыларның бик күп сорауларына җавап бирделәр.

Академиклар авылда киңәшә

Иртәгә, 12 августта, Кукмара районының Вахит авылында Халыкара информатика академиясенең күчмә утырышы була. Ул академия оешуның ике еллыгына һәм Берләшкән Милләтләр Оешмасының 50 еллыгына багышлана.

Вахит авылында Традицион булмаган медицина үзәге урнашкан. Аның җитәкчесе — Халыкара информатика академиясе академигы, Халыкара «Планетаны яңарту» ассоциациясе вице-президенты Рафикъ Миңлебай улы Миңнекәев.

Утырыш көндезге 11 сәгатьтә башлана.

Кунаклар өчен иртәнге һәм кичке сабан туе оештырыла.

Киңәшле эш таркалмас

Мәскәүдә Мөселман диния нәзарәтләре рәсми җитәкчеләренең киңәшмәсе булып үтте. Рәсәйнең Үзәк Европа төбәге мөселманнары идарәсе бинасында үткән бу җыелышта уртак белдерү кабул ителде. Анда: «Ислам динен тагын да ныгыту, Рәсәйнең барлык мөселман оешмаларының эшендә бердәмлек булдыру өчен, киңәшмәдә катнашучылар, һәрбарча дини оешмаларның үзара мәнфәгатьләрен искә алып, барлык юнәлешләрдә дә килешеп эш алып барырга вәгъдә кылдылар», диелә. Белдерүгә Рәсәй Үзәк Европа төбәге мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе мөфти Равил Гайнетдин һәм Рәсәй мөселманнарының Югары координацион үзәге рәисе, Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Габдулла Галиулла имза салган.

МӘДӘНИЯТ УЧАГЫНА... УТЫН КИРӘК

Татарстан Мәдәният министрлыгы коллегиясе утырышы булды. Анда мәдәният оешмаларының көзге-кышкы шартларда эшләүгә әзерлекнең барышы, мәдәният-сәнгать корылмаларын төзү һәм төзекләндерү мәсьәләләре каралды. Шул уңайдан Арча, Саба, Балык Бистәсе, Теләче һәм Чирмешән районнары мәдәният бүлекләре мөдирләренең хисабы тыңланды.

Әлеге төбәкләрдә зур оештыру эшләре башкарылган: кышкы чорга әзерлек, янгыннан саклану мәсьәләләре мәдәният хезмәткәрләренең семинарларында һәм киңәшмәләрендә тикшерелгән, башкарыласы эшләр планы төзелгән, һәртөрле төзекләндерү үткәрелергә тиешле мәдәният корылмалары күзәтү астына алынган. Бигрәк тә Саба районында эшләр әйбәт бара. Биредә үзәк һәм балалар китапханәләре, район музее, балалар сәнгать мәктәбе яңа биначисленә күчкән. Авылларда яңа клублар төзелә, җидесендә баштанаяк төзекләндерү үткәрелә.

Арча һәм Балык Бистәсе районнарында да мәдәнияткә мөнәсәбәтнең яхшы булуы күп кенә эшләр башкарырга мөмкинлек биргән.

Шул ук вакытта, дип билгеләп үтте коллегия, республика буенча тулаем алганда мәдәният оешмаларын көзге-кышкы чорга әзерләү бик акрын бара. Күп районнарда капиталь ремонт үткәрү өчен акча бирелми. Авыл җирләрендә мәдәният учакларын ягулык белән тәэмин итү бик начар.

Мәдәният корылмаларын төзү һәм төзекләндерү темпы да түбән. 1994 елда, акча булмаганлыктан, шәһәр һәм авыллардагы төзелеш туктатылып торган. Авылларда мәдәният хезмәткәрләре өчен торак төзелеше дә шундый язмышка дучар булды.

Быел, коллегия билгеләп үткәнчә, мәдәният корылмаларын төзү буенча дәүләт программасы нигезендә бирелгән акча максатчанрак кулланыла. В.Качалов исемендәге Рус зур драма театры, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, хореография училищесы, Татар яшьләр театры, сәнгать музееның фонд саклагычы бинарлары төзекләндерелә. Болардан кала, Казан яшьләр театрын, Берләштерелгән музейны төзекләндерү эшләре, Минзәлә драма театрын ремонтлау республика бюджетларыннан финанслана. Быел авыл җирләрендә мәдәният хезмәткәрләре өчен 1200 кв. м. торак файдалануга тапшырылыр дип көтелә.

Коллегия авыл мәдәният оешмаларының көзге-кышкы чорга әзерлеген тикшерү буенча рейдларны яңадан башлап җибәрергә һәм мәдәният бүлекләре мөдирләренә, идарә җитәкчеләренә мәдәният объектларын ремонтлау, төзү һәм аларга ягулык әзерләүдә ныклы контроль урнаштырырга кирәклегенә басым ясады.

Венера АЛИӘКБӘРОВА.

Милли рух читтә ничек яши?

Финляндиядәге «Ислам» татар җәмгыятенең чакыруы буенча академик Миркасыйм Госманов Хельсинкига китте.

Анда ул, нигездә яшьләрдән торган Финляндия татар җәмәгатьчелегенә татар тарихы һәм халыкның язма мәдәни мирасы буенча атна-ун көн дәвамында дәресләр уздырачак. Шуңа да игътибар итәргә кирәк: Финляндиядәге татар җәмәгатьчелеге яшьләрне милли рухта тәрбияләүгә җитди игътибар бирә. Анда ел саен диярлек мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп яшендәге балаларны махсус җыеп, аларга туган тел һәм дин буенча дәресләр бирү традициягә әйләнде. Шулай ук олырак яшьтәгеләргә дә тарих, туган тел буенча даими рәвештә мәгълүмат бирелә. Балалар һәм яшьләрнең мондый җәйге укулары уздырылганда башка илләрдән дә, мәсәлән, АКШтан, кунаклар чакырыла.

Башка төбәкләрдәге милләттәшләребез дә, Финляндиядәге татарлардан үрнәк алып, шушындый изге гамәлне гадәткә кертсәләр, бик күркәм, файдалы эш булыр иде.

Ике флаг та җилфердәде

Магнитогорск шәһәрендә Сабан туе бәйрәме елдан-ел матуррак, эчтәлекле һәм кызыклырак була бара, кешеләрне елдан-ел күбрәк җыя.

Быел да ул шаулап үтте. Анда Татарстан һәм Башкортстан флаглары җилфердәде, ике җөмһүриятнең дә гербы ялтырап торды. Мәчетнең икенче имам хатибы Өлфәт хәзрәт Шакир фатиха догасы укыды.

Монда Сабан туеның бөтен уеннары уйналды. Шәһәрнең төрле ансамбльләре, башка төбәкләрдән килгән бию, җыр, гармун осталары чыгыш ясады. Аннары теләгән кешеләр конкурска чакырылды. Алары да бик күп иде, димәк, халкыбызның талант чишмәсе саекмый.

Конкурста бүләкләр мул булды, катнашканнарның берсе дә нәүмиз булып калмады. Нуретдиновларның гаилә ансамблен аерата җылы кабул иттеләр. Алар «Җизнәкәй» дигән шаян җырны башкарып, беренче урынны алдылар. Гармунда уйнаучылар арасында Гали ага Юнысовны уздыручы булмады. Кечкенә Дилә татар җырларын бик матур итеп башкарып, шулай ук беренче урынга чыкты.

Көрәшчеләр көрәште, гер күтәрүчеләр гер күтәрде. Кыскасы, быелгы Сабан туебыз да күңелгә бик күп кызыклы мизгелләр, көлкеләр, кызыклы вакыйгалар турында истәлекләр салып калдырды.

Габделхак ӘХМӘТОВ.
Магнитогорск шәһәре.

● **Халык һөнәрен күрсәтә.**

Татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү фондының рәисе академик Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов белән әңгәмә.

Академик Миркасыйм ГОСМАНОВ:

РУХИ ТОРГЫНЛЫКТАН ЧЫГУ ЮЛЫ

— Хөрмәтле Миркасыйм әфәнде, мин Сезнең белән Татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү фондының эше турында сөйләшергә дип килгән идем.

— Бик рәхмәт. Сөйләшербез. Тик мин сүзне яңа гәзит — «Мәдәни җомга»ның чыгуы белән халкыбызны, гәзитнең бөтен укучыларын котлаудан башлар идем.

— Рәхим итегез, Миркасыйм әфәнде!

— Мәдәнияткә багышлап гәзит чыгару — зур күренеш. Халкыбыз гасырлар буена моңа сусап яшәде. Ләкин татарча басма сүзгә ирешү җиңел булмады. Беренче татар гәзите өчен көрәшә башлау XIX гасырның башына туры килә. Әмма ул 1906 елда гына чыга башлый. Халкыбыз йөз елга якын басма сүз булдыру хакына көрәшеп яшәде. XX гасырның 10-15 нче елларында шактый санда гәзит-журнал чыгып, халык рухи баеп, тернәкләнеп алды. Ләкин 1917 елгы вакыйгалардан соң милли басма сүзнең яшәве бик кыенлашты. 1920 елларның ахырыннан алып, үзгәртеп корулар башланганчыга кадәр татар телендә аз санлы, рәсми позицияне генә яктыртучы гәзит һәм журналлар чыкты. Анда да аларның эш мәйданы шактый тар булды. Халык, мәдәният, рухи культура өчен гәзит чыгару кыен иде. Мисалга «Идел» журналын чыгару өчен ун елдан артык кискен көрәш барганын китерү дә җитә. Үзгәртеп кору җилләре исә башлагач кына бу эшнә тормышка ашыру мөмкин булды. Шушыларны искә төшерсәк, «Мәдәни җомга» гәзите чыгу — зур вакыйга, әлбәттә. Яши алса — зур тарихи казаныш булыр.

Инде гәзитнең ике саны белән таныштык. Әлбәттә, ике саннан гына чыгып кискен карарга килү иртә; гадәттә яңа басма бер-ике ел дәвамында үзенең йөзен билгели. «Мәдәни җомга» берәр ел эчендә йөзен, юнәлешен тапса, бик мәслихәт эш булыр иде.

Һәр журналист теләсә кайсы басма өчен яза алмый. Шуңа күрә «Мәдәни җомга»ның үз кадрларын булдыру зарур. Аның матди яктан буш урында барлыкка килмәве уңай күренеш, әлбәттә. Әгәр хөкүмәтебез үзен демократик хөкүмәт дип исәпли икән, яңа органга тиешле игътибарын бирер, хәтта гәзит үзен беркадәр оппозицион хәлдә тотса да. Шушы уңайдан оппозициянең кирәклегенә, мөһимлегенә, зарурлыгына игътибар итәр идем.

1991 елгы вакыйгалар. Б.Ельцинның бер фәрманы нигезендә кодрәтле коммунистлар партиясе таралды да бетте. Ни өчен? Чөнки коммунистлар партиясе, үзенә оппозиция булырдай көчләрне тыеп килүе нәтиҗәсендә, үзенең көрәшә, ярыша алу сәләтен югалтты, аның көрәш, саклану иммунитеты юкка чыкты. Шуның өчен бердәнбер фәрман аның тиз таркалып, озак вакыт аптырап яшәвен барлыкка китерде. Оппозиция булмау һәрбер организмның яшәү сәләтен киметә.

Яңа гәзитнең рәсми хөкүмәткә оппозиция булуы кирәк. Оппозиция — дошман түгел, күзәтүче, төзәтүче дигән сүз. Җитәкчеләр, әгәр озын гомерле булырга телиләр икән, мөстәкыйль матбугат органына игътибар итәргә тиеш. Шуның өчен мин «Мәдәни җомга»ның мөстәкыйль фикерле махсус орган булуын теләр идем.

— Бик мөстәкыйль була башласаң, урыныңнан алып ыргытмаслармы соң?

— Мөстәкыйльләрне бүген алып ыргытсалар, иртәгә шул мөстәкыйльләрне алып ыргытучыларның үзләрен алып ыргытачаклар. Безнең дәүләтнең тарихы шуннан гыйбарәт. Большевиклар властька ничек килсәләр, аларның үзләрен дә шулай алып ташладылар.

Оппозиция дигән сүз дошман дигән сүз түгел, ул үлчәүнең икенче башындагы йөк, авырлык дигән сүз. Дөрес, моны аңлар өчен зур сәяси культура кирәк. Кызганычка каршы, моңарчы бездә андый культура булмады. Хәзер безнең җитәкчеләр шушы культурага ия булырга тырышырга тиеш, шулай булганда гына без нормаль җәмгыять төзи алачакбыз.

Япониядә язылмаган бер кагыйдә бар: андагы монополияләр үзара конкуренциядә яши. Ләкин Япония сәнәгатьчеләре бервакытта да үз конкурентларын юк итәргә тырышмыйлар. Җиңелеп көчсезләнгән көндәшләренә яңадан аякка басу мөмкинлеге бирәләр, компромисс юлын эзлиләр. Шул рәвешле төрле монополияләр арасында нормаль яшәү шарты тудыралар. Шуңа күрә алар яшәүгә сәләтле, һәм эшләп чыгарган продукцияләре югары сыйфатлы.

Бездә конкуренциянең юклыгы һәм товарларның сыйфатсыз булуы — мәгълүм факт.

Сәясәт белән җитәкчелек итү сәнгате дә ярышу ул, анда үзенә күрә көндәшлек шартлары да яшәргә тиеш. Шул вакытта гына үсеш була. Бер генә төрле сәясәт булдымы, ул — кризис дигән сүз!

Инде Фондыбыз турында нәрсәләр сорамакчы идегез, Саимә ханым?

— Башта, әлбәттә, кайчан оешуы, кем финанславы, максаты турында берничә сүз әйтерсез.

— Мин рәис булган Фонд «Җыен» фонды дип атала, ул — рәсми булмаган хосусый инициатива фонды. 1991 елда шәхси инициатива белән — Раил Сираҗиев, Разил Вәлиев һәм мин — оештырдык.

Фонд янында бизнес — сәүдә белән шөгыльләнүче «ТатАрт» дигән үзәк бар. Шуның керем акчасыннан тиешле өлеше Фондка бирелә. Китап чыгару, кайбер зыялыларга ярдәм итү максаты куела.

Татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү фонды 1991 елда зур җыен уздырды һәм үзенә «Җыен» дигән исем алды (соңрак) һәм беренче адымнарыннан ук китап чыгара башлады. Боларның беренчеләре — Михаил Худяковның «Очерки по истории Казанского ханства», Карл Фуксның «Казанские татары», Исмәгыйль Бәй Гаспринскийның «Россия и Восток», Һади Атласиның «Сөембикә» исемле китаплары булды.

М.Худяков һәм К.Фукс китапларының басылып чыгуы бик урынлы һәм үз вакытында булды. Бөтендөнья татар конгрессында Президент докладында татар тарихын дөрес чагылдырган өч тарихчының — Худяковның, Фукс һәм Гумилевның исеме аталды. Димәк, шушы нәширлек эшчәнлеге белән «Җыен» фонды тарихыбызны дөресрәк яктыртуда кайбер чараларны башлап җибәрде.

«Җыен» фонды театр һәм сәнгать әһелләренә дә мөмкин кадәр ярдәм күрсәтергә тырыша. Мәсәлән, Г.Камал исемендәге театр белән безнең хезмәттәшлек әйбәт кенә бара дип исәпләргә мөмкин. Бигрәк тә яшьрәкләргә ярдәм итәбез. Колумбиягә барып, андагы театр сәнгате белән танышып кайту өчен Фәрит Бикчәнтәевкә матди ярдәм күрсәттек. Стипендияләр бирәбез. Шактый вакыт моннан элек «Бәхетле балачак» дигән ансамбльгә яңа сәхнә киемнәре белән ярдәм иттек, концерт оештырыр өчен арендага бина алып бирдек.

Кайбер фәнни китапларның дөньяга чыгуына да Фонд өлеш кертте. Мәсәлән, Раиф Мәрдановның «Әл-Ислах» гәзитенә төзелгән күрсәткечен, Хатип Миңнеголовның «Татарская литература и Восточная классика» дигән китабын һ.б. чыгардык.

Бу юнәлештә эшләүне (китап чыгаруны) киләчәктә дә дәвам итәчәкбез. Шушы көннәрдә генә типографиягә берничә китап бирелде.

Киләсе 1996 елда татар театрының 90 еллык юбилее була. Менә шушы вакыйга уңае белән без 1926 елда чыккан, татар театрының беренче тарихы кебегрәк итеп язылган «Татар театры тарихыннан» дигән китапны бастырабыз. «Җыен» фонды шул рәвешлә театрыбызның юбилеен махсус билгеләячәк.

Икенче бер юнәлешебез — чит илләрдә һәм өлкәләрдә яшәүче татар диаспоралары хакында китаплар чыгарырга ниятлибез. Мәсәлән, Австралиядә яшәүче һәвәскәр шагыйрә Ләйлә Садриның шигырьләрен һәм мөнәҗәтләрен аерым китап итеп бастырырга уйлыйбыз, чөнки диаспорага игътибар бирү — безнең алда торган зур бурычларның берсе. Татар мәдәнияте гөрләп үскәндә ул диаспорадан көч алган. Әгәр без киләчәктә зур милләт булып, барлык татарларны бергә җыеп, бердәм булып яшәргә теләсәк, диаспорада яшәүче милләттәшләребезне дә онытмаска тиешбез. Бу юнәлештә эзләнүне, материаллар туплауны киләчәктә дә дәвам иттерәчәкбез.

Читтәге диаспоралар тарихын өйрәнү дә актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Шушы максаттан чыгып, мин үземә иң яхшы таныш булган Көнбатыш Кытайдагы татар диаспорасы турында бер китап яздым. Аның кыскача журнал варианты «Казан утлары»нда басылган иде. Хәзер ул күләмле китап кыяфәтен алды. Бу диаспорага махсус игътибар итүнең икенче сәбәбе — ул заманында чит илләрдәге иң зур диаспораларның берсе һәм иң көчлесе иде. Аның тарихы һәм гыйбрәтле, һәм фаҗигале фактларга бай. Киләчәктә шул китап та укучыларга барып ирешер дип өмет итәм.

— Фондның исеме — татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү дигән девиз белән бара. Ләкин сез чыгарган китаплар арасында урысча китаплар да бар. Монда берәр төрле каршылык юкмы?

— Минемчә, монда әлләни каршылык юк. Без чыгарган урысча китаплар элек урысча язылган әсәрләрдән гыйбарәт — Худяков, Фукс, Гаспралы китаплары. Икенчедән, татар телен үстерәбез дип урыс теленнән ваз кичеп кенә әллә нәрсәгә ирешеп булмый. Бездә, кайбер сай фикерле кешеләр кебек, урыс теленә карата бойкот ясау очраклары да күренә. Берничә ел элек яңгыраган мондый фикерләрнең ялгыш икәнен хәзер аңлый башладык. Әгәр тарихыбызны тирәннән, әтрафлап белергә теләсәк, урысча язылганнарны яхшылап өйрәнү, алай гына да түгел, гарәп, фарсы, монгол телләрендәге чыганакларны, немец, инглиз, француз телләрендә чыккан махсус хезмәтләрне дә белү зарур.

Өченчедән, һәм иң мөһиме — хәзер халкыбызның зур өлешенең бары урысча гына укый алуын онытмаска кирәк. Татар телендә генә китап чыгарып, тегеләрен читкә кагу милләтебезнең юкка чыгуын гына тизләтер. Урысча гына сөйләшә торган милләттәшләребездән без үзебезгә фикердәшләр, союздашлар эзләргә тиешбез.

(Ахыры 6 нчы биттә).

РУХИ ТОРГЫНЛЫКТАН ЧЫГУ ЮЛЫ

(Ахыры. Башы 5 нче биттә).

— Әйе, хәзер бит әнә чит өлкәләрдәге, БДБ илләрендәге татарча бер авыз сүз белмәгән кайбер милләттәшләребез үзләре яшәгән төбәкләрдә татар үзәкләре оештырып, шуның эшен башлап йөриләр...

— Әйе, шуннан соң инде без, кайберәүләр кебек, татарча начар сөйләшә торган милләттәшләребезне «манкорт» дип сүгү юлына бассак, үзебезнең телектәшләребез булырдай кешеләрне күбрәк югалтачакбыз. Аларның хәленә керергә, аларны да аңларга, дәрес информация һәм сыйфатлы китап белән тәэмин итәргә кирәк.

— Инде гадәттәге сорау, Миркасыйм әфәнде: «Җыен» фондының киләчәккә планнары нинди?

— Мәгълүм булганча, моннан ике ел элек «Җыен» фонды балалар җырына конкурс уздырган иде. Шушы юнәлештә киләчәктә дә эшләргә ниятебез бар. Ихтимал, нинди конкурс уздыру турында белдерүләр дә чыгарырбыз (аерым алганда «Мәдәни җомга» газете битләрендә дә).

Сәнгать әһелләренә хәл кадәре ярдәм итү дә өстән төшми.

Радио һәм телевизион программалар турында да хыялларыбыз, уйларыбыз бар. Планнар турында бик җәелеп сөйләшәсе килми, чөнки икътисади шартлар юрганыңа карап аягыңны сузарга мәҗбүр итә. Кайвакытта хәтта тезләрне бөкләп ятарга да туры килә.

Икенче төп юнәлеш — китап чыгару. Быел өч китап чыгарабыз. Киләсе еллар хакында да кайбер өметләребез бар. Минемчә, киләчәктә эшлисе эшләр турында җәелеп сөйләгәнче, конкрет эш күрсәтү дөрес һәм мәгкульрәк булыр. Чөнки, әйткәнемчә, киләчәктә икътисади хәлләрнең ничек буласын белгән юк. Уйлаганнарның минималь өлеше генә чынга ашса да, алга таба ике адым хәрәкәт булыр иде.

— Ә сез менә тел турында чыккан законнарны тормышка ашыру буенча тиешле оешмаларга тәэсир итә алмыйсызмы, «толкач» була алмыйсызмы?

— Митингларга чыгып кычкыру юлы белән түгел, реаль продукция бирү юлы белән тәэсир итү яхшырактыр.

Ә Фондның барлыкка килүе — хосусый инициативаны тергезү, шуның үрнәген булдыру, күрсәтү. Башкалар да уянсын, мөстәкыйль оешмалар булып алар да чыгарсын китаплар, алар да ярдәм итсен мәдәниятнең үсешенә.

Гасыр башында, мәдәният гөрләп үскәндә, ул хосусый кулларда булган. Ә инде гасыр уртасында, хөкүмәт кулына калгач, мәдәният үлә башлады.

Безнең максат — хосусый инициатива үрнәген күрсәтү!

— Аңлашылуынча, «Җыен» фондының эшчәнлеге төрле юнәлештә бара. Ә менә аның төп фәлсәфәсе дип нәрсәне күрсәтер идегез?

— Төп фәлсәфә — әле генә әйтелгән хосусый җәмәгатьчелек инициативасын аякка бастыру, шуның үрнәген күрсәтү, өлге, мисал бирү. Хәзер, бөтен җәмгыятебез интеллектуаль кризис кичергән бер вакытта, интеллектуаль торгынлык сазлыгына батканда мондый җәмәгать инициативасының әһәмияте бик зур. Халыкның үзе, аның вәкилләре эшкә ныклап керешсә генә без интеллектуаль һәлакәттән котылачакбыз. «Җыен» фонды эшчәнлегенең төп фәлсәфәсе дип интеллектуаль торгынлык белән көрәшүне атар идем. Тагын шундый фондлар оешып, һәрберебез һәр төбәктә эшли алсак, өстебезгә ишелергә торган интеллектуаль һәлакәттән котылу юлын табар идек.

— Әңгәмәгез өчен рәхмәт Сезгә!

Әңгәмәне
Сания ИБРАҺИМОВА оештырды.

К ҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫНДА

Тылсымлы дөньяга сәяхәт

«Казан» милли-мәдәни үзәгенең күргәзмә залларында төрле жанрдагы, төрле темаларга багышланган экспозицияләр сәнгать сөючеләрне чакырып тора.

Исхакыйга багышланган

Даими эшләүче экспозицияләрнең берсе озак еллар хаксыз рәвештә тыелып килгән һәм, ниһаять, исеме халкыбызга кайтарылган татар язучысы, публицист, танылган сәясәтче Гаяз Исхакый иҗатына багышланган. Әдипнең тормыш юлы, аны халык бәхете өчен көрәшкә дәртләндергән остазлары Ш.Мәрҗани, И.Гаспринский, замандашлары Г.Кариев, К.Мотыйгый һ.б.лар турында да күргәзмә бай мәгълүмат бирә. Шунда ук Г.Исхакыйның сәяси эшчәнлеген тулыландырган «Иттифак» партиясе, милли мәҗлес һ.б. темаларга караган экспонатлар да шактый.

Буыннар хәтере

Күргәзмә залының бер өлеше шулай дип исемләнгән. Бирегә соңгы елларда зур игътибарга лаек булган татар халкы тарихына, күренекле шәхесләр тормышына караган шәҗәрәләр тупланган. Алар белән танышканда ирексездән күңелдә сорау туа: мин кем, нәселем кемнән башланган, ник моңа кадәр гаилә шәҗәрәсенә игътибарым булмады? Ә бит һәр шәхеснең үз шәҗәрәсе бар, ул халык тарихы белән бәйле... Шиксез, бу экспозиция тамашачыларның игътибарын җәлеп итми калмас.

Татарстан җәүһәрләре

Бу күргәзмәдә татар халкының сәнгате, мәдәниятенең үсеше чагыла. Бу юлы экспозицияне оештыручылар халкыбызның матур үрнәкләре белән таныштыруны максат итеп куйганнар. Бирегә кулдан язылган борынгы китаплар, хаттатлар эшчәнлеге, шәмаилләр, ука белән чигү үрнәкләре белән танышырга мөмкин. Чаллыда яшәп иҗат итүче шәмаил остасы Ф.Гыйрфанов эшләре, рәссам Л.Фәсхетдинованың ука белән чигү үрнәкләре дә күргәзмәдә лаеклы урын алган.

Нәкыш сәнгате

Ул халкыбызда борынгыдан килә. Соңгы 70 ел эчендә бу өлкәдә олы рәссамыбыз Бакый ага Урманче саллы хезмәтләр бирде. Аның картиналары, графикасы, шәмаилләре күргәзмәне бизәп тора.

Нәкыш сәнгатен бүгенге көннәрдә рәссам Канәфи Нәфыйков та дәвам итә. Күргәзмәдә аның шактый эшләрен күрергә мөмкин.

Төрледән — төрле

Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты — рәссам Әхсән Фәсхетдинов күргәзмәдә үзенең «Ияләр, рухлар» дигән циклы белән катнаша. Шушында ук республиканың яшь рәссамнары иҗаты белән дә танышырга мөмкин. Керамика осталары Х.Латыйпов, Р.Нигъмәтуллина, К.Җәмитов сыннары мифология һәм серле ырымнар дөньясына алып керә.

«Казан» милли-мәдәни үзәгендә экспозицияләр, калейдоскоптагы пыяла кыйпылчыклары кебек, әледән-әле алышынып тора. Күптән түгел бирегә рәссам Мәхмүт Госмановның шәхси күргәзмәсе ачылды. Аның туган якны сурәтләгән реалистик картиналарыннан яктылык, җылылык бөркелеп тора.

Шау чәчәктәге бакчалар, нарат урманнары, агымсулар — табигатебезнең гүзәл мизгелләренә мәдхия булып күңелгә сеңә.

Татарстаннан читтә яшәп иҗат иткән рәссамнар белән дә милли үзәк даими таныштырып тора. Шул исәптән, Тольятти шәһәреннән 18 яшьлек Лариса Хафизованың күргәзмәсе тамашачы күңеленә хуш килер. Аның әсәрләрендә кызларга гына хас нәзакәтлелек, самимилек бар. Лариса йөрү бәхетеннән мәхрүм, әмма ул язган картиналарда тормыш тулы динамикада бирелә.

Күргәзмәдә шулай ук инкорель ысулы белән (аны испанлы рәссам Луис Ортега уйлап тапкан) эшләнгән полотнолар да бар. Күргәзмәнең бу өлешен рәссамнар үзара «Татарстан натюрморты» дип атыйлар. «Сөембикә» панносы бу натюрмортның йөзек кашы дип бәяләнергә лаеклы.

Сәнгать сөючеләр, сезне «Казан» милли-мәдәни үзәге чакыра.

Рауза СОЛТАНОВА,
мәдәни үзәкнең
фәнни хезмәткәре.

«Сокландыргыч башкала»

Лондондагы Flint River Press ltd фирмасы «Казан. Сокландыргыч башкала» дигән бик матур альбом чыгарды. Урыс, татар, инглиз телләрендә дөнья күргән бу басмада татар халкының мәдәнияте турындагы сүзне Казанда туып-үскән шагыйрь Равил Бохараев язган.

Фоторәсемнәрен Белградтан килгән Драголюб Замурович төшергән. Әлеге фото остасы дөньяның күп шәһәрләре һәм илләре турындагы альбомнарга иллюстрацияләр ясаган. Үткән ел исә ул Татарстан башкаласына килеп киткән иде.



● «Идегәй» китабына Рушан ШӘМСЕТДИНОВ ясаган рәсемнәр.

Зөлфәт

Яшенле төн

Ниләр булды икән сиңа тагын? —
Яшенле төн сыман шомлы чагым...

Күкрәгемдә тора күкләр күкрәп,
Йөрәктә шау ялкын дулый дөрләп.

Ни китерде сиңа яңа таңың?
Ниләр булды икән сиңа тагын?

Дәваламый гына Вакыт-табиб,
Онытырга күптән вакыт та бит! —

Ләкин өрнү һаман килә тора,
Суык елларны да ера-ера.

Сыкранасың текә упкын-ярда:
«Алып кит лә мине! Син кайларда?!»

Һәрбер мәлем минем —
яшенле төн.
Сорау бирә гомер: «Син кем? Син кем?»

Тик шул сорау яна җанда дөрләп.
Күкрәгемдә тора күкләр күкрәп.

...Курыкмыйча кара бу яшенгә —
Ул яшендә
минем күз яшем дә...

5 июль, 1995 ел.

Юаныч

Сәер гомер биреп шагыйрь итте...
Тик язмышка җанда үч ятмый —
Мин —
аш пешергән учак түгел,
Кызык өчен яккан учак мин.

Ялкыннарым уйный. Күзлар кыза.
Өчкын өермәсен җил йота.
Туктал, юлчы, уйлан утка карап
Учак янындагы тынлыкта.

Без юлдаш бит, юлчы!
Син белмисең
Юл соңында ниләр көткәнен.
Кызык өчен җирдә мин кабындым,
Кызык өчен күккә китәмен.

Өзын була күрсен, юлчым, юлың!
Миңа язсын озак дөрләргә.
Тик язмасын пыскып интегергә
Җирдә учак кирәк көннәрдә...

Уйлан, юлчым! Уйчан кәеф белән
Уйланасы килә минем дә —
Ялкын төсем калсын күзләреңдә,
Җылым калсын синең киемдә...

Синең үең калсын ялкынымда,
Калсын синең авыр серләрең —
Хәсрәтләрдән сине йолыр өчен,
Бер уйлатыр өчен дөрләдем.

Юаныш уз минем янда, юлчы,
Хәсрәтең бит, әнә, ничаклы!
...Мин
аш пешергән учак түгел,
Юанырга яккан учак мин...

5 июль, 1995 ел.



Гомеркәй

Кичке шәфәкъ алсуланган чакта
Ике җиһан китте җанымнан —
Берсе ашты чиксез биек күккә,
Берсе сеңде җиргә
Тын гына.

Бер сәяхәт бугай бу гомеркәй!
Язмыш, дибез узар юлларны...
Биниһая тирән икән язмыш,
Биниһая
Язмыш югары!

Ходай безне
Серле бу Җиһанга
Серле сәфәр өчен яраткан:
Алсу таңнан кичке шәфәкъка
Һәм
Алсу таңга —
Кичке шәфәкътан.

Таң сызылып аткан серле мәлдә
Ике Җиһан кайтты җаныма —
Берсе инде чиксез биек күктән,
Берсе менде җирдән
Тын гына...

4 июль, 1995 ел.

Ык

Йа Ходам, якты бу дөньяң!
Ык суы
чыктандыр ла,
Ыкның якты дулкыннары
Чыклардан чыккандыр ла.



Төсләрен алгандыр ла Ык
Салават күперенннән,
Назларын алгандыр агым
Гөлләрнең керфегеннән.

Җир сүзе аша гарешкә
Чык сарган камышлардан —
Билләһи сәҗдә китәрлек
Тезләнеп нишы ярга!

Гомерне салып суыңа
Юасы иде, агым —
Аксын да китсен иде лә
Гомерлек гөнаһларым...

Чайка бер минем гомерне,
Һич кенә карышмамын —
Бардыр бит инде миндә дә
Кемнеңдер каргышлары?

Аксын да китсен елларның
Саташып узганнары,
Югалсын синең чоңгылда
Чигәсе изаларым! —

Диеп дәшкән булам Ыкка,
И юләр, тома юләр! —
Ходайга синең бурычны
Шул Ыгың мәллә түләр?

Син бит адәм баласы шул!
Гөнаһсыз —
балык кына...
Котылып булмас язмыштан
Ыкларга салып кына.

...Ә шулай да Ыкка карыйм
Догалы бәндә сыман,
Мең шөкер итеп язмышка,
Ярында сәҗдә кылам.

Ыкның якты дулкыннары
Чыклардан чыккандыр ла...
Йа Ходам! Якты бу дөньяң! —
Ык суы —
чыктандыр ла...

4 июль, 1995 ел.

Баз исе

Мин дә кайттым туган нигеземә...
Саумы, гөрләп торган шау урың!
Җанлы иде синең кышкы карлар,
Тере иде синең яңгырың!

Шушы бәбкә үләнгә ятып
Мин идемме җырлар җырлаган?
Торылдашып биек-биекләрдә,
Муен сузып ерак киңлекләргә
Очып уза иде торналар...

...Сәлам биреп,
Атлап керсәм дә мин
Туган йортым җавап бирмәде.
Бусагасы мине танымады,
Тәрәзләре мине күрмәде.

Тәрәзәләр киереп ачкан чакта
Ургып керә иде яз исе.
Хуҗасыз йорт
үлем эзли бугай —
Тулган аңа юеш баз исе...

Әткәм тавышы да юк шул инде.
Ишетелми әнкәм көлгәне.
Тәрәзәләр сукыраеп калган.
Исән бары
Бәбкә үләне.

Күз алдымда әмма
тере төрмыш,
Мәңге бетмәс сыман дөньяда! —
Әнә, әткәм тынып намаз укый.
Әнкәй камыр изә. Мич яна.

Мәңгелектәй иде лә бу нигез!
Йөрәкләрне кысып моң баса —
Таралырдай нигез идемени
Таратучы чорлар булмаса?!

Издә безнә бәрхәдәрсез чорлар,
Барысы да сүнде, сүтелде.
Инде менә йорт та үлеп бара,
Үлеп бара
Кеше шикелле...

Кабатланырмы соң
Тәрәзләрдән
Ургып-ургып кергән яз исе?
...Мин йортыма карап
Илне уйлыйм —
Тулган аңа юеш баз исе...

4 июль, 1995 ел.

БЕЗГӘ КУНАК КИЛДЕ

Виктор РОЗОВ:

«МИН ГОМЕРЕМ БУЕ ТАТАРЛАРГА ШӨКЕР ИТӘМ...»

Бирим дисә колына — чыгарып куяр юлына, ди безнең халык Аллаһы тәгалә хакында... «Мәдәни җомга»быз борын төртеп маташкан көннәрдә баш мөхәррир мине дә яңа гәзиттә актив катнашырга өндәде. Ничек баш тартасың? Зарыгып көтеп алган мөнбәребез ич! Һәм менә көтмәгәндә Казанга Мәскәүдән мәшһүр урыс драматургы Виктор Розов килеп төшмәсенме. Ә мин аңарда ике ел драматургия серләренә өйрәнгән кеше — кунактан интервью алып калырга бик кулай форсат. Югарыда телгә алынган әйтем шуңа искә төште.

Чынлап та, Виктор Розов — күп кенә татар драматургларының Укытучысы, инде дистәдән артык ел аның белән күрешелмәгән — Ходайга шөкер итми нишлисең. Ә минем үземә бу исем бигрәк тә якын һәм кадерле: ул минем «Китәм инде» дигән драмамны урысчага тәрҗемә итеп («Под знаком Марса» дип атады ул аны), шул елны гына Мәскәүдә чыга башлаган «Современная драматургия» журналында бастырды. Үзем моны хәтта белми дә калдым! Җитмәсә, сез миңа, зинһар, үпкәләмәгез, Ризван, рөхсәтегездән башка гына журналга бирергә җөрьәт иттем, ди очрашкач. Нинди үпкәләү ди! Виктор Розов бүтән берәүнең пьесасын тәрҗемә итсәме?! Кавказлы драматурглар тартма-тартма чәчә аракысы һәм иң шәп коньяк-шәрабләр, шәшлеккә түшкә-түшкә яңа чалган сарык итләре аның алдына китереп салыр иде! Ә уртаазиялеләр!.. Юк, фәкыйрь татар баласының «бөреңге күшәп тәрбияләнгән» хыялы аларның чын сый-нигъмәтләрен күз алдына да китерә алмый. Абруе бөтен дөньяга таралган язучының андый хөрмәтләргә генә хакы баштан ашкан. Күпме драматургның чиле-пешле пьесасын, урысчага тәрҗемә итеп «кеше ясап», дөнья күзенә чыгарды ул! Тик ул үзе кавказлыларның да, уртаазиялеләрнең дә юмартлыкларын ишек тупсасына да якын китерми — холкы ул түгел. Ә минә аның җиңел кулы кагылган һәр әсәргә күк капусы ачылуы — бәхәссез. Мин моны үз пьесамның бәхетле язмышыннан чамалыйм: Виктор Розовның исеме белән әртелгәч, аны, унбишләп телгә аударып, күп кенә сәхнәләрдә уйнадылар. Шулар арасында данлыклы Балтыйк буе, Кавказ һәм Урта Азия сәхнәләре дә бар. Үзебезнең Казаныбызда гына да берьюлы ике театрда уйналды ул. Шуңа күрә, күренекле драматургның Казанга килүе минем өчен көтелмәгән зур куаныч иде.

Кунакның үзе белән әңгәмә башлаганчы, гәзит укучыларының хәтерен бераз яңартып үтәм. Виктор Сергеевич Розов, инде сигез дистәнең аргы ягына атлап чыккан кеше, үз гомерендә ничә пьеса язганын үзе дә төгәл генә әйтә алмыйдыр — бик күп, ике сүз белән генә әйткәндә, аның әсәрләре нигезендә кинофильмнар төшерелгән һәм төшерелә (мисалга кайберләре: «Летят журавли», «Я шагаю по Москве» һ.б.), Җир шарын Магелланнан ким урамагандыр: Америкада да, Аурупада да, Азиядә дә көтеп алынган хөрмәтле язучы ул һәм танылган җәмәгать эшлеклесе, дәүләт бүләге лауреаты, әдәбият институты профессоры һ.б., һ.б. Ә урыс драматургиясендә аның урынын бүтән беркем дә дәгъвалый алмый: безнең илдә драма конфликтсыз булырга тиеш дигән ялагай уйдырма чәчәк атканда (илленче еллар) Виктор Розов кискен бәрелешле пьесалар иҗат итә башлап, ярты гасыр эчендә яшьләрнең театраль олъязмасын булдырды.



Новой газете пожелание — стареть и стареть — долгой жизни!
В. Розов
1995.

Виктор Розов белән без — Зиннур Мансуров, Рөстәм Мингалим һәм мин — елга вокзалында «Виссарион Белинский» теплоходында очраштык. Ул элеккечә үк үткен күзле, ачык йөзле һәм җиңел сөякле кеше икән: безне каютасының ишеге төбендә күрүгә, өстәл яныннан сикереп торып, ике куллап күрешге (татарларга хас бу гадәте каян килгәнлеге әңгәмәбез агышында беленер). Җиңел хәрәкәтле булса да, без кергәндә үк аның даруга охшаган төймә капканын күреп өлгердек: хатыны Надежда ханымның — без аңа шулай дип дәштек, чөнки әтисенең исемен төгәл әйтә алмабыз, дип шикләндек — соңрак иплән кенә кисәтүеннән олуг кунакның инде ике мәртәбә авыр инфаркт кичергән булуы ачыкланды. Хәл-әхвәл сорашкач, әңгәмәбез гап-гади сораудан җанланды:

— Виктор Сергеевич ! Бик тәвәккәл кеше икәнсез : урамга чыкмаслык челлә, ә Сез — олы юл уртасында.

— Челлә?! Идел буйлап югарырак менеп карагыз сез! Дөрес, баштарак безне Казан тирәсендә 40 градустан ким түгел, дип куркытканнар иде. Килеп җитсәк — җанга рәхәт җиләс һава... Оҗмахта яшәп ятасыз сез, яшьләр!

Безнең Идел күбеге кебек чаларган башларыбызга игътибар да итми бу карт! Сиксән ике яшьлек биектән шулай күренәбездер инде.

— Яшьләр, дисез дә... Казан урамнарына без кичектермәслек зур йомыш төшсә генә чыгабыз.

— Ә Идел — минем шундый «урамнарым»ның берсе инде! Германия немецларының Идел буйлап сәяхәткә чыгуларын ишетүгә, шундук фрахталаган парахутларын абордажга алдым. (Көлә). Волгарь бит мин: Костромада буын сикерткән джигит.

— Ишетүебезчә, теплоход Әстерханга чаклы төшәчәк икән, ә Сез, Казанда туктап, Мәскәүгә кайтып китәсез, диделәр.

— Сәбәбе бар аның... Мин, гомумән, гомерем буе татарларга рәхмәтлемен! Дүрт-биш яшемнән якыннан күреп беләм мин сезнең халыкны, — дип дәвам итте ул сүзен, безнең сораулы карашларыбызны күреп. — Костромада безнең каршыда гына Татар бистәсе бар иде. Кечкенә елга аркылы гына чыгасы . Мәчетле, базарлы. Баштарак без, бала-чага, алар ягына чыгарга шөлли идек. Шулай да, кайбер татарларны күреп беләбез: иртәләрен алар безнең якка чыгып катык-сөт саталар. Аларны, бер-ике адым атлауга, бөтен халык сырып ала: чөнки иң чиста, иң тәмле катык-сөт татарларда гына була. Әчеп-тузып йөргән татарны гомумән күргәнебез булмады. Шундый иплеләр, эчкерсезләр һәм үз кадерләрен үзләре беләләр. Шуңамы икән, Татар бистәсенә чыгып йөрергә тиз генә базмадык... Ә соңрак — безне аннан аркан белән дә сөйрәп кайтарып булмый башлады! (Көлә). Ләкин Казанда төшеп калуымның сәбәбе яшьлек истәлекләрем түгел... Сугышта каты яралангач, шактый озак дәваланып ятырга туры килде миңа монда. Госпиталь мехчылар клубында иде. Исәнме әле ул клуб?.. Бик әйбәт: инде өметсез моның бер аягы дигәндә, ике аягыма да исән-имин бастырган җирне кабат күрәчәкмен икән! Казанны да карап йөрисем килә...

Алданрак булса да, әйтеп үтим: иңенче көнне без Виктор Сергеевич белән тагын очраштык һәм ул безгә мехчылар клубында булуын, хәзер ул чакта үзе дәваланып яткан иркен палатаның вак өлешләргә бүлгеләнүен, элек госпитальдә эшләгән татар врачларының һәм шәфкать туташларының олы йөрәкле, һәркемгә тигез игътибарлы һәм үтә кече күңелле булуларын кат-кат, дулкынлануын яшермичә, бәйнә-бәйнә сөйләде. Ә бит ул көннәрдә госпиталь яралылар белән энә төшмәслек шыгрым тулы иде, дип берничә мәртәбә кабатлады ул. Тынгысыз кунагыбызга Казанның күп җирләрен күрсәткәннәр икән: мәркәзегез шактый нык матурланган һәм искиткеч чистарган (Сугыш чоры белән чагыштырганда шулай тоеладыр, әлбәттә! — Р.Х.), шәһәрнең гүзәл йөзен билгели торган элекке мәһабәт биналарны саклавыгызга сөендем, ди. Иң азактан гына: «Тик бер нәрсә эчне пошыра: Казанда да яңа бистәләр — бөтен Рәсәй калаларыннан берние белән дә аерылмый икән — шул ук шыксыз шырпы тартмалары... Кайда да тоталитар дәүләт чире!» — дип өстәде.

Әлегә бүгенге әңгәмәбезне дәвам итәбез. Сүз, ниһаять, үз «атларыбызга» — драматургиягә һәм театрга күчә.

— Виктор Сергеевич, Сез татар драматургиясенә шактый якыннан тәэсир иткән язучы...

— Каян килеп?!

— Татар драматургларының күбесе Сезнең курсларда драматургиянең алгебрасын өйрәнде... Хәтта кайберләребезнең әсәрләрен Сез үзегез урысчага тәрҗемә иттегез...

— Дөрес. Мәсәлән, Ризван, сезнең бер пьесагызны. Ләкин болар гына миңа татар драматургиясенә якын торам, дип әйтергә нигез бирми. Драматургларыгыздан Аяз Гыйләҗевне, Туфан Миңнуллинны, Батулланы... менә каршымда тын гына утыручы Рөстәмне һәм тагын кайберәүләрегезне бераз беләм... Хәзерге татар драматургиясенә ничек карыйсыз, дип сорамакчы буласыз, шулай бит?

— Шулайрак иде... Хәтерлисезме икән, Виктор Сергеевич, сиксән икенче елда сәнгать фәннәре докторы Инна Люциановна Вишневская «Литературка»да: «Илебез драматургиясенең бүгенге биеклеген татар драматургиясе билгели», — дип язып чыккан иде?

— Бу бәя — Инна Люциановнаның намусында! (Көлә). Сүзем юк, мин аның белән озак еллар бергә эшләдем, аның беркайчан да, нигезсез авыз күтәреп, җилгә сүз ташламаганын яхшы беләм. Хәтерлим, бик хәтерлим мин аның зур бәясен... Күпмедер хаклык та булгандыр анда ул чорларга карата... Ә инде бүгенге хәлләргә килсәк һәм бигрәк тә — алдагы перспективаларны күз алдында тотсак... Гомумән, бүген кемгә кирәк соң чын драматургия?!

Менә сиңа мә! Радиодан, телетапшырулардан исеме төшмәгән, пьесалары төрле телле сәхнәләрдә туктаусыз шаулап барган данлыклы драматург авызыннан шундый пессимистик сүз чыксын инде...

— Сезнең үз пьесаларыгызның сәхнә түреннән төшкәне юк ич, Виктор Сергеевич?

— Инерция генәдер ул бәлкем?.. Мәскәү сәхнәләрен генә алыйк: бүген нинди пьесалар куела анда? Бәясе өч тиен тормаган чүп-чар! Сәбәбен дә бик җиңел аңлаталар: халык җитди сүздән гарык булды, имеш, тамашачыга уен-көлке, көмит кирәк... Уен-көлкенең дә төрлесе була. Берәүләр артистны сәхнәдә шатыр-шотыр кашындырып тамашачыны шаркылдата, икенчеләр — бөек Гоголь, мәсәлән — бөтен Рәсәйнең ялган битлеген ачып, күз яше аша көлдерә! Халык җитди сүздән туймады, буш сүздән туйды. Киресенчә, аңа чын җитди сүзне әйткәннәре юк әлегә. Һәм җитди сүзне сәнгатьчә әйтә белүче режиссерлар калмады — менә нәрсәдә хикмәт! Әнә — дебаркадерда минем улым Серый йөри. Режиссер Сергей Викторович Розов. Режиссерлар хакында тәпләрәк итеп аның белән сөйләшә аласыз... Хәер, үзегез дә бүгенге театр хәлен яхшы беләсездер, дип уйлыйм. Сүз җаеннан, Ризван, сез үзегез соңгы елларда ниләр кырдыгыз? Ялгышмасам, драматург Юлиу Эдлис бервакыт сезнең турыда, аннан

мин Европа дәрәҗәсендә драматург чыгачак, дип өметләнәм дигән иде. Йә, мактаныгыз?

— Аурупа драматурглары арасында минем исем күзегезгә чалындымы соң, Виктор Сергеевич? (Көлә). Җитди генә әйткәндә, әллә ни зур эш майтарганым юк әлегә... Тарихи темаларга тотындым соңгы елларда. Киносценарийлар белән дә мавыгам.

— Куелалармы соң?

— Өметемне өзмим әлегә.

— Менә-менә! Нишләп хәзерге заман темаларына әйбәт кенә әсәрләр яза ала торган драматург тарихка чумган да, әлегә перспективасы нульгә якын булган кинога тотынган? Җавап кирәкми: чөнки театрга бүген җитди драматургия кирәкми! Дөресен әйткәндә, мондый тотрыксыз заманда эпоха ясарлык пьеса туа да алмый. Драматург белән вакыйга арасы ерак булуы зарур. Даль сүзлегендә онытыла башлаган бер зирәк тәгъбир бар: «дар прозора». Алдан күрә белү сәләте, дип якынча аңлатырга була аны. Тарихка тотынып сез бик дөрес эшләгәнсез: халкыгызның артта калган ерак тарихы сезне алга таба да ераграк карарга өйрәтер. Татар драматургиясенең киләчәк язмышын әнә шундый «дар прозора»га ия була алган драматурглар гына уңай якка хәл итә алыр, дип уйлыйм мин... Бу — бар халыкларга да кагыла.

— Виктор Сергеевич, Сез еш кына радио аша һәм телетапшыруларда чыгышлар ясыйсыз. Әлбәттә, чыгышларыгыз күбрәк үзегез яраткан яшьләр темасына була. Әмма, белүебезчә, бүгенге сәясәттән дә читтә тормыйсыз. Шушы көннәрдә Татарстан үзенең суверенлыгының бишьеллыгын билгеләп үтә. Безнең республиканың Бәйсезлек игълан итүен ничек кабул иттегез?

— Бик яхшы кабул иттем. Рәсәй — Федератив дәүләт икән, анда яшәүче бөтен халыклар да тигез хокуклы, бер-берсенә буйсынмаучы, бәйсез булырга тиеш. Хәзергә ул — кәгазьдә генә. Ә тигез хокукны беркемгә дә «зәңгәр каймалы тәлинкә»гә салып китереп бирмиләр. Һәр халык аны үзе яулап алырга тиеш. Цивилизацияле юл белән, әлбәттә.

— Цивилизацияле юл дигәннән... Виктор Сергеевич, цивилизацияле илләрнең дәүләт башлыклары, гадәттә, элегрәк ата-бабалары бүтән халыкларга кылган начар гамәлләре өчен бүген гафу үтенәләр. Ә Рәсәйнең бүгенге җитәкчеләре татарлардан һәм башка йөзләгән халыклардан, ата-бабалары аларның дәүләтләрен җимереп, мәдәниятләрен юкка чыгарган һәм йөзләрчә меңләгән кешеләрен кырган өчен гафу үтенергә җыенмыйлар, ахрысы... Киресенчә, бүген үзләре Чәчәнстанны көлгә әйләндерделәр!

— Цивилизацияле илдә яши башлыйк, аннан сөйләшербез бу темага.

— Бирсен Ходай!

— Да-да, дай Бог...

....

Сиксән яшәгән мәшһүр драматург, каютасыннан чыгып, авыр аксый-аксый трапка кадәр төште һәм безнә сагышлы карашы белән озатып калды: аның үткән күзләре бик еракка, алга төбәлгән кебек тоелды...

Шушында аның «В поисках радости» дигән пьесасыннан бер яшь персонажның репликасын китерү бик урынлы булыр төсле:

«О л е г (задумавшись). Тогда, Гена, совсем не будет коммунизма, никогда!»

Бу пьесасын Виктор Розов 1956 елда төмамлаган...

Әңгәмәне Ризван ХӘМИД язып алды.

31 июль, 1995 ел.

Мөнәсәбәт

Заһид МӘХМҮДИ

Йөрәкне алыштырып була. Ә намусны?



Узган атнада Бразилия табиблары берәүгә ясалма йөрәк куйдылар. Шәп эшли, нәкъ йөрәк кебек, минутына алтмыш тапкыр тибә.

Алла боерса, киләчәктә ясалма башлар да булыр әле. Әмма Ходай иҗат иткән баш белән дә күпме ахмаклыклар эшләгән кешелек дөньясы ясалма баш белән нәрсә кыла алыр? Бер гомернең, бер башның кадерен белмәгән адәм баласы икенче башның кадерен белерме?

Ярый, бусы хыял гына. Ә намусны алыштырып буламы? Ул инде йөрәк тә, баш та түгел. Булмастыр, мөгаен. Бер тапкыр тапладыңмы, агартам димә. Тапланган намус, каралган теш кебек, бер сызларга тотынса, дару гына коткара алмас.

Президент Ельцинны да намусы борчый башлады, ахры. Һәрхәлдә, ул хастаханәдә дәваланган вакытта «Вести» программасын алып баручы, Президентның йөрәге авырып китүенә Чечня хәлләре дә сәбәпче булгандыр, дип турыдан-туры әйтеп салды.

Грозныйга гаскәр кертеп, Конституцион тәртип урнаштыру Рәсәйгә бик кыйммәткә төште. Солдат шинеле кигән унсигез яшьлек егетләр анда тугыз ай дәвамында шәһәр һәм авылларда сугыш хәрәкәтләре алып бару тәҗрибәсе тупладылар. Тик әлеге тәҗрибә Рәсәйгә коточкыч мәгънәсез һәм куркыныч суешта башларың салган шушы меңнәрчә егетләрнең табутлары, ата-аналарның канлы күз яшьләре рәвешендә кайтып керде. Татарстанга да кайтты берничә табут. Очраклы хәл булдымы бу гамәл? Юк, барысы да белә торып һәм аңлы рәвештә эшләнде. Чечняның шәһәр-авылларын җир белән тигезләгәндә, гөнаһысыз тыныч халыкны чебен урынына кырганда Ельцинның һәм иярченнәренең бер күзе Татарстанда булды түгелме? Безнең ишеләргә гыйбрәт өчен эшләделәр моны. Ике-өч ай элек мондый фикер Мәскәү радиосы һәм телевидениесе аша ачыктан-ачык күп тапкырлар һәм максатчан рәвештә яңгырады.

Шулай итеп, әле кайчан гына СССР Конституциясенең дистәдән артык маддәсен бозып, коммунистлар партиясен таркаткан (яхшымы ул, начармы, Төп Законны берәүнең дә бозарга хакы юк), РФ Югары Советы депутатлары утырган Ак йортны тупка тоткан Президент Конституция турында «кайгырта» башлады. Ләкин бусы да чираттагы күз буяу гына булды. Чынында Ельцин һәм аның командасы, Федерация, дип, ярым фашистик унитар дәүләткә нигез сала башладылар. Элекке империя урынында икенчесе — тагын да куркынычрагы һәм мәкерлерәге туып килмиме? СССР барында Татарстан бәйсезлек өчен көрәштә ялгыз түгел иде. Аның башка республикалар кебек үк үзбилгеләнү хокукы булган союздаш республика статусы алу мөмкинлеге бар иде. Балтыйк буе, Урта Азия республикалары бәйсезлек өчен көрәш алып барганда Татарстанга урыс шовинистларының теше бик үтмәде. Хәзер без бу ике башлы каракош белән кара-каршы утырып калдык. Безне нинди язмыш көтә? Татарстан үзенең дәүләтчелеген торгыза алырмы? Әллә ул киләчәктә гөбернә генә булып калырмы?

Ельцин режимы кризис чорын кичерә. Аның һәм «сугыш партиясе»нең чечен халкын буйсындыру турындагы нияте тормышка ашмады. Илдә тәртип юк: халык хуҗалыгы ярым җимерек хәлдә, инфляция, эшсезлек һәм җинаятьчелек көннән-көн котырып үсә бара.

Шушы елның беренче ярты елында Мәскәүнең үзендә генә дә егермедән артык җинаятьчел төркем кулга алынды. Ә иректә калганнары күпме? Заказ буенча үтерүләр инде күптән гадәти хәлгә әверелде. Әле тегендә, әле монда ясалма бомбалар шартлый, террорчылар самолетларны, автобусларны кулга төшереп, заложниклар ала, завод-фабрикаларда һәм шахталарда бетмәс-төкәнмәс аварияләр, үлем-бетемнәр булып тора. Төрмәләр шыплап тутырылган. Яңаларын төзергә акча каян табалар, диген син.

Чит илләрдә бөтенләй башка хәл. Әйтик, Америка Кушма Штатларында җинаятьчеләр саны түгел, бушап калган төрмәләр саны арта бара. Мисал өчен, Техас штатында 800 кешегә исәпләнгән бер төрмә администрациясе хәзер аны кунакханә буларак файдалана. Кеше ышанмаслык хәл! Аларда нигә шулай икән дә, бездә нигә шулай? Сәбәбе мәгълүм: америкалылар безнең кебек ел да бер Конституция кабул итмиләр. Алар ике йөз ел элек кабул ителгәненнән бик канәгать. Безнең кебек атлаган саен референдумнар, сайлаулар да үткәрмиләр. Ә болар миллиардлаган сум акча чыгымнары таләп итә. Һәм ул кемнең кесәсеннән чыга дип уйлыйсыз? Сезнең белән минем кесәдән!

Быел Россия Федерациясендә яңа сайлаулар көтелә. Ул безгә күпмегә төшәр? Белгечләр әйтүенә караганда, 400 миллиард сумнан да ким булмас. Менә нигә хәерче Россия! Менә нигә безне һәм Чечняны кулдан ычкындырырга теләми — майлы калҗа ычкына кулдан!

Мәскәү тарафыннан шуның кадәр җәзаланган, мәсхәрә ителгән, иза чиккән батыр чечен халкын Россия Федерациясе составында калдыру кайсы як өчен генә файдалы булыр икән? Ике арада барган канлы суеш өлкән буыннар гына түгел, балалар күңеленә дә мәңге онытылмаслык үч һәм нәфрәт тойгысы салып калдырды. Алар арасында Җәүһәр Дудаев һәм Шамил Басаев булып үсәргә теләүчеләр бик күп булыр әле. Шулай булгач, бер урыс сәясәтчесе әйтмешли, ничәмә-ничә еллар буена бәйсезлек өчен көрәш алып барган Ичкерия халкын тынычлыкта калдыру дөресрәк түгелме? Иманым камил, Рәсәй составында калган очракта, Чечен Республикасы тагын ике йөз ел буена бөтәү яра булып торачак.

Аз гына намусы булган республика җитәкчеләре, дипломатлар, депутатлар, сәясәтчеләр, хәрбиләр, әдәбият һәм сәнгать әһелләре Чечнядагы сугыш хәрәкәтләренә карата тискәре мөнәсәбәтләрен белдерделәр инде. Татарстан да үз мөнәсәбәтен белдерде. Россия хөкүмәте белән генерал Дудаев вәкилләре арасында җитди сөйләшүләр башланып китүдә аларның да өлешләре зур. Ә Шамил Басаевның Буденновскига ясаган походы вакыйгаларны тизләтте генә.

Җитәр, сугышмыйк инде, егетләр. Тыныч, тату булып яшәсәк, адәм затына ясалма йөрәк тә, ясалма баш та кирәк булмас.

Мәгыйшәт

Гомер юлындагы чакрым баганаларын күбрәк арттa калдырган саен кеше үзенең үткәненә җентекләбрәк карый башлый булса кирәк. Минем гомеремнең азмы-күпме йөк салган арбасы да алтмыш алтынчы баганага якынлашып бара. 1930 елның 17 гыйнварында Чистай каласында дөньяга килгәнмен.

Шундый тойгы белән яшим: гүя тормышымның буеннан-буена күзгә күренмәс кыллар сузылган. Кайчак язмыш аларга оста музыкантларча кагыла (күркәм көннәр кичерәм). Ә кайвакыт шул нечкә-нәфис кылларга кувалда белән оралар (ник туганыма үкенерлек халәттә калам).

Әти-әнием — Фатыйма һәм Хәмит Камаловлар Чистай педагогия техникумын тәмамлаган авыл укытучылары иде.

Җиденче класстан соң, 1943 елның көзендә Буа ветеринария техникумына укырга кердем, ләкин октябрь бәйрәменә кайтканнан соң укырга бармадым. Күңелем тартмый иде. Әни, йомшак холыклы хатын, әллә ни басымчакланмады. Хәзер болай фикерлим: ярый әле телер-теләмәс укып китмәгәнмен. Яратмый өйләнергә мәҗбүр булган кеше төсле, күңеленә чит булган хезмәттә гомер буе изаланыр идең, корылы йөрү (йөксез) килеп чыгар иде. Ә болай, яраткан эшемә муеннан чумып эш иткәч, үземне сират кичеп, фирдәвестә (иң беренче дәрәҗә оҗмахта) утыргандай хис итәм. Әдәбият минем өчен сәгадәт талы (бәхет символы!) Ветфельдшер булып китсәм, рас әгәрә, сукырларга күзгә сатучы булыр идем...

Исәктән Күл-Черкен авылына күчеп килгәч, колхозда эшли башладым. (Ул елларда — «Искра», хәзер «Ватан» колхозы). Такыр басу торнасы (артык кашык) булып яшәр хәл юк иде. Ире фронтта һәлак булган апаның — җиделлык мәктәп директоры Хәтимә Курамшинаның үзенең дә өч баласы бар иде бит. Дәү әни дә аның тәрбиясендә.

Колхозда үгез дә җиктем, ат та. Кырга тирес чыгардык, чәчүлек орлык, көлтә ташыдык, көз азагында Лашчы разъездына бәрәңге илтә идек. Кордашлар белән эшләү үзенә бер канәгатьләнү бирә иде шикелле.

1944 елның көзендә мин Буа шәһәрендәге Мулланур Вахитов исемендәге урта мәктәпнең сигезенче классында укый башладым. 1945—46 уку елында тугызынчы классны тәмамлагач, хәл мөшкелләнде. Өс-баш чыгып төшүте, ризык дигәненә өмет киселде. Тәрәксез калган колмак сабагыдай булдым. Уф, дип суласам, дәрья болганыр иде кебек тоелды.

Каңгырып йөргән көзге көннәрнең берсендә мине Буада яшәүче атаклы артистка Зөләйха апа Богданова очратып, хәл-әхвәл сорашты (минем аның агитбригадасында район авылларын әйләнеп чыкканым бар иде инде). Аннары кырт кисеп эш тәкъдим итте.

— Энем, — диде ул, — яңа оешкан Буа колхоз-совхоз театрына актерлар кирәк. «Галиябану»ны сәхнәләштерәләр. Син бит безнең шәп артист. Урнаш шунда эшкә. Алар тиз арада гастрольгә китәчәкләр...

Менәр як — атның сул ягы, камчылау як — атның уң ягы. Сайла, Барлас, бер якны. Йә театрга урнашасың да көн итәрлек җай табасың, йә сукбайлыкта йөрисең... Театрга керергә ризалаштым. Зөләйха апа театрның директоры һәм режиссеры Исхак абый Дасаев белән сөйләште, һәм мин иртәгесен үк сәхнә эшчесе һәм актер булып киттем. Нихәл итим? Талда кунар урыны юк кош сыман идем ич. Карыным белән кар ярып, борыным белән боз тишәргә дә риза идем.

Башкарырга тиешле ролем шул иде: Исмәгыйль Хәлилне аткач, йөгереп килеп җиткән ике кешенең берсе мин. Әйтер сүзем: «Бу ни хәл? Ни булды? Нишләделәр?»

Гастрольгә киттек. Квартирага карт актер Гали абзый Донской белән төшеп йөрдек. Котыш белән Тотыш сыман. Мин аның йомышчысы идем, ләкин ул, күпне күргән, күпне белә торган карт миңа да байтакны бирде.

Шулай башланган эш 1946 елның ноябреннән алып 1948 елның июленә кадәр дәвам итте.

Ике елга якын гомер эчендә дистәгә якын роль уйнадым. Ярата идем сәхнәне, хәзер дә ихластан яратам. (Үзешчәннәргә кушылып уйнарга бүген дә әзермен). Әмма укыйсы килү теләгем һәммәсеннән дә көчле иде. Өс-башны беркадәр рәткә-юньгә китергәч, кышлыкка азык-төлек алып куйгач, тәвәккәлләп унынчы класста укый башладым, 1948—49 уку елында урта мәктәпне тәмамлау турында аттестат алдым. Түбәм күккә тиде, тик... бу әле юлның башы гына иде. Югары белем аласы бик килә, мәгәр ничегрәк итеп яшәргә?

Фанер чемоданыма хезинәдә барын — запас бер пар күлмәк-ыштан һәм китапларны салып, Казанга юл тоттым. Исәбем вагон түбәсендә бару иде. Юлга бер тиенем дә юк иде. Ходайның рәхмәте дими ни дисең, тарихтан укытучым Гөлсем Галләм кызы Султиева очрады. (Ул — Янтуганныкы, әтиемнең дә, әниемнең дә укучысы). «Юлыңа акчаң бармы соң?» дип сорады. Бик кыенсынсам да турысын әйттем. Ул миңа егерме алты сум акча бирде. Нәкъ билетлык. Бу — мине поездга түгел, олы тормышка озату иде.

Иртәнге бишләр чамасы шикелле иде, Казанга килеп төштем. Барып сыеныр урыным бер генә — Щапов урамындагы тугызынчы йорттагы икенче квартира. Анда үзләренең биш баласы белән әти ягыннан кардәш Хәйдәр абый Камалов һәм Гашурә җиңги яши. Абый, туфрагы җиңел булсын, йомшак кеше иде. Шофер правасын алдырганнан соң тимер юл вокзалындагы посылкалар ташу бүлегендә каравыл торды.

Җиңги (без аңа «Гашурә апа» дип эндәшәбез) гомер буе авыр эштә булды, һиндидер снабта йөк төяде, йөк бушатты. Бик яхшы җөйче. Миңа, минем сеңелләремә генә дә күпме кием текте самими, ярдәмчел җан!

Гашурә апа мине гадәтенчә бик ачык каршылады. Кабул итү имтиханнарына килүемне белгәч (документларымны да шул көнне тапшырдым), «Үзебездә торырсың», — диде. Әй киң күңелле кеше дә соң!

Сулъяк Болак белән Мартын Межлаук (соңгы елларда шулай атала) урамнары кисешкән җирдә Казан дәүләт педагогия институтының төп бинасы урнашкан. Кабул итү комиссиясе дә шунда. Документларны тапшырдым. «Тулай торак кирәкме?» — ди директорның алгы бүлмәсендә утыручы зур гәүдәле, зур борынлы, бөдрә чәчле яһүд агай. Күзлек пыялалары артында зур ачылган күзләр. Кырыс, кискен.

— Кирәксә, әнә теге ишектән директор янына кереп, менә бу ордерга имза сырлатып чык... (Ул елларда ректор фәкать университетта гына булып, башка югары уку йортларының башлыклары директор дип йөртелә иде).

Керсәм... бар булдыгымны сөенеч басты. Зур кабинетта, «Т» хәрефе ясап сузылган зур өстәлләр түрендә Йосыф Әхмәтҗанович Туишев утыра. Ул бит Телеграф тыкрыгына урнашкан махсус урта мәктәпнең директоры иде, ә минем ул мәктәптә сигезенче классны тәмамлагач, бик аз гына укып алганым булды бит. Күз дигәнең йомшаграк булу аркасында Буага кайтып киткән идем.

— Уз әйдә, уз. Тулай тораккамы?

— Ул ордерны алырга кул сузды һәм мине исенә төшереп өлгерде.

— Махсус мәктәптә укып алган идеңме?

— Әйе, абый.

— Бөдрәләреңнән танытдым. Инде безгә, институтка килдеңме? Әйбәт булган. Карале, Камалов ялгышмасам, син круглый сирота бит, әйеме?

— Әйе, абый. Укытучы балаларыннан, әти-әниләре үлгән булса да, укыган өчен түләтмиләр, дигәч, монда килдем.

— Шуның өчен генәме?

— Соң укытучы һөнәре миңа бик якын инде ул.

Директор ордерга кул куйды һәм стена буендагы урындыкларны күрсәтте. Утыр дигәне. Үзе телефоннан шалтыратып, Бирюшев дигән берәүне чакырды. Тиз арада озын буйлы, кара тутлы бер абый килеп керде. Фронтовик булырга тиеш. Бер кулы гарибрәк.

— Менә, Рашат, безгә бер тырыш малай килә. Татар теле-әдәбияты бүлегенә. Мин аны дүрт-биш елдан бирле беләм. Спецшколадан. Ул шыр ятим. Хәзер дә менә бер тиене юк, иманым камил. Профкомда сөйләш, акчалата булышыгыз. Хәзер үк. Аннары мин үз фондымнан карармын. Беренче экзаменыңны биргәч тә минем яныма кер, Камалов, ярыймы?

Рашат абый Бирюшев институтның ВЛКСМ комитеты секретаре икән. Тарих факультетын тәмамлап, аспирантурага калган.

Йөз илле сум акча биреп, кул куйдырдылар. Бер кирпеч ипи сатып алып, Гашурә апаларга кайтканда, мин җирдәге җәннәтнең җиденче катында идем. Ник дигәндә, җавап анык: фитрәт көннәре — кризис кичерә идем ләбаса! Инде болай булгач, фәлән-фәсмәтән, катык-сөзмәдән дигәндәйләрне дә авыз итәргә мөмкин булачак!

Институтның беренче тулай торагында, Зур Кызыл урамындагы борынгы монастырьда яшәп, керү имтиханнары бирә башладым.

Беренче имтихан урыс әдәбиятыннан сочинение. Ике тема — дәресләрдә өйрәнгәннәрдән, берсе — ирекле. Бүгенгедәй хәтердә: «Я знаю город будет, я знаю саду цвесть» В.Маяковский».

Мин ирекле теманы сайладым. Буадагы М.Вахитов исемендәге урта мәктәпнең унынчы классын бергә тәмамлаган сабакташларым Мөхит Мөхәммәтҗанов, Даян Бикмуллин янәшәмдә, миннән күчермәкчеләр. Мөхит — бик көчле математик, ә сочинение аңа авыр бирелә.

Төп бинаның 67 нче аудиториясендә барлык факультетларга керүчеләр бергә язабыз. Иң арткы рәткә утырган идек, имтихан алучы Гыйльман Тимергалиевич Вәлитов, нидәндер шикләнеп, безне иң алгы рәткә күчереп утыртты. Бу аның тарафыннан чебенгә чукмар күтәрү иде инде. Без болай да куркып-имәнеп кенә тора идек.

Хәтер кайтавазы

«Һәй, чиркәү мәәзине!» — дип мыгырдандым, тик тыңламый хәлебез юк иде. Ядәчән киергән дә усал карап тора бит!

Иртәгесен урыс теле һәм әдәбиятыннан телдән имтихан тотканда сочинениене «хорошо»га язганымны белдем. Ике урында өтерләрне санга сукмаганмын икән. Әмма Вәлитов агай миннән канәгать икәнлеген яшереп тә тормады. Телдән җавапларыма «отл.» куйды.

Географиядән һәм немец теленнән шулай ук «хор.» булды. Ә татар теле-әдәбиятыннан язма һәм телдән имтиханнардан, әлбәттә инде, «отлично» булды. Монысына шигем юк иде.

Беренче имтиханнарны уңышлы тапшыргач, Йосыф абый Туишев янына кердем. Бу юлы приемныйдагы яһүд агай — Александр Абрамович Фрумин — әллә ни тоткарламады (без аны үзе артында Трумэн дип тә атый идек).

Йосыф абый директор фондыннан ике йөз сум(!) яздырып бирде. Рәхмәтем чиксез иде. Беренче стипендия көненә (имтиханнарны «удовл.»сыз тапшырып бетердем, «уд.» алсаң стипендия булмаячак иде), 22 сентябрьгә кадәр тамагым тук, күңелем көр булды. Үземне кеше итеп сиздем.

Күп еллар үткәч, Йосыф Әхмәтҗановичны соңгы юлга озатканда, минем, сакаллы сабыйның, кешеләрдән качып елавым да шуларны хәтерләп иде бит.

Имтиханнарда иң шүрләгәнем чит тел икәнлеген икърар итәргә тиешмен. Аны мәктәптә рәтләп укытмадылар. Шуның авыр йөге институтта да, аспирантурада да баш очымда кылыч булып асылынып торды. Тигәнәктән йон алуга, таштан юкә суюга тиң иде чит тел белән изалану!

Әйбәт кенә укып киттем. Мәгълүм бер горурлык белән расплый алам: дипломымның кушымтасында «зачтено» һәм «отлично» дигәннән башка билге юк. Бер генә «хор.» да алганым булмады.

Немец теле мине сырхауга саптыра язды. Институтның беренче-икенче курсларында бу фәннән безнең төркемне (ярты группаны) профессор Морозовның аерган хатыны укытты. Холкы юк иде. Бер минуттан ни кылырын, ни әйтерен белми тилмерә идек. Миңа имтиханда «отлично»ны да бик тә җаена торганга гына куйгандыр. Ә ул «алтын бишле» иде.

Мин икенче курста Горький исемендәге стипендия алдым (ул вакытта 450 сум акча иде әле). Өченче курста Сталин исемендәге стипендиягә тәкъдим итәчәкләре ачыкланды, әмма зачеткага бер генә «хорошо» да кермәскә тиешлеге шарт итеп куелды.

Җәмәгать эшләре җәһәтеннән җан тыныч иде. Беренче курста ук филология факультетының комсомол бюросы секретаре.

Икенче-өченче курста институтның ВЛКСМ комитеты әгъзасы (уку секторы), дүртенче курста һәм аспирантураның беренче елында институт комсомол оешмасы башлыгының урынбасары, аннары ВЛКСМ комитеты секретаре.

Өченче-дүртенче курсларда Сталин исемендәге стипендия алып уку миңа сеңлем Ралинаны (соңрак кече сеңелем Джемманы да) институтка китерергә, үзем яшәгән тулай торакка урнаштырырга җай бирде.

Педагогия институтында үткән чор минем өчен бик күп нәрсәләрнең бөрынлап китүе белән бәйле.

Беренче шигырьләр. Яшьлегендә шигырь язмаган кеше булмый, диләр. Хактыр. Мин иң-иң беренче шигыремне Буа районында ул чакта «Яңа юл» исеме белән чыккан газетада бастырдым. Май бәйрәменә багышланган иде шикелле. Һәрхәлдә, «Кулларында чәчәк бәйләме» дигән бер юлы һәм «бәйләме»нә рифмадаш булып килгән «бәйрәме» хәтердә.

Студент булгач, «Яшь сталинчы»да (хәзерге «Татарстан яшьләре»)

Сәфәре

Барлас КАМАЛОВ

бер-ике шигырем басылды. Монысы шагыйрь Сөхаб Урайский ярдәменә бәйләнгән. Шигырьләр, әлбәттә, Сталинга мәдхия җырлаучы юллардан тора иде.

Беренче хикәям. Ул да «Яшь сталинчы»да дөнья күрде. «Күңел газабы» дип аталган бу өйрәнчек әсәр дүртенче курста укыганда, 1953 елның 20 февралендә басылды. Аның газета сәхифәсенә кереп китүенә ул елларда үзе дә яшь язучы исәпләнгән Гариф Ахуновның булышлыгы тигәнен әйтү кирәк.

Журналистикага беренче адымымны да яшьләр газетасында ясадым. Студент чагында ук эшли башлаган булды, күрәсең, соңыннан радиожурналист Роберт Гатауллин миңа паркларның җәйге сезонны башлап җибәрергә хәзерлеге турында язарга задание бирде. Бүгенгедәй истә, башлап Үзәк паркка юнәлгән идем. Мәкалә чыкты. Шуны юл башы дип саныйм.

Аннан соң дистәләгән мәкаләләр бастырдым. Редакторлар Гали абый Хуҗи, Рашат Гайнанов, Рафакъ Тимергалин хуплап тордылар. Гали абый Хуҗи белән без нык дуслашып киттек. Мин аны, Риза ага Ишморат, Шәрәф абый Мөдәррис, Зәки абый Нури белән бергә, әдәби остазым дип саныйм. Һәммәсенең якты истәлеген гомерем азагынача күңел түремдә изге саклаячакмын.

Үземнән шагыйрь чыкмаячагын мин тиз аңладым. Тәнкыйтьче булырга ниятләдем. Бу өлкәдә мин Ибраһим абый Нуруллинга соклана идем (хәзер дә бик ихтирам итәм). Форсаттан файдаланып әйтим, ул — миңа бик булышкан зат. Берничә әсәремне укып. бәяләп, азмы-күпме яхшыртырга бик ярдәм итте.

Әдәби рецензияләр, тәнкыйть мәкаләләре язып карадым мин.

Институтны тәмамлагач, гыйльми совет мине татар әдәбияты буенча аспирантурага тәкъдим итте.Фәнни җитәкчем итеп Җамал Галиевна Вәзиеваны билгеләделәр. Кандидатлык минимумын ярыйсы гына тапшырдым, диссертациягә керештем. Темам «Мирхәйдәр Фәйзи драматургиясе» иде.

Диссертация язылды, ике кат кафедрада тикшерелде (кафедра мөдире Абдулла Җамалетдинович Сайганов иде), көзгә (1956) яклауга куелырга тиеш иде.

«Хәерчегә җил каршы, — дигәннәр. — Алдан булса — тезе туңа, арттан булса — оны туза». Партиянең XX съезды И.В.Сталинның шәхес культын пыран-заран китерде. Ә минем диссертациям, башка бик күпләрнеке шикелле, Сталинның әдәбиятка кагылышлы фикерләре, теге яки бу чорга, вакыйгаларга карата әйткәннәреннән цитаталар белән шыплап тутырылган, гомумән, сталинизм рухында язылган иде. Моны ул чор үзе таләп итә, ә фәнни җитәкче, муен тамырын төеп, шуны даулый иде. Диссертациянең бу варианты узмаячагы кояшлы иртәдәй ачык булып калды. Тупаруны белмәс хакыйкать шул иде.

Һәммәсенә кул селтәп, Буа районы газетасы редакциясенә эшкә кайтып киттем. Җитмәсә, ул елларда Казанда квартира мәсьәләсен хәл итү дә минем көчемнән килерлек түгел иде. Флюра инде, әнисе өендә яшәп, Луначарский исемендәге урта мәктәптә һәм Буа ветеринария техникумында укыта иде. 1954 елның 26 апрелендә туган Рөстәм әбисе кулында үсә иде (энесе Рәшит нәкъ биш елдан соң, 1959 елның 25 апрелендә дөньяга килде).

(Алгарак узып булса да әйтим: диссертация якланмаса да, тупланган материал, ясалган нәтиҗәләр, куелган көч бөтенләй үк әрәм булмады. Байтак гомер үткәч, 1987 елда Татарстан китап нәшриятында «Мирхәйдәр Фәйзи» дигән китап бастырып чыгардым).

Буа район газетасы редакциясендә баштарак — тәрҗемәче, аннары җаваплы секретарь булдым. Редактор урынбасары булып беркадәр эшләгәч,мине Казанга, «Татарстан яшьләре» газетасына редактор итеп күчерделәр. Мәскәүгә, ВЛКСМ Үзәк Комитетына әңгәмә-консультациягә, расланырга барып кайттым.

Буа белән җылы гына саубуллашырга туры килде. Партия райкомының беренче секретаре Георгий Федорович Мамаков саубуллашканда әйтте:

— Җибәрмәскә ни тырышып карадым, булмады. Яшьләр Салих Гыйлемханович Батыевка кергәннәр. Ул сине күчерергә вәгъдә биргән... Мин, Барлас, сине райкомга идеология буенча секретарь итеп алмакчы идем, — диде.

Ә минем, турысын әйтим, Казанга күчәсем бик-бик килә иде. Бу кала — әдәби мәркәзебез бит. Бөек Тукай әйткәнчә, «монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур». Мин исә язарга ныклап керешергә карар кылган идем.

Буада эшләгән чагында Татарстан китап нәшриятында беренче җыентыгым — «Гомер иткәндә» дигән тупланма дөнья күрде. Бу хәл, беренче улым тугандагы кебек үк, олы шатлык китерде.

Хикәяләр, повесть язуымны дәвам иттем. Төп хезмәттән һәм җәмәгать эшләреннән соң вакыт бик аз кала иде, югыйсә. Әмма яшь чакта аруны белмисең икән ул. Хәзер үзем дә гаҗәпләнгәләп алам, ничек өлгергәнмен? Комсомол райкомы бюросы әгъзасы, партия райкомы лекторы, татар һәм урыс драма түгәрәкләре җитәкчесе (үзем дә уйнап), район радиоузелында татарча тапшыруларны алып баручы редактор-диктор. Кичен эштән кайтканда, райком каршындагы квартирам янында ат яки машина көтеп торучан.

— Кайсы колхоздан? — дип белешәм дә, хәзер чыгам дип, тамак ялгарга кереп китәм. Аннары — колхозга, лекция укырга! Рәхмәт, халык күп җыела иде. Игътибар белән тыңлыйлар, сораулар күп була.

Буада эшләгән чорда гаять истәлекле бер вакыйга булды. Мин 1957 елда яшьләрнең һәм студентларның YI Бөтендөнья фестивалено бардым. Районнан дүртәү идек: ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Наил Зарипов, «Кыят» совхозы тракторчысы Виктор Цыганков, «Кызыл йолдыз» колхозы (Карлы авылы) сыер савучысы Гөлфия Мифтахова һәм мин.

Шушы грандиоз вакыйгада катнашу беренче тапкыр ил чикләрен атлап чыгуга тиң иде. Дөнья киңлеген тойгандай булдым.

Казанга күчеп эшли башлагач, җаваплылык күпкә артса да, мәшәкать бераз кимеде. Дөрес, монда да ВЛКСМ өлкә комитеты бюросы әгъзасы, әледән-әле эш куша торалар иде. ләкин районлагыча чабулыйсы түгел иде инде.

Бердәм, тату коллективта эшләдем дип әйтә алам. Нигездә. Ни өчен нигездә дим?

Комсомол Үзәк Комитетыннан расланып кайтып, эшкә керешкәч, (1959 елның 16 октябрендә «Татарстан яшьләре»н беренче мәртәбә кул куеп чыгардым), редакция хезмәткәрләренең һәммәсе диярлек берәм-берәм яныма кереп, сөйләшеп, зар түгеп чыктылар. Кечкенә генә коллективта да ике-өч төрле позициядә торучылар барлыгы сизелде.

Эшли башлавыма ун көн дигәндә коллективны җыеп алып, киңәшмә уздырдык. Бу чара миңа «Хөрмәтле кадерле хезмәттәшләр, минем янда күбегез булып чыкты. Һәркайсыгызны дикъкать белән тыңладым, аңларга тырыштым. Күңелемдә кырык сер тартмасы бар. Иләкнекен чиләккә бушатып йөри торган гадәтем юк. Илдәтнә адәм түгелмен, хәбәр ташымыйм. Сер итеп сөйләгәннәрегез миндә калыр. Инде болай килешик: һәр бәхәсле нәрсәне коллектив җыелышында тикшереп хәл кылырбыз. Читтә-чатта гәп куертулар булмасын», — дип әйтү өчен зарур иде.

Шулай булды да.

«Татарстан яшьләре»ндә эшләү миңа тормышны өйрәнү юлында күпне бирде. Яшь язучы буларак, бу чорда шактый бай материал тупладым, гыйбрәтле язмыш кешеләре белән аралаштым, халык тормышының пульсын тоярга өйрәнә төштем, теләсәм-теләмәсәм дә экономик мәсьәләләр белән кызыксынырга тиеш булдым. Беренче чиратта нефть дөньясына игътибар итәргә кирәк иде.

Диңгезче татар егете Әсгать Җиһаншин белән якыннан танышуыма да журналистлыгым сәбәпче.

Өлкән буын кешеләре яхшы хәтерли, 1960 ел башында кече сержант Әсгать Җиһаншин җитәкчелегендәге дүрт солдат, язмыш шаяруы аркасында, моторы сафтан чыккан баржада Тын океанда 49 көнлек дрейф кичерделәр. Азыксыз, сусыз... Аларны америкалылар коткарды. Туган илгә кайткач, егетләрне Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләделәр.

Ул вакытта космонавтлар галәмгә күтәрелмәгән иде әле, яшь солдатларның каһарманлыгы дөньяны шаулатты.

Океан гизәргә мәҗбүр булган егетләрнең (Филипп Поплавский, Анатолий Крючковский, Иван Федотов) башлыгы Әсгать Җиһаншинның Самара өлкәсендәге (ул чакта Куйбышев өлкәсе) Шентала район үзәгенә, әти-әнисе, туганнары янына ялга кайтасын белеп, без, берничә журналист, шул тарафка сәфәр чыктык. Төркемдә шагыйрь Илдар Юзеев, радиожурналист Карл Фәезов, «Комсомолец Татарии» хезмәткәре (ул бик оста фотокор да) Жан Миндубаев һәм мин идем. Океан батырына дип Муса Җәлилнең өч томлыгын алып бардым.

Төрле тарафлардан килүчеләр күп булса да, Җиһаншиннар өендә безне, Татарстан вәкилләрен, әйбәт каршыладылар. Солдатның әтисе Рәхимҗан абый да, әнисе Хәтимә апа да улларының исән кайтуына чиксез шат иделәр.

Беркадәр вакыт узгач, мин Әсгать белән Әлмәттә, яшь нефтьчеләр слетында күрештем.

Әсгать Җиһаншин белән янә дә очрашуыбыз комсомолның XIY съездында булды (16-20 апрель, 1962 ел). Егет ул вакытта Ломоносов шәһәрендә диңгезчеләр мәктәбендә укый һәм Ленинград өлкәсеннән делегат булып сайланган иде. Тәнәфесләрдә гел бергә сөйләшеп йөрдек, ә бер кичне ул без яшәгән «Варшава» кунакханәсенә килде...

Яшьләр газетасыннан мине «Социалистик Татарстан»га (хәзерге «Ватаным Татарстан») күчерделәр. Анда әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булдым. Баш редакторыбыз Шәмси Хәбибуллович Хамматов бик әйбәт кеше, әмма эшкә җигү дигәндә аяусыз иде, тын алырга да ирек бирмәде. «Миңа язучы кирәкми, журналист кирәк», дип кырт кискәне дә булды. Сиздем: монда эшләү озакка китсә, хушыгыз, хикәя һәм повестьлар! Роман язу хыялы да чәлпәрәмә киләчәк!

«Чаян» редакциясенә күчәсе иттем. Анда вакыт иркенрәк. Тик ничек диләр әле? «Ходай бүрегә ризык бирсә, тешен сындырып бирә», диләрме? Сатира-юмор әсәрләре язу минем өлешкә тигән көмеш түгел икән. Бер ел чамасы эшләгәч, ул чактагы баш редактор Әхмәт абый Исхак хозурына кердем.

— Булмый миннән монда эшләү, бушатыгыз, — дип гозерләдем.

Ул килеште.

Татарстан радиосында эшли башладым. Әүвәле пропаганда редакциясендә булдым, аннары иҗтимагый-сәяси тапшырулар буенча баш редактор иттеләр. Нәкъ бер ел эшләгәч (өстәвенә мин бит әле перевод белән килгән идем), радио һәм телевидение җитәкчесе Фаикъ Газизович Надыйровтан чираттагы ялга җибәрүен сорадым. Ул, кешеләр җитешми, кайсы сырхау, кайсы укуда, дип, отпуск бирмәде. Ә минем «Яшь имәннәр» повестен тәгәлләп, Татарстан китап нәшриятына тапшырасым бар иде.

Кат-кат сорагач та ял бирмәгәч, ундүрт ай эшләгәннән соң үз белдегем белән китеп бардым. Мәгәр бу миңа кыйммәткә төште. Партҗыелышта миңа каты шелтә «ябыштырдылар». «Яшь имәннәр» бер елга соңгарып чыкты.

1966 елның маеннан профессиональ язучымын. Дөрес, ара-тирә редакцияләрдә эшләп алам, радиода актив катнашам...

Пенсиягә кадәр һәм пенсиягә чыккач тырышулар заяга булмады. Бер-бер артлы «Яшьлеккә сәяхәт», «Күршеләр», «Күңел кыңгыраулары», «Ялыкмаслар», «Урамнар киңәя», «Язгы күкрәү», «Сарсаз кызы Сария», «Колокольчики души», «Канат яргандa», «Канатлы кырмыска», «Йөрәк давыллары», «Ярсөяр әрәмәсе», «Өметең өзелмәсен», «Язмыш сәхифәләре», «Уйлый күңел» китапларым дөнья күрде. Боларга өстәп, берничә очерк китабым чыгуын да әйтергә мөмкин.

Татарстан китап нәшриятында «Көмеш беләзек» дигән тупланмам кәгазь көтеп, нәшрият агайларының мәрхәмәтен көтеп ята. «Адашкан адәмнәр» повестеның китап варианты әзер.

Кызык өчен исәп-хисап белән шөгыльләнеп баккан идем, бу юлларга имза куйган көнгә 2 романым («Өметең өзелмәсен», «Җир күчәре»), 22 повестем, 188 хикәям бар икән. Очеркларым, китапларга, спектакльләргә рецензияләрем байтак.

Беренче хикәям басылганга кырык елдан артык вакыт узган да киткән. Еллар саны белән китаплар санын чагыштырсаң, һич мактанырлык түгел. Хәер хикмәт санда түгел, сыйфатта бит! Әсәрләремнең сыйфаты турында үзем авыз ача калсам, бу һичничек акланмаган минсенү булыр иде. Аларга бәя бирү әдәби җәмәгатьчелек һәм укучылар эше. Кырык ел буена ручка кысып тотып, бармакка сөял йоктыруның нәтиҗәсен шунда күрәм: сүз кыйммәтенә, әдәби сүз кадеренә төшенеп барам шикелле.

Сүз, туган телдә әйтелгән вә язылган сүз, тылсымга иядер ул. Сүз ана назыннан да ләззәтлерәк була ала. Шуның белән бергә, сүз дарыдан, бомбадан да хәвефлерәк. Шуңа күрә сүзләр белән үтә сак булу зарур. Сүзләргә карата түзем булу кирәк. Сүз белән үтереп тә, коткарып та була. Сүз белән хыянәт кылырга да мөмкин.

Изге сүзләрне — Ата-Ана, Ватан, Тугрылык, Азатлык, Намус сүзләрен адым саен тәкрарлап, арзанайтмаган хәерле. Байракны чехолда саклаган кебек, олы мөкатдәс сүзләрне күңел түрендә саклау — иң хәерлесе.

Язучы өчен сүз — бөек могҗиза. Сүздә мәгънә дә, хис тә, моң-көй дә, хәтта төс тә бергә тупланган...

Инде ни диярга кала?

Мактанып җиткермәгәнмен ләбаса! Миңа 1980 елның апрелендә — Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, ә 1992 елның августында Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре дигән исемнәр бирелде. Санга сугучыларга бик рәхмәт!

Бүгеннәрдә яңа әсәр язам. Килер көннәргә планнар да кечкенәдән түгел дә... әдәбият-сәнгать типкен хәлендә бит. Язганыңны бастырыр җай юк.

Без экономик фахишәлек баткаклыгында, рухи сазлыкта. Дөньяви ориентирларны җуйдык бугай. Тормыш мәгънәсе тойгысын югалттык шикелле. Әдәбият та «каралды». Сталинизмны сүгеп кереп киттек тә, сүкмәгән нәрсәбез аз калып бара бугай инде. Әхлак, намус, мәхәббәт, ышаныч, оят, вөҗдан, аяу-мәрхәмәт дигәннәргә кире кайту зарур.

Югыйсә бит халыкның башы бик түбән иелгән. Халык түзә. Бер анекдот торып-торып хәтердә яңара: кайсыдыр заводта баш адәм эшчеләрне сүгә, имеш. Сезне һичнинди чаралар белән куркытып булмый, иртәгә асабыз инде сезне, ди, янәсе. Шул чакта бер эшче кул күтәреп, рөхсәт алып кына сорый: «Аса торган бау казнаныкы буламы, әллә үзебезгә өйдән алып килү тиешме?» — ди, имеш... Менә без нинди маразмда. Ә бит тыныч заманда яшибез, дигән булабыз. Германияне Җиңүнең ярты гасырлык юбилеен бәйрәм иттек. Җиңүче хәерчеләр икәнебезне онытабызмы? Җиңелгән немец белән җиңелгән япон тормышы безнең кешеләрнең таң алды төшенә дә керми...

Менә иҗат әһеле булып яшә шул вазгыятьтә! Алып-сатарлар соң дәрәҗәдә азынган, дәүләтне күмәртәләп талаучылар койрык чәнчеп чапкан шартларда. Илдә чын хуҗа юк, чын хуҗа! Шуңа бик авыр...

Июнь, 1995 ел.
Казан.

БЕЗ НИЧЕК ТӘРБИЯЛӘНӘБЕЗ

ДӨНЬЯНЫ ӘХЛАК ТОТА



«Кешене киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар», дигән мәкаль бар. Мөгаен, дөрестер ул мәкаль. Әмма «акыл» төшенчәсендә төп урынны әхлак категориясе алуы бәхәссез. Чөнки кемнең кемлеге әхлаклылыгында күренә-беленә. Ул хәтта кечкенә нәрсәләрдә, вак-төякләрдә дә чагыла (исәнләшә белү, ягымлы елмаю, кеше сүзен бүлдерми тыңлау — шундыйлардан).

Күп кенә гадәтләр күләгә кебек гомер буе кешегә ияреп йөри. Әлбәттә, аерым очракларда «театр уйнарга» — үзеңнең чын йөзеңне яшерергә буладыр. Тик күпкә түгел. Шулай да була: «Бу кеше түрә булгач бөтенләй бозылды, кешене танымый башлады», — диләр. Моның белән килешеп булмый. Чөнки тиешле әхлак тәрбиясе алганнар болай итмәс. «Мин кем булдым», — дип масаймас. Мәсәлән, Норвегия короле өй хезмәтчесе тотмый, гади халыклар белән дә теләп аралаша икән, димәк, ул — тиешле дәрәҗәдә тәрбияле кеше. Швециянең элекке премьер-министры Улофф Пальмның эшкә йөри торган машинасы булмаган. Хатыны укытучы икән, ул аны үз машинасында эштән алып кайтып йөри торган булган. Һәркем йөри торган гади кинотеатрдан хатыны белән бергә кайтып килгәндә, аны атып та үтерделәр инде... Садри Максудиның «Англиягә сәяхәт» дигән китабында (Казан, 1914 ел) инглиз короленең дә искиткеч гади һәм итагатьле булуы турында языла. Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Шуны да хәтерлим: редакциядә эштән соң үзара шахмат уйнаган журналистларның кайберләре Мәскәүдә, Ленинградта Югары партия мәктәбен тәмамлап кайткач, партия өлкә комитеты аппаратында эшкә урнаштылар һәм... минем кебекләрне күрмәмешкә салына башладылар. Кая инде ул исәнләшү дигән гади генә нәрсәләр...

Тормыш шартлары әйбәт булганга, бүгенге яшьләр бозылды, дип сөйләүчеләр, уйлаучылар бар. Бу мантыйк-логика белән фикер йөртсәк, бөтен Аурупа илләрендә, Америка, Япония кебек җирләрдә гел генә бозыклар яши, дип уйларга туры килер иде. Безнең пропаганда «капитал илләрен» күпме генә карага буяп күрсәтергә тырышмасын, ул илләрдә халык тәртипле. Ә Русиядә моннан мең ел элек ничек булган, бүген дә шулай: егылып эчү, урлашу, кеше үтерү, йорт басу, ялганлашу һ.б. Иң үкенечлесе шул: күршеләргә ияреп, безнең халык арасында эчүчелек нык артты. Бөтен тәртипсезлек, әхлаксызлык нигезендә аракы дигән агуга табыну ята. Ирләр генә түгел, хатын-кызлар да эчә. Моннан 40-50 ел элек дөньядан киткәннәргә шул хәлне күрсәтсәң, алар шундук кире каберләренә кереп качарлар иде... Революциягә кадәр татар, гомумән, мөселман яшәгән авылга аракы, тәмәке кебек хәсисләр кермәгән. Гаиләләр ишле, тормыш авыр булса да, сау-сәламәт, иманлы яшьләр үскән. Ленинның әйтүенә караганда, революциягә кадәр урыслар белән чагыштырганда, татарларда мәктәпләр саны 10 мәртәбәгә артык булган. Татар эчмәгән, ул белем алган. Ә бит революциягә кадәр тормыш бүгенге белән чагыштырганда да нык авыр булган. Бүген ничек? Яңа туган балаларның кимендә 85 проценты авыру. Һәр зур авылда дебил балалар мәктәбе ачарга мөмкин. Мин үскәндә 500 хуҗалыклы авылыбызда авыру балалар туганын хәтерләмим. Ләкин әбинең: «Исереккә сәлам бирмә», — дигәнен яхшы хәтерлим...

Беркемгә дә сер түгел: һәр халыкның буыннан-буынга, гасырдан-гасырга күчеп килгән тәрбия традицияләре бар. Алар үзләренә күрә «тәрбия университеты» ролен уйныйлар. Шунысын да әйтик: халык традицияләре еш кына дини канунннарга нигезләнгән була. Кайбер Казан педагог-профессорлары моның киресен дәлилләргә маташсалар да, хакыйкать алардан өстен: татар тәрбия традицияләренең формалашуында Исламның роле гаять зур. Бәхетебезгә, ул — пакь, саф, гадел дин. Әнә шуны оныту (дөресрәге; көчләп оныттыру) безне бүгенге фаҗигаләргә китерде дә инде. Бу хак: Ходайга ышанган татар бервакытта да авызына шайтан суын — аракы-фәлән алмаган. Ислам дине баланы физик җәзага тартып тәрбияләүне тыйды (әлбәттә, моны бозучылар да булгандыр, анысы башка нәрсә). Әнкәй мәрхүмә әйтмешли, кыйналган баланың оят битлеге ертыла, ә оятсыздан теләсәң ни көтәргә була... Коръәндә ап-ачык әйтелгән: Ходай тәгалә иргә бүләк итеп хатын һәм балалар бирә, ул алар өчен Аллаһ алдында җаваплы. Балаларны — гөнаһсыз җаннарны — мәрхәмәтле алымнар белән тәрбияләргә кирәк... Мин бер генә халыкны да диннәренә, гореф-гадәтләренә карап хурламыйм. Әмма христиан диненең балага физик җәза биреп тәрбияләүне хуплавын әйтергә мәҗбүрмен. Ул болай дип аңлата: Адәм белән Хава-анамыз гөнаһ кылганнар, шуның өчен оҗмахтан куылганнар. Шуңа күрә Адәм балаларының һәммәсе дә, шул җөмләдән яңа туган балалар да, гөнаһлылар, имеш. Ә гөнаһны киметүнең юлы физик җәза икән. Шуңа таянып, инквизиция вакытында Аурупада 6 миллионнан артык кеше җәзалап үтерелгән. Әле дә Германиядә баласын кыйнап үтерүчеләр бар икән. Англия мәктәпләрендә (Американың кайбер штатларында да) укучыларны физик җәзага тарту каралган. Атаклы немец философы педагог-психолог И.Гербарт балаларны физик җәзага тарту өчен «штрафлар дәфтәре» төзегән. Урта гасырда Аурупа мәктәпләрендә: «малайларның колагы — аркаларында» дигән тәгъбир йөргән, һәм аз гына гаеп өчен дә малайларны бик нык кыйный торган булганнар. Ләкин ни генә булмасын, үз методлары белән балаларына әйбәт тәрбия бирә алганнар. Ә менә Кытайда, Япониядә балалар культы яши...



Бу да «Америка» ачу түгел: кеше шәхесен формалаштыруда хезмәт тәрбиясенең роле бик зур. Кайчак ул роль хәлиткеч була. Аурупада, бигрәк тә Швеция, Норвегия мәктәпләрендә кыз балалар өй эшләренә, бала тәрбияләү алымнарына өйрәнеп, имтихан тоталар. Ир балалар слесарь, монтер, балта остасы һөнәренә өйрәнәләр. Ә безнекеләрнең күбесе — стенага чөй генә дә кага белми. Англиядә 12 яшьлек фермер малае комбайн белән икмәк ура. Инглиз хатыннары үзләре бәйләгән кофта, свитерларны яратып киярләр. Дөньяның барлык кыйтгаларында да балалар эшкә өйрәнеп үсә. Минемчә, эш белү һәм акы үтәргә омтылу — һәртөрле дипломнардан, фәнни дәрәҗәләрдән, исемнәрдән өстен тора. Иң бәхетсез кеше — эш белмәгән кеше. Ни өчен бүгенге ата-ана әнә шул бик гади генә хакыйкатьне аңларга теләмидер, әйтүе кыен...

Япониядә, Кытайда, Һиндстанда, гарәп илләрендә хатын аеру да, бала кыйнау да юк. Аурупа илләрендә, Америкада халыкның уртача гомере — 75-77 ел, Япониядә берничә елга күбрәк. Ә бездә — ирләрнең гомере — 54-56, хатыннарның — 60-62 ел. Тулаем алганда, бу да әхлаксызлыкка, эчүчелеккә барып тоташа. Күптән түгел Казанда чыга торган бер урыс газетасында: Малые Клыки (Питрәч районы) дигән авылда бер ир заты да юк, һәммәсе дә эчеп үләп беткәннәр, дип язылган иде...

Димәк, бүгенге тәрбия эшенең иң актуаль бурычы булып эчкечелеккә каршы актив көрәшү тора. Чит илләрдә дә күп эчәләр, дип сөйләнүләр — ялган, аракы ясау белән шөгыльләнүче оешмалар акчасына алып барыла торган пычрак пропаганда гына. Мәсьәлә бер төрле генә тора: яки аракы эчеп халык юкка чыга яки без эчүчелеккә юлны ябарга тиеш.

Тәрбия эшен кайчан башларга, һәм нәрсә ул тәрбия дигән сорау беренче карашка гына гади булып тоела. Педагогика фәненең хәзергә кадәр, нәрсә ул тәрбия, дигән сорауга өзеп кенә җавап бирә алганы юк. Моңа иң беренче чиратта «совет педагогикасы» дигән сәясәтләштерелгән фән гаепле. «Совет педагогикасы» (әйтерсең лә, педагогика формацияләргә, җәмгыять төзелешенә карап төзелә!) үзенең төп бурычы итеп «коммунистик җәмгыять кешесен тәрбияләүне» куйды. Моның нигезендә илдә бары тик бер халыкны — урысларны гына калдырып, башкаларны бетерү, ассимиляцияләү телəге торды. Бу, чыннан да, шулай булып чыкты. 50 ел эчендә СССР дип аталган урыс империясендә яшәүче 194 халыкның-милләтнең 93 е юкка чыкты. Берничә дистә елдан башка милләтләр дә бетәргә тиеш иде. Бу — фараз итү түгел, бәлки, чынбарлык. Н.С.Хрущев, партия мөнбәреннән торып, коммунизмга тизрәк күчүнең бер төп алшарты — бөтен илнең урыс телендә сөйләшүе, эш йөртүе, дип игълан итте. Ә без, тизрәк шул коммунизм оҗмахына кереп, эшләми генә рәхәт яшәргә ашыктык.

Бөек гуманистларның, мәсәлән, Я.А.Коменский, К.Д.Ушинский һ.б. фикере буенча, тәрбия бик иртә башланырга, милли характерда гына булырга тиеш. Бу һәр халык үз балаларын, яшьләрен үз халкы традицияләрендә тәрбияләргә, тәрбия эше ана телендә алып барылырга тиеш дигәнне аңлата. Тел бетү белән халык та бетә, ди К.Д.Ушинский. Совет власте елларында 40 дистәгә якын милләтнең-халыкның бетүе әнә шуның аркасында булды. Милли мәктәпләр урынын, милли балалар бакчаларын да урыс укыту-тәрбия йолалары алыштырды. Чөнки милли тәрбия милли үзаңны үстерүгә дә нык хезмәт итә. Шовинист җитәкчеләргә бу һич тә ошамады. Манкорт дип йөртелүчеләрдә милли үзаң дигән нәрсәнең тамчысы да юк. Алар ата-ана теленә, гадәтләренә битараф кына түгел, аңа каршы актив дошман булып чыгыш ясыйлар. Татарстан Югары Советында әнә шундыйлар шактый иде, һәм алар татар теле, татар мәктәбенең үсешенә теш-тырнаклары белән каршы тордылар. Милли тәрбиянең булмавы шуңа китерде: миллионнарча динсез, денсез, әхлаксызлар үсте. Шулар аркасында кичләрен урамнарда йөрү куркынычка әйләнде. Әти-әнисе, баба-әбисенең пенсиясен талап эчүчеләр саны ишәйде. Һәм моңа беркем дә түгел, без үзебез, безнең җәмгыять гаепле. «Сыйнфый, коммунистик тәрбия»нең үкенечле нәтиҗәсе бу.

Татар халкында ата-ананы, гомумән, олкәннәрне хөрмәт итү — борынгыдан килгән гадәт. Моның мәгънәсе шунда: бала өлкәннәрдән үрнәк ала, аларның сүзен йөрәге белән кабул итә. Халыкның тәрбия традицияләре халык авыз иҗатында: мәкальләрдә, табышмак, әйтем, бәетләрдә, җырларда, хикәятләрдә, әкият-дастаннарда, кыйссаларда һ.б. саклана. Ләкин тәрҗемә итә башласаң, күпләренең мәгънәләре юкка чыга. Димәк, аларны ана телендә генә сөйләргә кирәк икән. Мин үзем газиз әнкәм сөйләгән-көйләгән кыйссаларны, бәетләрне тыңлап үстем, еш кына «балавыз да сыктым». Менә шуларның кайберләре. «Сак-Сок» бәетенең эчтәлеге бик гади, әмма мәгънәсе гаҗәеп тирән: ике улының үзара ызгышуына түзә алмаган ана, бер-берегезне күрмәс хәлгә килегез, дип, аларны каргый. Шуны әйтүе була, ике малай, кошка әверелеп, тәрәзә аша очып чыгып китә. Икесе тауның ике ягында бер-берсен күрә алмыйча, «Сак», «Сок» дип эндәшәләр. Ире кайткач, хатыны аңа булган хәлне сөйләп бирә. Һәм Аллаһыга ялвара, мин гаепле, балаларымны элекке хәленә кайтар, дип үтенә. Әмма бу очракта Ходай тәгалә көчсез булып чыга. Нәтиҗә: бала өчен ана Аллаһтан да өстен җан иясе икән! (Монда бәлки тагын бер нюанс бардыр: юк кына нәрсә өчен дә баланы каргарга ашыкмаска кирәк...) Бераз тыйнаксызлык булса да, әйтим инде, без әнкәйнең 4 улы һәм бер кызы, аны тирән хөрмәт иттек, бервакытта да сүзеннән чыкмадык... Бервакыт әнкәй Сөләйман пәйгамбәр турында мондый кыйсса сөйләгән иде: чит илләрдә озак еллар патшалык итеп, Сөләйман пәйгамбәр баеган һәм әтисен күрергә дип туган-үскән җиренә кайткан. Һәм ниндидер сәбәп аркасында, әтисен ат өстендә килеш кенә сәламләгән. Бу шулкадәр зур гөнаһ булган ки, Ходай тәгалә пәйгамбәр кадәр пәйгамбәрне дә ярлыкамаган. Барлык башка пәйгамбәрләрдән аермалы буларак, үлгәч кабердә Сөләйманның гәүдәсе черегән. Димәк, бала өчен әти дә бөек зат икән! Һәм без, чыннан да, әткәйне дә нык хөрмәт иттек... Бәлки кайберәүләр, бу мисаллар примитив һәм бүгенге заман балалары өчен бармый, дияр. Минемчә, яшенә карап бик бара. Моны тәҗрибә күрсәтә... Шул да хәтердә сакланган: кичке ашны ашап бетергәч, әнкәй казаннан җылы су алып һәммә савыт-сабаны юа һәм корытып сөртә, үзе болай ди иде: савыт-сабаны бервакытта да юмыйча калдырырга ярамый. Югыйсә, пычрак савытларны, канатларын талдырып, фәрештәләр каплап торачак. Ә бу — зур гөнаһ, ди. Эшләре беткәч әнкәй битен юа, авызын кат-кат чайкый, югыйсә, шайтан үбәр, ди иде.



Элегрәк өлкәннәр бервакытта да балалары алдында «сер» чишмәгәннәр. Шулай булмаганда балаларның бозыласын белгәннәр. Бүген кайбер гаиләләрдә шул нәрсә җитми, өстәвенә: «Гаиләдә кем баш?» — дигән бәхәсләр дә була. Бу бәхәс мәгънәсез. Чөнки баш булу җаваплылыктан башка берни дә бирми. Хатыннарга мондый киңәш бирү урынлы булмас микән: бервакытта да гаилә башлыгы булырга омтылмагыз. Кайбер хәйләкәр ирләр, бурычны өсләреннән төшерү өчен, лидерлыкны хатыннарына тапшырырга тырышалар, юклы-барлы акчаларын кайтарып бирәләр дә, бүтән сорама, теләсәң нишлә, диләр. Юк инде, күршеләр әйтмешли, так не пойдет. Син ир икәнсең, тырыш, гаиләңне тәэмин ит. Кайбер хатыннар «властьны үз кулына алгач», улларын да шул рухта тәрбиялиләр. Бервакыт ике хатын сөйләшә, берсе икенчесенә болай ди: «Көч-хәл белән улымны ВУЗ бетерттердем. Моңа бик күп көч куйдым. Хәзер өйләндерергә вакыт җитте. Иремә әйтми акча җыйган идем, ике бүлмәле кооператив фатир өчен түләдем. Дөнья көтәрдәй уңган татар кызы табасы иде. Улымнан рәт чыкмас. Юньсез. Ипи генә дә кисеп караганы юк. Ходаем, ярдәмеңнән ташлама...»

Бер зур галим җәмгыятьнең хәлиткеч тоткасы икәү: җитештерү сферасы һәм нәселне дәвам иттерүче механизм, дигән. Ул хаклы. Ә нәселне дәвам иттерү ул — бала табу гына түгел, иң элек һәркемне җәмгыятьнең тулы канлы әгъзасы итеп формалаштыру, бәхетле гаиләләрдә бәхетле балалар үстерү дә. Һәммә кеше шуңа омтылырга, үз өстенә төшкән изге бурычын үтәргә әзер булырга тиеш.

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ,
галим-педагог.

Марат ӘМИРХАНОВ

Шерше ля фа

Шаян хикәя

Француз дусларның җиһанны гизгән бу әйтемен бөтен инсаният белә. Аны тәрҗемә итеп тә торасы юк, Шерше ля фа, бәтте-китте вәссәләм! Син җир шарының кайсы яртысына барып чыксаң да аңлыйлар, димәк ки, бу үз өлешенә тигән кәмешен эзли икән, диләр.

Бу миңа да турыдан-туры кагыла, җәмәгать. Ник дисәң, мин дә язмышыма тигән гүзәлемне эзлим. Күптән эзлим инде. Яшермим, тапкан чакларым да булгалады. Менә соңгысын гына алып карыйк. Әминә исемле иде. Чибәр иде, каһәр. Йөзе әле генә мичтән алынган күмәч кебек түм-түгәрәк, йомшак, кайнар. Ул атлаулары! Янбашларын ян-якка уйнаткалап үтеп киткәндә, егыл да үл инде. Биләнә колачым чак-чак җитә иде. Такташ, әйтерсең лә, үзенең мәшһүр шигырен минем Әминәмә багышлап чыгарган. Туры килсә дә килер икән.

Шәп кәләш иде Әминә. Характерлар гына туры килмәде, мәхәббәтебез кабынганчы ук сүнде. Пример, мин үзем беренче урынга ярдәмчеллекне куям. Шундый зат инде мин, мохтаҗлар яныннан битараф кына узып китә алмыйм. Әминә шушы сыйфатымны килештереп бетермәде, ахры. Шулай бервакыт, танышуыбызга атна-ун көннәр узгач, мәгъшукамны паркка чакырдым: әйдә, мәйтәм, бераз культуралы ял итеп алыйк әле, мәйтәм, кешеләрне карыйк, үзебезне күрсәтик.

Йөрибез, малай, паркта падручкым, бөтенесенең күзе бездә. Әһә, мәйтәм, пар килгәнбез икән. Шунда, гөнаһ шомлыгына, кечкенә кызчыгын җитәкләгән бер анага күз төште бит. Туңдырма сатучы янында туктадылар болар. Түзмәдем, йөгереп бардым да, яшь әнинең кулыннан әләктереп алдым. Нишлисез, мәйтәм, балагызга ангина була ич. Билгеле, әйткәнемне ошатмады ханым, сезнең ни эшегез бар анда, дип, китеп барды. Икенчесе шулай ук борынын җыерды. Анысына: сумкагызны җилкәгезгә асмагыз, умыртка сөягегез зәгыйфьләнер, дигән идем. Беренигә карамый өченче ханымга да зәмичәни ясарга туры килде. Бәй, аякларында асларыннан песи баласы үтәрдәй ифрат та биек үкчәле туфлиләр. Таеп китсә, шарт сына бит аягы.

Мин шулай кешеләрне акылга өйрәтеп йөргәндә Әминәкәй дә сызган иде. Алай да хатын эзләүдән ваз кичмәдем, җәмәгать. Беренче генә түгел лә. Гәҗитләргә мин биргән игъланнарны җыйсаң, бер китап чыгарырлык булыр иде: «Буем 152 сантиметр, утыз алты тешем дә исән, сукыр эчәгедән кала, бар әгъзаларым да урынында, укымышлы, тәртипле...»

Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска, дип дөрес әйткәннәр, аңламадылар минем саф омтылышларымны. Берсе хәтта язып ук җибәрде. Үзеңне әүлия итеп күрсәтмәкче буласың, ышандылар, ди, кәт, дип сырлаган иде ул.

Вәйт кызык, ә? Аллаһы тәгалә шулай идиальни итеп яраткач, нишлим соң инде. Ләкин дә уйландырды бу хат мине. Туктале, мәйтәм, кызык итим әле мин боларны. Һәм тоттым да гәҗиткә әр-яңа игълан юлладым. Анда түбәндәге сүзләр бар иде: «Азып-тузып йөрүче 40 яшьлек әлкәш үзенә тиң эзли. Йорт-җирләрегезне, 20-30 ел җыйган байлыкларыгызны бер-ике атнада җилгә очырырга вәгъдә бирәм. Күз төпләрегездән күк китмәс, кулым каты, ә йөрәгем — мүк».

Җавап көтә башладым, ун, егерме көн көтәм, юк кына бит, каһәр, шәфкатьлелек күрсәтүче. Их, мәйтәм, сезгә тегеләй дә, болай да ярап булмый икән, мәйтәм, ачуымны китерсәгез, буфшым да уеннан чыгармын, иң яхшы кандидатурадан колак кагарсыз, мәйтәм. Ләкин, һич көтмәгәндә, дөньяның тәрәзәсе бөтенләй башка яктан ачылды бит, җәмәгать. Шерше ля фа баскычын кемдер астын өскә әйләндерде дә куйды. Башта ышанмадым, мәйтәм, саташам, ахры, уянып җитмәгәнмендер, дип уйлыйм. Чөнки барысы да әле генә күргән төшкә бәйләнеп китте, кайсы төш, кайсы өн икәнен тәгаенләрлек тә түгел.

Имеш, ниндидер яман зат мине ком чүленә китереп ташлаган. Кызу, чыдар әмәл юк, эчәсе килә. Тирә-якта зәһәр еланнар башларын сузган. Ходаем, нинди гөнаһларым өчен җәзалыйсың, аерган хатыннарым өчен булса, тәүбә-тәүбә, җайларга тырышып карармын. Тик ни... алар хәтсез, ә мөселман кешегә Үзең дүртне генә фарыз кылгансың, дим.

Догаларым барып иреште, күрәсең, алдымда гүзәл дәрья хасил булды. Тирә-ягымда җимеш агачлары. Шунда ук хур кызларыдай көттә туташлар хозурланып йөриләр.

— Чибәр егет, нинди җилләр ташлады сине монда? — дип сорады берсе.

— Шерше ля фа, — дидем мин.

— Шерше ля фа?

— Әйе, гүзәлкәй, әйе, — дип тегенең кулларына үрелдем. Инде тоттым гына дигәндә әермә купмасынмы. Бөтен дөнья ком бураны эчендә калды. Кычкырам, имеш, теге хур кызын эзлим...

Уянып китсәм, кулымда телефон трубкасы, кем беләндер сөйләшәм.

— Мьсе, Әбелмәлих, рәхмәт, комплемент яхшы, мин сезнең белән очрайт келим.

— Ә-ә, бу синмени, гүзәлкәем, — дим, — буран... мин сине югалттым.

— Мин Патрисия, мьсе, Әбелмәлих, мадьмазель, монда йөрим сәяхәт, мин укыдым игълан, мин сезнең белән очрайт келим.

Ниһаять, йокы исереклегеннән арындым: игълан буенча француз кәләше шалтырата лабаса! Патрисия! Исеме үк ягымлы, каһәр. Безнең чукмар борынлы Әминәләр түгел инде ул мадьмазельләр. Франция! Париж!

Тик игъланның кайсы вариантын укыды икән? Хәер, соңгысы буенча шалтыратып та маташмас иде.

— Мин көтәм җавап, мьсе, — дип гөрелдәде чыбыкның теге очындагы күгәрчен.

Ул җавап көтә. Ә минем күзләр бүлмәне айкый. Стенадагы обой да кубыштырган икән, дим, ул шөрә идәнгә палас-мазар җәйгәндә шулай ук ярап куяр иде. Нишләп әле шкафның ишеге купты икән?

Шатлыгым тоныклана төште, аны соң, Патрисияне, мәйтәм, өйгә китерергә тиеш булам түгелме? Мин икеләнеп торган арада:

— Мин киләм иртәгә, кәт, — дип Патрисия мәсьәләне хәл итте дә куйды. Һәм нәкъ вакытында ишек уемында пәйда да булды бу.

Ышанасызмы-юкмы, аны күрергә, сүз куәмне югалтып, тораташ булып каттым, җәмәгать. Мин үз гомеремдә бик күп хатын-кыз күрдем, кәнишне, күбесе үземне кире какты, бәгъзеләрен, ихтимал, үзем дә ошатып җиткермәгәнмендер. Ләкин дә ишек бусагасында басып торучы мондый карачкыга беренче юлыгуым иде. Үзе озын, үзе килбәтсез, борыны сихерче карчыгыныкы шикелле кәкре, ни алды, ни арты дигәндәй, нәкъ пәри калтырчасы. Җитмәсә, елмайган була, тешләренең атныкы кадәре икәнен белми.

— Минеке килде, әссәламегаләйкем, — дип Патрисия миңа какча кулын сузды.

— Гафу итегез, — дидем мин, — мин... ни... кире уйладым... миңа беркем дә кирәкми...

Патрисия минем сүзләргә колак та салмады, бүлмә эченә үк үтте.

— Мин күз алдына китердем шулай, мин риза! — ди.

— Мин әлкәш, мин зверь, — дип ырылдыйм моңа, — мин башкисәр, у-у-х!

Әлеге сүзләрдән соң Патрисия үкчәсен күтәрергә тиеш иде. Ә аның болай да зур авызы фәкать колакларына кадәр җәелде генә.

— Мин беләм, мьсе, ир шундый миңа кирәк. Мин укыдым игълан.

— Укыдың? Соңгысынмы?

— Әйе, мьсе, Әбелмәлих, сезнең ошый экземпляр, сез ничек начар, шулай миңа яхшы. Бер ир мөселманны иттем ант төзәтергә. Безнең җәмгыять шөгыльләнә шәфкатьлелек... Без дус кызым белән чыгарга әлкәшләргә кияүгә булдык.

— Французыңа чык! — дим моңа.

— Юк бездә әлкәшләр сезнең кебек. Килдек монда. Өйрәндем тел махсус шуңа күрә, — дип авызыма каплмасынмы мадьмазель.

Менә шулай, җәмәгать, үзебезнекеләргә үч итеп язган игълан мине Патрисия кочагына ташлады. Инде яшәп ятабыз. Эчәргә сабыштым. Ул төзәтә, ә мин нигәдер төзәлмим. Мөгаен, тагын Шерше ля фагадыр.

Танылганны тану кыенмы?

Аны, бәлки, күпләр ишетеп-күреп беләдер. Сәхнәдән сөйләсә — тамашачылар тыела алмыйча көләләр, ди. Әбиләр һәм бабайлар, апалар һәм абзыйлар, энекәшләр-сеңелләр, өлкәннәр һәм балалар — телевидение аша чыгышларын көтеп алалар икән. Хәер, телевидение дигәннән, бу кешедә телепатия дигән гаҗәеп бер көч тә бар, дип сөйлиләр. Тик менә шунысы... Фотохәбәрче аны сәхнәдә вакытта төшереп алган да, исемен язарга онытткан. Ә без менә хәзер сәхнә остасын таный алмый аптырыйбыз. Әгәр дә сез безгә аның кем икәнен әйтеп хат язсагыз, сезне бүләк — китап көтә. Ә инде бүләкнең иясен ачыклау — тану-танымаудан һәм безгә юлланган җавап хатның иртәрәк җибәрелүеннән тора!

Касыйм ТӘХАУ

Башка нинди уй килмәс...

Заман болгавыр — авыр бу чакта
Ләкин...
Өмет уты да кала учакта.

* * *

Доносчы белән әләкче — икесе бер,
Әләктән кеше башы китә Себер.

* * *

Караклык инә урлаудан башлана,
Инә урлаган — атка ташлана.

* * *

Мәкерлененең тырнагы — кармактыр,
Тырнакның хуҗасы — бармактыр...

* * *

Тәкәбберненең борыны югары,
Берни дә күрми борыныннан ары.

* * *

Хатын да, мин дә нәчәлник —
аякка бастык.
Өйдә — икебезгә киң бер ястык.
Аякка бастык, ястыктан качтык —
Икебез ике фирма ачтык...

* * *

Саранның саранлыгы — йөзендә,
«Юк»тан башка булмас сүзендә.

* * *

Ябалак-ябалак кар төшсә —
җил исмәс,
Карт ябалакның моңа исе китмәс.

* * *

Егәрең җитмәсә — ярышма,
Көч-куәтең булса — калышма.

* * *

Бүре уласа, бар эт койрык кыса,
Болдыр астына ук кереп поса.

* * *

Начар гадәтеңне куалама —
Кеше олешен даулама.

* * *

Гаугалы өйнең нигезе авыш,
Авыш нигез теләсәң — җәнҗал белән кавыш.

ПАР(О!)ДӘЯ

Нияз АКМАЛ

Нигә гел яз түгел икән җирдә?
Нигә кырыс кыш
Күңеле нечкә иргә?

Әхмәт РӘШИТОВ.

Аңлау кирәк күңеле нечкәләрнең максатын —
Яшәр идек кыш көне дә кар сатып, —
Нигә гел кыш түгел икән Җирдә?
Тагын ни кирәк инде бездәй иргә?
Тимәгез әле нечкә җиргә!..

Давыл

Гурий ТАВЛИН

Романнан өзек

Язучы Гурий Тавлин Казан ханлыгының вәхшиләрчә тар-мар ителүе турында «ҺӘЛАКӘТ» исемле тарихи роман төгәлләде. Сезнең игътибарга шул әсәрдән бер өзек тәкъдим итәбез.

Казанлыларның беренче һөҗүменнән соң яшь патша Иван Васильевич татарларны буйсындыруның җиңел булмаячагын тойды һәм шәһәрне яуларга ныклы хәзерлек чаралары күрүне тиеш тапты. Беренче чиратта Сакчы полк башлыклары Дмитрий Микулинский белән Дмитрий Плещеевка Болакның уң ягына үрмәләр куярга боерды. Боерык кичекмәстән тормышка ашырыла башлады. Урыс укчылары, Болакны кичеп, бистә коймалары буенда чокырлар казырга керештеләр. Алар казыган чокырлар казанлыларның калаларыннан чыгып һөҗүмгә ташлануларына комачаулаячак иде.

Гаскәрнең Уң кул полкына Казансу елгасының аръягына урнашырга кушылса да, ул әле анда күчәргә өлгермәгән иде. Патша аңа елганың уң ягына, шәһәрдән бераз көнчыгыштарак төпләнергә әмер бирде. Әлеге полкта унсигез мең кеше бар, шуларның унике меңе — җайдак, калганнары җәяүлеләр иде. Шул ук көнне Юртоулга да Арча кырыннан Казансу елгасы аръягына күчәргә кушылды.

Беренче орыш урыслар өчен дә җиңел булмады. Күпләр һәлак булды, җәрәхәтләнүчеләр дә аз түгел иде. Гаскәр башлыкларыннан Дмитрий Хилков белән Юрий Шемякин яраланды. Полкларның күченүләре ашыгыч барды. Алар саклык чаралары күрүне онытгылар.

Үрмәләр куючы егет — тиргә юешләнеп беткән бүреге астыннан чегәнneke кебек кара бөдрә чәчләре чыгып торган көлөч йөзле Яшка Пух сирәк сары сакаллы иптәше Петька Босойга:

— Шәрә маңгайларның кичәге һөҗүме безнең кенәзләргә акыл өстәмәде шикелле, — диде.

Чытык чырайлы Босой гаҗәпләнде.

— Ник алай дисең?

— Аларның кичәге һөҗүмнәрен бүген дә кабатлавы мөмкин бит.

— Ахмак булсалар, кабатларлар. Кичәге бәрелештән соң аларның безгә яңадан борыннарын гына да күрсәтүләренә ышанмыйм мин.

— Алай димә, татарлар куркуның ни икәнен белмиләр. Менә әйтте диярсең, безгә алар кыслаларның кайда кышлаганын төшендерерләр әле.

Урысларның Казан өстенә яу йөрүләрен Алла хупламый, күрәсең. Алар урта Иделдәге бу горур ханлыкны тез чүктерергә инде ничә килеп, һәр килүләрендә бер рәт тә чыгара алмыйча, кире кайтып киттеләр. Кыш көне дә, көз көне дә килеп карадылар, әмма уңышка ирешмәделәр. Инде менә максатларын тормышка ашырырга җөен килделәр. Ләкин бусында да авызлары пешәр күк. Кышын алар юлга чыкса, яздагы шикелле җылыта, көзен килсәләр, ишеп яңгырлар коя, җир өсте тоташ сазлыкка әверелә, һөҗүмгә, орышка күтәрелү турында уйларлык та булмый иде. Ахырда, урыслар мөселман Казанына ничек интегә-интегә килсәләр, табигать көйсезлегенә нәфрәтләнеп, Казан кальгасы тирәсендә берничә көн сүгенә-сүгенә таптанып торгач, ник килүләренә үкенеп бетә алмый, тәртәләрен кайту ягына боралар иде. Менә бусында да татарларны акылга өйрәтер өчен яуга кузгалырга гына өлгерделәр, Кырым ханы Дәүләтгәрәйнең төрек янычарлары белән бергә Туланы камаганы турында хәбәр алдылар. Аларга, юлларында бүленеп, Дәүләтгәрәй белән очрашырга, башта аны тар-мар итәргә туры килде. Аннары Мәскәү белән Казан арасындагы мукшы сазлыкларын, билгесез карурманнарны үткәндә юлсызлыктан җәфаландылар, ачлыктан интектеләр, аларны мазасызлар өчен юри яуган кебек көнаралаш койган яңгырларда күшектеләр, авыр тупларын аркаларына күтәреп, арып-талчыгып, черки, кигәвен, бөгәлҗән кебек канэчкеч бөҗәкләр талавыннан бимазаландылар. Шундый тәмуг газапларына тиң җәфалануларны кичерә-кичерә килүләренең ни мәгънәсе бар иде урысларга? Алар бу походларын Казанга изге ният белән, янәсе, татарлар кулындагы алтмыш мең урыс тоткынын азат итү сылтавы белән оештырдылар. Дөресендә максат ул түгел, ә башбирмәс Казан ханлыгын тез чүктерү, буйсындыру иде. Моңа комачаулаучы киртәләр, тоткарлыклар, бетмәс-төкәнмәс каршылыклар, бәлаләр инде барысы да артта калмаганнар, урысларны яңа күңелсезлекләр, элеккеләреннән күпкә кыенрык та, хәтәррәк тә яңа бәхетсезлекләр, кичерелгәннәреннән дә дәһшәтлерәк, хәтта уйга да кертә алмаслык коточкыч афәт көткән булып чыкты.

Искәрмәстән акыл ирешмәслек һәлакәт китергән хафалы 25 август төне унтугыз яшьлек урыс патшасының да, хәрби эштә тәҗрибәләре зур карт, шулай ук тәҗрибәсез яшь гаскәр башлыкларының да, Казанны буйсындырырга килгән урыс сугышчыларының да күңелләренә онытылмаслык булып уелды.

Һава ул көнне көндез чамасыз бөркү булды. Кич кергәч Сакчы һәм Сул кул полкларындагы укчылар Болак инешенең аръягына чыгып үрмәләр куйдылар, кала мөшләре итәкләрендә чокырлар казырга керештеләр. Кала читендә Болак тамагыннан ерак түгел казанлыларның Таһир мунчасы дип дан тоткан зур таш мунчалары бар иде. Урыс укчыларның бер төркеме шул мунчага урнашты. Болак буена үрмәләр куелып беткәч, алар артына моңарчы алларында ышыкланыр нәрсәләре булмаган туплар урнаштырылды. Туплар, үрмәләр артында ышыклангач, Казан өстенә бер-бер артлы утлы җәдрәләр төкерергә керештеләр. Уң кул полк Казансу елгасының аргы ягында, каладан бераз арырак, Арча кырына күчерелде. Юртоул полкы исә Арча кырыннан Кабан күле буена кайтарылды. Урынын алыштырганда ул полкка казанлылар кинәт каладан һөҗүм оештырдылар һәм каты ук бәрелеш булып алды. Күченүчеләргә алгы полк ярдәмгә килгәч кенә кала хуҗалары тагын шактый кешеләрен югалтып, кальгалары эченә чигенделәр. Урыслар өчен ярыйсы ук күңелле һәм уңышлы үткән бу көннең куанычын төнлә юлында очраган бөтен нәрсәләрне ватып-җимереп тар-мар иткән коточкыч гарасат чәлпәрәмә китерде.

Яшь урыс патшасы үзе дә, гаскәр башлыклары да, көндезге мәшәкатьләрдә арыган-алҗыган сугышчылар да, кичке эңгер иңгәч, кыска гына гыйбадәттән соң ашарга утырдылар. Шулчак төньяктан кинәт кенә бик көчле салкын җил исәргә тотынды, һәм күктә инде саран гына җемелдәшә башлаган беренче йолдызларны Казансу елгасы аръягындагы урманнар өстендә пәйда булган авыр кара болытлар каплады, күзләрне камаштырып, утлы чыбыркыларга охшап, елык-елык яшеннәр яшьнәде, йөзләгән туплар берьюлы гөрселдәгән шикелле, бөтен әйләнә-тирәне тетрәтеп, берөзлексез күк күкрәде. Салкын җил отыры көчәйгәннән-көчәеп, өермәле давылга әверелде. Аннары, кинәт, гүя, күкнең төбе тишелде, чиләкләп бозлы яңгыр коярга кереште. Өермә олуг кенәзнең, шулай ук күпчелек гаскәр башлыкларының утакларын җиргә ныгыткан казыклары-ниләре белән бергә кубарып, дәһшәтле яшен чыбыркылары телгәләгән вәсвәсәле юеш караңгылыкка чөйде. Кинәт кенә башланган рәхимсез давылдан һәм бозлы яңгырдан тотрыксыз утак-чатырларда ышыкланырга мәҗбүр булган сугышчылар котырынган өермә иркендә чиләкләп койган салкын яңгыр кочагында калдылар. Көчле җилдә кемнәрнеңдер Алладан ярдәм сорап ялварулары, кемнәрнеңдер кара төнне, каһәрле язмышларын, мәрхәмәтсез давылны, аяусыз яңгырны, Казанны, каргалган язмышларын ләгънәтләп сүгүләре, сыкранулары, кемнәрнеңдер авыр ыңгырашулары — барысы бергә буталды. Давыл һич туктамастай котыра, сөякләренәчә шөбәрешеп күшеккән кешеләрне бөтенләй шәрә калдырырга теләгән шикелле, соңгы җеп бөртекләренәчә юеш киемнәрен йолыккалый, аяктан егарга тырышкандай тарткалый. Янәшәдә Иделнең ярларыннан чыгып, бөтен тирә-юньне астында калдырырга җыенгандай ярсулы шаулавы ишетелә.

Яшен чыбыркы-чытырманнары яктысында олуг кенәзнең куркудан танымаслык булып бозылган чырае, бөтен буена юеш монах киеме сыланган килбәтсез чандыр гәүдәсе күренеп алды. Аннары аның карлыккан тавыш белән:

— Якында кем бар?.. Бу шашкан гарасаттан, зинһар, аралагыз минә!.. — дип инәлгәне ишетелде.

— Монда, минем янга кил, олуг кенәз, татарлар өстебезгә чакырган бу шайтани вәсвәсәдән бергә ышыкланырбыз, — дип чакырды аны, давыл һәм яңгыр шавын басып, кенәз Михайло Воротынскийның калын тавышы. — Федул, Иван Васильевичка булыш безнең утакка керергә...

Давыл шашынганда тик Зур полк башлыгы Михайло Воротынскийның һәм тагын берничә гаскәр башлыгының утаклары төн куенына очмыйча урыннарында калдылар. Иләмсез салкын җил-яңгырда чыланып туңудан тешләре тешкә тими калтыранган патша үз полкының башлыгы янында ышык һәм чагыштырмача тыныч урынга юлыкты.

Урыс явы төне буе котырынган давылда керфек тә какмады. Табигатьнең ачы шуклыгын кем ничек булдыра алса, шулай кичерде. Өермә кузгалгач, яшен чыбыркылары елкылдаудан һәм дөньяның асты өскә килгәндәй дөбер-шатыр күк күкрәүләрдән шашынып, нишләргә, кая барырга белми арлы-бирле чабышкан атларга тапталып йөзләрчә кеше һәлак булды.

Таңга таба шашынган давыл да, чиләкләп койган бозлы яңгыр да тынды. Офык читеннән табигать көйсезләнүенә оялган төсле кыюсыз гына кояш чыкты. Иртән Казансу һәм Идел буйлары канкоешлы яу кырын хәтерләттеләр. Бөтен әйләнә-тирәне өермә вакытында үлгән урыс сугышчыларының мәетләре, ат үләксәләре каплаган иде. Чәчләрне үрә торгызырлык күңелсез күренеш иде бу. Давыл бөтен көймәләрне җимереп батырган, су астына китмәгәннәрен йомычкага әверелдергән, салларны таратып агызган, алардагы хәрби кирәк-яракларны, гаскәр өчен китерелгән бөтен азык-төлекне Иделдәге балыкларга аш иткән булып чыкты.

Көтелмәгән төнге гарасат урысларны шулай үтә кыен хәлгә куйды. Яшь патша олуг кенәз Иван Васильевич Казан ханлыгын эссе табада биетер өчен оештырган бу килүенең дә уңышсызлыкка очрау ихтималын бөтен барлыгы белән тойды. Ул үзен, бу хәлдән каушап калмаска, дип кисәтеп, дьяк Иван Выродковка Зөядәге бөтен азык запасын кичекмәстән Казанга китерүне оештырырга боерды.

Олуг кенәзне татарларның туган йортларын саклап ныклы каршылык күрсәтергә җыенулары Казан тирәсенә аяк басуларының беренче көнендә үк сагайткан иде. Истә-санда юкта давыл каян килеп чыкты тагын, дип аптырады ул. Казанны яулау сугышларының озакка сузылуы безнең файдага булмас, аның воеводаларда да, сугышчыларда да ризасызлык тудырачагы көн кебек. Дошманнарым, мине патшалыгымда өнәмәүчеләр болай да аз түгел. Гаскәр башлыклары арасында сугышның озакка сузылачагына пошынып, Казанны теге тапкырлардагыча алмыйча, авыз күтәреп, Мәскәүгә кайтып китәргә димләүчеләр һичшиксез табылыр. Әнә кенәз Андрей Курбский бүген иртән, уң кулының баш бармагы белән ияген кашый-кашый, Казанга карап:

— Җәй үтеп китте, алда көз, озакламас кыш та килер. Безнең кайтыр юлыбыз озын. Минемчә, татарларның бирелергә исәпләре юк, Иван Васильевич. Гаскәр азык-төлексез калды — бөтен туемлыкларыбызны давыл ашады. Хәзер миндә, турысын әйтәм, Казанны тез чүктерә алуыбызга өмет киселде. Мәскәүгә кайту сәфәренә чыгу турында кайгырта башларга вакыт түгелме икән инде? — диде төнге фаҗигагә шатлангандай.

Аңа:

— Ачыгу ихтималыннан һәм тәнрәсез татарлардан котың алынган икән, тотмыйм сине, кенәз, кайтып кит Мәскәүгә, юлыңа ак җәймә! — дип бик дөрес җавап бирдем.

Төнге фаҗига минем ихтыяр көчемне сындыргандыр, дип уйлап, кенәз Курбский ялгышты, нык ялгышты. Акланырга, мине янә түбәнсетергә тырышты ул.

— Мине куркаклыкта гаепләвең урынсыз, патша. Туланы хәтерлә, анда кырымлылар белән төрек янычарларын тар-мар иткәндә алган яраларым төзәлмәгән әле. Мин аларны шара сукканда алмадым. Бер генә кеше дә Андрей Курбский куян йөрәк димәс...

Үзе турында югары фикердә ул хәсрәт Алеша Попович, аңа телен тешләтү зыян итмәячәк.

— Куркак булмагач, нигә Казанны тез чүктермичә, мине Мәскәүгә кайтып китәргә димлисең? Патшаның иреннәрендәге сөт яңа кибеп килә, ачлыкка һәм кыенлыкларга ул түзмәс, буйсыныр дисеңме?

— Аллам сакласын, Иван Васильевич! Синең турыда алай уйлау — җинаять.

— Соң?

— Мин, гаскәр түзә алмас, дим.

— Гаскәр өчен башыңны авырттырма, кенәз. Бел, гадел һәм кодрәтле күк патшабыз Тәңре хәзрәтләре вөҗдансыз татарлардан үч алыр өчен килгән христиан гаскәрләрен мәрхәмәтеннән мәхрүм итмәс.

— Мин аңламыйм, бүген төнлә Тәңре безне мөселманнар белән бутады микән әллә, гөнаһ шомлыгы?..

— Тәңренең безнең ныклыгыбызны, аңа тугрылыгыбызны сынавы дим мин төнге гарасатны. Тәңрегә сүз тидергәнең өчен телең корсын, еретик. Бар хәзер үк утак-чиркәүгә кереп күз яшьләрең белән Ходайдан ярлыкау сора!..

Иван Васильевич бу сүзләрдән юга-

...ән воеводасы янынан, ...җиренгәндәй кырт борылып, ...ды.

...Курбский патшаның эре ады... ...ән үзеннән ераклашкан... ...ашкан төз гәүдәсенә карап, ...әрниче ел гына элек думный ...з кубызларына биеткән ма... ...иде үзе дә калмаган, авызы... ...амый ачсаң, сине кан түке... ...т тә тор икән, диде күңелен...

...е аштан соң патша иркен ...гаскәр башлыкларын җыярга ...ың утагын, көн яктыра баш... ...н болын түреннән табып, ...рынына инде яңадан корган...

...кенәз, гадәтенчә, кара монах ...тәнге дәһшәттән соң һаман ...ына алмаганга, поход төхе... ...кайнар күмерләр тутырыл... ...бүлы зур тимер савыт куй... ...иде. Утак артында көрәктәй ...н күк нык укчы озын көпшә ...р савытның төбенә тоташ... ...уртача зурлыктагы күрекне ...басып утлы күмерләрне сү... ...ерләтә иде. Патша, төхеткә ...гаскәр башлыкларының төнге ...ән соң һәркайсының нәрсә ...амаларга ниятләп бирәм-бе... ...н кичерә башлады. Әнә Олуг ...лыкларының берсе җирән ...зур кызыл борынлы, сабыр ...беркайчан да ашыга-каба... ...ыучы кенәз Михайло Воро... ...Гаскәр әллә туемлыкларсыз ...әллә юк, иртән торып кала ...урнашкан укчыларының ни... ...лар куюларын барлап кайт... ...тәҗрибәле башлык, тыйнак, ...шикелле масаючан түгел, ...ыл вакытында булган кадәр ...ктән, сугыш кирәк-яракла... ...мәхрүм калды, хәзер безгә ...айтып китү кулайрак булыр, ...башына да кертми булыр. ...кның икенче җитәкчесе ил... ...дә өске ягына чыккан, әмма ...чә хәрәкәтчән, почык борын... ...ы чатан кенәз Иван Федоро... ...славский да өметсезләнми ...ике башлыкның фикерләре ...к, әйтерсең, алар бер-берлә... ...айчан да каршы килмәскә ...анар. Дөрес, Мстиславский ...к холыклы, шулай да полкны ...дә үзеннән биш-алты яшькә ...уйлап эш итүчән сабыр пары ...кийга нәрсәдә дә булса кар... ...е, үзен өстен куярга тырыш... ...елми. Килгән казага иң шат... ...еше, мөгаен, туганнан тумыш ...димир Андреевич Старицкий... ...бүген минем бөтен гаскәрне ...алып кайтуымны, Мәскәүдә ...миңа каршы баш күтәрүен ...ннән Аллага туктаусыз ял... ...р. Минем урыныма төхеткә ...хыялланып төннәр йокла... ...өсте төш күреп йөри ул. Кара ...ы күзләремнән укымасын, ...ттән инде миңа туры карага... ...хеткә утыру, аңа, үз колак... ...рә алмаган күк үк, насыйп ...Алла кушса. Мәскәүдә мин ...нә оештырмасын дип, аны ...теп килдем. Әйдә, туемлык... ...нле Иделгә батуы мөхтәбәр ...р Андреевичның күперенкә ...бераз шиңдерергә ярап ку... ...олк башлыклары Иван Про... ...ән Дмитрий Хилков үзара ...емилэр. Кенәз Иван Про... ...рей Курбский кебек үк, нә... ...рынгыдан ук абруйлылыгы... ...ә Хилковка нәселенең боры... ...елме икәне сукыр бер тиен. ...ы оештыручы, оста стратег. ...ялкау, авырлыклар алдын... ...н төшә. Хилков аның кап... ...ы. Кичә ул каладан чыккан ...гайлар белән орышканда ...кулының тәзәлүен кәтеп ят... ...н бәйләтеп кулын муенына ...ән тупларны дошман укла... ...ыклар өчен ашыгычлык бе... ...ыкларыннан үрелгән кур... ...га туфрак һәм ком тутыр... ...е. Баһадир гәүдәле кенәз ...ыю да, тәвәккәл дә. Әмма ...фатларын күпертергә яра... ...салымы белән дә гади су... ...ан аз аерыла. Пронский ...тостеге йон-каурыйларын ...ан купшы әтәчкә охшый. ...ызыл, ыштаны кара, күн ...елән башындагы бүреге са... ...дагы шарфы ак, бияләйлә... ...нде сакалы агарып килә, ...ән һаман ташламый. Монда ...юк, кем алдында купшыла... ...лай, аңламассың. Гадәт ...холык, диләр, дөрестер ул. ...е алган ярасы өчен тәңре... ...рдән үч алмый моннан ки...

тәргә риза булмас. Пронский исә алны-артны карамый Казан тиресен ташлап китү ягында булырга тиеш. Уң кул полкның икенче башлыгы кенәз Курбскийның пары кенәз Петр Щеняттьев та Андрей Михайлович җырын җырлар. Иртән аның җимерек борынлы, сирәк сакаллы ябык чырае сүрән, сагаюлы иде. Сакчы полк башлыклары Василий Серебряный белән Семен Шереметевка казанлыларның этлекләре яхшы таныш. Алар аны Зөя каласы воеводалары булгач үз җилкәләрендә татыганнар. Икесе дә чын христианнар, үзләрен Тәңренең тугрылыклы коллары исәплиләр. Урта яшьләрдәге бу кенәзләр — уйлап эш итә торган ышанычлы кешеләр. Үз полкымдагы гаскәр башлыклары Владимир Воротынский белән Иван Шереметевның икесенең дә үз фикерләре юк, башлары бүрек киярге генә ярый. Бу минем өчен әйбәт. Сүзен сүз итәргә чәчрәп торган үҗәтләрне яратмыйм мин. Үз полкым башлыклары өчен мин тыныч. Алар инде өлкән яшьтә булсалар да, киңәш башлангач шөрә калып утак уртасына чыгып биергә кушсам, һичкемнән тартынмый пох-пох килеп чүгә-чүгә биячәкләр. Моңа кадәр өч тапкыр Казан патшасы булган, кыяфәтендә үк ач күсе чалымнары кычкырып торган Шаһгали хан җил кайсы якка көчлерәк өрсә, тишекләре өскә тырпайган җәлпәк борынын, дуңгызныкы күк кечкенә оятсыз күзләрен, табак шикелле котсыз түгәрәк шадра чыраен шул якка бора. Аңа Казанны камап тору ни, яңа бичәсе чибәр Сөембикә янына кайту ни. Ул сатлыкка нәрсә әйтсәң, ләббәйкә дип шуны үтәячәк. Нарядлар (артиллерия) хуҗасы кенәз Михайло Морозов, алып килгән дарының күбесен Идел йотса да, Казанны тез чүктерми кайтып китүне башына китерергә дә куркадыр. Моннан киткән тәкъдирдә аңа бөтен тупларны — зурларын да, кечкенәләрен дә, алар, Аллага шөкер, берничә дистә генә түгел, йөз илле данә, ашыгыч тәстә кайту юлына хәзерлисе була. Кайтырга ашык-пошык чыгу кенәз Михайло Яковлевич шикелле тәҗрибәле нарядчы эше түгел. Юртоул башлыклары Федор Троекуров белән Юрий Шемякин гаскәр җыенының кыенлыкларын үз җилкәләрендә татыган бәндәләр. Аларның Мәскәүдән монда килгәндә Мещера сазлыкларында һәм мукшы урманнарында туемлыклар кытлыгыннан үзләре дә, кешеләре дә нык интектеләр, диделәр. Әмма аларның үзләреннән ул турыда зарланганнарын ишетмәдем. Төнге казага да алар, минем күк үк, ул Тәңренең безне сынавы булды, дип карыйлардыр, шөт...

Утагына гаскәр башлыклары җыелып беткәч, патша аларның үзенә тугрылыкларын сынарга булды.

— Казанны камауны төгәлләүне,

аны алуны, ханлыкны тар-мар итүне мин мөгълүмегез Шаһгали патшага йөкләргә булдым, — диде ул сагышлы кыяфәт белән. — Яныма сезне шуны белдерергә чакырдым. Сезне алда мин җитәкләмәм, Шаһгали патша җитәкләр...

Утак эчендә кабер тынлыгы урнашты. Воеводалар аптырашып бер-берләренә караштылар. Аларның барысының да күз алдына каратут шадра йөзле, зур яфраклары өрекмән яфрагыдай тырпайган, такыр башына алтын чигүле затлы кара келәпүш кигән, кап корсаклы, кыска камыт аяклы Шаһгали хан килде.

Тынлыкны алыптай гәүдәле кенәз Федор Троекуров бозды. Ул ашыкмый гына урыныннан калкып:

— Башкалар ничектер, мин синең сүзләреңне аңламадым, Иван Васильевич, ачуланма, — диде тамагын кырып. — Уйнарга түгел, дошманыбызны тәмам тар-мар итү сугышына килдек ич без монда, вөҗдансыз татарлар кулындагы тоткын туганнарыбызны коллыктан аралау сугышына. Ә син безне тәңресез Шаһгали патша кулына тапшырырга булгансың. Казанга килергә чыгар алдыннан чиркәүдә сөйләгән сүзләреңне инде оныттың, күрәсең. Эшме бу? Безне син үзең җитәкләмәсәң, Юртоулны җитәкләүдән баш тартам мин.

— Мин дә, — дип кушылды аңа кенәз Юрий Шемякин.

Бүтән воеводалар да олуг кенәзнең җитәкчелекне үз өстеннән төшерүенә каршы килделәр.

— Безне монда син китердең, син үк сугыштыр. Без Шаһгали патша кул астына күчүгә каршы, — диде кенәз Михайло Воротынский сүзне ары дәвам итәргә урын калдырмаслык итеп.

Патша каш астыннан саран гына елмаеп, кулларын күкрәгенә куйды.

— Ярар, сүземне кире алам, сезне Шаһгали патша кулына бирмим, — диде җыерылган кашлары астыннан үткен күзләре белән янә утакны айкап. — Үзегезгә мәгълүм, төнге гарасат безне ач калдырды. Татарларны җиңү хәзер икеләтә кыенлашты. Бәлки Казанны камауны төгәлләп, безгә Мәскәүгә кайтып китәргәдер? Кем ничек уйлый, әйтегез, тартынмагыз.

— Үз фикеремне мин әйтеп карыйм, Иван Васильевич, хаксыз булсам, төзәтерсең. — Кара бөдрә сакаллы, утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге кенәз Александр Горбатый урыныннан калыкты. — Без хәзер Казан янында. Монда килергә авыр һәм озын юл үттек. Дошман каласын әле юньләп камап та бетермәдек, башкарасы эшләребезне — татарларны тар-мар итеп, урыс тоткыннарын — кан кардәшләребезне азат итмичә Мәскәүгә кайтып китү, минемчә, үз-үзебезгә хыянәт итү булыр. Без бу килүебездә дә казанлыларга сабак укытмый кайтып китсәк, алар элеккедән дә ныграк оятсызланырлар. Мин башлаган эшебезне ахырына җиткерми туктамау ягында.

— Ә менә кенәз Андрей Курбский синеңчә уйламый, Александр Васильевич. Чәнчелсен Казан, кайтыйк Мәскәүгә, туемлыкларыбызның барысын да Идел йотты, инде эшебез харап, ди. Монда ачка үлүдән курка...

— Кайтасы килгән кешене тотма, Иван Васильевич, кайтсын. Кенәз Андрей Михайловичның, чыннан да, ачтан аяк сузуы бар, ул — нәзберек адәм. Андый үзе турында гына уйлый торган бәндәнең арабызда булуыннан булмавы хәерле.

Патша усал елмайды.

— Ишеттеңме, Андрей Михайлович?!

Курбский, кызарып, урыныннан сикереп торды.

— Син мине дөрес, аңламадың, галиҗәнап. Мин монда соңгы тамчы канымача хыянәтчел казанлылар белән сугышырга килдем һәм сугышырмын да. Ә, кенәз Александр Васильевич, без синең белән ахырдан, чебиләрне көзен санаганда сөйләшербез. Ул чакта синең үлчәү тәлинкәң басармы, минекеме, күренер...

Патша утактагы башлыкларны тагын күздән кичерде.

— Йә, тагын кем үз сүзен әйтә?

Кенәз Василий Серебряный, башындагы биек бүреген салып, хәлле җиңе белән тирләгән маңгаен сөртте дә хатын-кызныкы сыман чәрелдек тавыш белән:

— Казанны буйсындырмый Мәскәүгә кайтмыйбыз. Безне Казан күзгә кергән чүп шикелле өзлексез борчый, татарларның оятсызлыгына чик куярга күптән вакыт. Моннан тагын берни майтармый кайтып китсәк, мин дә тоткынлыктагы кардәшләребезгә хыянәт итү булыр дим.

Кенәз Серебряный сүзен төгәлләгәч, патша янәшәсендә утырган туганнан тума агасы Владимир Андреевич Старицкийга утактагыларның барысы да ишетерлек итеп:

— Гаскәр башлыклары кенәз Курбскийны якласалар, мин төхеттән ваз кичеп, монастырьга китәрмен дигән карарга килгән идем. Ходайга шөкер, үзең күрдең, воеводалар, татарларны тынычлыкта калдырып Мәскәүгә кайтмаска, дип дөрес эшләделәр. Мин монда күп итеп азык-төлек җибәрергә һәм шуның өстенә өстәмә туемлыклар юнәтергә казнадан акча сорап Мәскәүгә чапкын җибәрдем. Озакламый Зөядән салларга һәм көймәләргә азык-төлек, шулай ук сугыш кирәк-яраклары төяп дьяк Иван Выродков белән Шаһгали патша да кайтып җитәрләр. Давыл зур каза китерсә дә, баш исән бит әле, аңа бүрекне ничек тә табарбыз, мөхтәрәм воеводалар. Хәзер үк сез үз полкларыгызга кайтып сугышчыларыгызның күңелләрен күтәрегез, аларны дошманны аяусыз кыйнарга дәртләндерерлек вәгазьләр сөйләгез. Безнең эшебез хак, без тәңресез татарларны һичшиксез җиңәрбез, Зөядән азык-төлек килеп җитә, кичкә сезне туйганчы ашатырбыз, диегез. Барыгызга да игелекле Алла ярдәмчегез булсын, дигән изге теләктә калам мин. Хәзер, сез киткәч, Тәңренең безгә рәхим-шәфкать күрсәтүен үтенергә утак-чиркәүгә керәм, — дип олуг кенәз төхетеннән торды.

Давыл татарларны да читләтеп узмады. Тик аларга ул китергән зыян урысларны дучар иткән белән чагыштырганда йөзнең бер өлеше генә иде. Бистәдәге бер мәчетнең манарасын яшен сугып аударган, дүрт кеше шул манара ватыклары астында калган, котырынган җил Черек күл ярында үскән бөтен карт агачларны аударган, калкурак җирләрдә утырган кырыклап өйне түбәсез калдырган, Төмән капкасы өстен ишеп төшергән, Арча кырындагы урманнарга яшеренгән Япанчы бәкнең утыз меңле бәктермәсен дә аямаган — йөзләп атны һәм алтмышлап кешене агачлар баскан иде.

Казанлылар давылдан соң иртән хан болынында урысларның утаклары бик нык сирәкләнгәнне, сугышчыларының тыз-быз чабышып кешеләр һәм атлар мәетләрен җыеп йөрүләрен күреп, кяферләр Казанны тагын ташлап китәргә җыеналар бугай, дип куаныштылар. Давылның урысларга коточкыч каза китергәнен алар кала һәм бистә мөшләреннән күзәттеләр. Иртән хан болынында урыслар лагеренда бер генә учак та тергезелмәде. Ә башка көннәрдә анда алар бихисап төтиләр, болында эшлекле җанлылык хөкем сөрә иде.

— Төнге гарасат кяферләрне шөп дуылдатканга охшый. Ул безнең файдага булган, Аллаһы тәгалә безнең аһардан ярдәм соравыбызга колак салган, кикрикләрен шиңдергән мәлгуньнәрнең, шекер, — диде үзалдына сөйләгәндәй Хан капкасы башлыгы Бикчура морза.

— Хәзер бердәм күтәрелеп чыксак, ярты сәгать эчендә аларны кырып бетерәбез бит, ник чыкмыйбыз, нәрсә көтәбез? — дип мөрәҗәгать итте аңа йөз башы Бознак оглан.

— Килешәм, син хаклы, оглан. Ләкин чирләне кыйнаганны кайда һәм кайчан күргәнең бар синең? Кяферләр бүген шул чирле хәлендә. Үҗәтлекләре, кайнарлыклары әнә җилгә очкан. Аларны дөмектерергә бер генә ук та өрем итерлек түгел. Ажгырып торган үзеңә тиң дошманны тәпәләү генә кызык. Монда күп тукрамый кайтып китәрләр төсле алар. Кайтып китсәләр, безнең дә, аларның да каны коелмас. Сугыш безгә түгел, аларга кирәк иде бит.

— Анысы шулай, тик ничектер яңадан Казанга юлны онытырлык итәсе иде аларны...

Бу вакытта Казан олуглары хан сараена җыйналганнар, аларга да урысларга килгән бәхетсезлек сер түгел иде инде.

— Форсаттан файдаланып безгә кяферләрне тар-мар итү хәзер берни түгел. Аны кулыбыздан ычкындырмаска кирәк, — диде Чапкын морза. — Кукылы борын яшь урыс патшасын Казан төшенә керсә, кара тиргә батып калтыранып уянырлык итәргә.

— Егылганны түбәләү килешерме икән безгә, Аталык морза? Гаделлек булмас бу. Дошманга килгән казадан файдаланып яуланган җиңү без мөселманнарны бизәмәс, дим мин. Сиңа теше-тырнагы белән каршы торган дошманны тар-мар итү кызык, ә бәладән мәлҗерәгән дошманны тукмау мөселмәт шөгыль булмас. Килешәсезме минем белән? Кемдә башка фикер бар? — дип залдагыларга карады Ядкәр хан.

— Хак сүзгә берни өстәп булмый, галиҗәнап. Төшендердең, син хаклы. Намусыбызга хыянәт, мөселманлыгыбызга хилафлык итмибез, — дип хуплады аны Зәйнеш карачы.

Салават күпере ясаучы Әлфия

Рәссамнарның борынгы сәнгать үрнәкләренә мөрәҗәгать итүе — табигый. Узган гасырларның мәдәни мирасын өйрәнеп, аны заман рухы һәм йөрәк хисе белән оретеп, яшь рәссам Әлфия Ильясова безгә кабатланмас сәнгать үрнәкләре бүләк итә.

Әлфия 1983—87 нче елларда Казан сәнгать училищесында белем ала, 90 нчы еллар башында Мәскәү иҗат йортларында сыналу үтә. Яшь рәссамны 1992 елда — Татарстан, ә 1993 елда Русия Рәссамнар берлегенә әгъза итеп алалар.

Нәкъ менә шул елларда яшь рәссамның иҗат йолдызы кабына: ул Татарстан һәм Русиядә оештырылган «Яшь рәссамнар күргәзмәсе», «Зур Идел» (Казан), графика жанрында эшләгән рәссамнарның Владимир шәһәрендә үткән Бөтенроссия күргәзмәсендә, Мәскәүдә 16 республика рәссамнары катнашында узган «Арт-миф» һәм С.-Петербургта үткәрелгән «Тат-арт» кебек югары дәрәҗәле күргәзмәләрдә катнаша. 1994—95 нче елларда Казанда һәм Чаллыда үткәрелгән күргәзмәләрдә дә Әлфиянең урыны түрдән булды.

Узган ел «Туран» фонды аның шәхси күргәзмәсен оештырган иде, тамашачы рәссамның әсәрләрен яратып карады. Озакламый Әлфия Голландиянең Зутфен шәһәрендә, Татарстанның танылган рәссамнары Е.Голубцов, И.Гыйmранов, И.Хәсәнов һ.б.лар белән бергә, зур халыкара күргәзмәдә катнашачак.

Рәссамның халык арасында танылуының бер билгесе — ул язган картиналарның үтемле булуы. Әлфиянең шактый эшләре Татарстан сынлы сәнгать музее, «Туран» фонды һәм «Казан» милли-мәдәни үзәге тарафыннан сатып алынды.

Әлфия Ильясова йолдызының сәнгать күгендә капылт кабынып китүе очраклы хәл түгел. Монда Әлфиянең абзыйсы — танылган рәссам Р.Килдебәков һәм аның хатыны — гобелен остасы М.Килдебәкованың йогынтысы шиксез. 1960—1970 нче елларда ук инде Р.Килдебәков иҗатында борынгы формаларга нигезләнеп образлар иҗат итү осталыгы, палитрасында җете, фантастик төсләр куллануга омтылыш ярылып ята иде. Рәссамнар гаиләсендә, киндер һәм буяулар дөньясында тәрбияләнгән Әлфия, үз иҗатында бу сыйфатларны сендереп кенә калмады, аларны үстерде һәм тирәнәйтте дә.

Җиңгәсе М.Килдебәкова йогынтысында Әлфия тиз арада гобеленнар эшләү ысулын үзләштерде һәм үз иҗатында форма төгәллегенә, силуэт гадилеге, декоративлык һәм буяудан буяуга күчкәндә чикләрнең йомшаклыгына ирешә. Гобеленнар эшләү — күп көч һәм вакыт сорый торган һөнәр. Әлфиягә гобелен кысалары тар тоелды, һәм ул графика жанрына күчтә. Җете буяулар — гуашь, пастель, акварель белән картиналар язу һәм литография (таштан гравюралар ясау) техникасының бөтен серләрен өйрәнде. Аның графика ысулы белән ясалган эшләренең композициясе җиңел һәм нәфис. Ул рәсемнәрне озын һәм кыска сызыклар ярдәмендә ясый («Канатлы ат» һәм «Күл буенда» шундыйлардан). Рәссамның бу эшләре оста чигү өлгесенә охшаш. Графика ысулы белән ясалмады, ә бәлки аның стилистик фикерләвенә тиң булырлык буяулар, образлар синтезына ирешә алды. Алай гына да түгел, бу — рәссамның иҗат өлгесенә әйләнде, дисәк тә ялгышмабыз. Әлфиянең картиналарын, аның образлар системасын, язу ысулын





ган картиналарда табигать гүзәллеге, андагы тынлык, тыныч күктә очкан кошлар, суда йөзгән үрдәкләр — болар барысы да борынгы Шәрык мәдәниятенә, ерак тамырларга барып тоташа.

Моннан өч ел элек яшь рәссам Ходай биргән сәләтен сынлы сәнгатьтә сынап карарга ният итте, һәм аның иҗат җимешләре башкалабыз сәнгать сөючеләре өчен зур вакыйга буларак кабул ителде. Әлфиянең акварельләрендә хатын-кызның нечкә тойгылары чагыла. Хатын-кыз рәссам — бездәнең халыкта сирәк күренеш, талантлысы — бигрәк тә! Әлфия Ильясова сынлы сәнгатьтә Шәрык темасын тирәнтен өйрәнеп кенә касәнгать сөючеләр инде танып өлгерделәр.

. Әлфия Ильясова XIX гасыр азагы, XX гасыр башы Көнбатыш сынлы сәнгать традицияләре белән дә таныш. Аның иҗатында импрессионистик алым да ачык шәйләнә, бик күп башка рәссамнардан да ул үзенә иҗаты өчен азык таба. Балаларча садә язу алымында яшь рәссамның борынгы архаик сәнгатькә мөрәҗәгать итүен тоябыз. Ә нәфис, нәзакәтле буяулар синтезы исә тамашачыны үткән чорлардан бүгенгә тормышыбызга алып керә.

Әлфиянең кешеләрне сурәтләве дә үзенчәлекле: ул кешенең башын һәм гәүдәсен фас белән язса, аякларын профильдә тә. Образ схематизмга кор Бу — очраклы түгел, әлбәт сам гади, примитив фо аша тирән рухи образ сурә омтыла һәм, әйтергә кирәк образлары тамашачыны бі калдырмый.

Кеше — галәм күзәнәге, бигатьтән аерылгысыз, шуны ассызыклап әйтергә ша. Аның картиналарында та чак кына төсмерләнә. ның яраткан төп темасы Ул — Хатын-кыз һәм Җим картинада Мәрьям-ана агачы янында сурәтлән сендә исә Кол Галинең З сын күрәсең, Мөхәммәт пә рнең хатыны Гайшә бакча нең авызына агачтан өз өзелгән җимеш каптыра... тиналарда моң һәм жанны та торган әллә нинди нур (

Рәссамны Ана белән Б разы да дулкынландыра. (белән»). Хәтер тамашачы лам дөньясына алып китә сәмдә... Мәрьям-ана сабы шеләргә күрсәтергә алы Ана образын чагылдырг рьям тыныч, сабыр холы үзенең бөеклеген тоя. «I дигән полотно да үзе аннан тантаналы рух бөрк ра.

Сынлы сәнгать белән а ныш булмаган кеше дә Әл картиналарында ярылыг ихласлык, самимилекне ы тоя. Ул ихласлыкны уй рып булмый — аны кичер турыдан-туры киндергә к генә мөмкин. Бер үк ка — кеше һәм табигать, җәнлекләр. Киек җанвар аларның бергәлеге жанны мый, ул — табигый ите кылына. Алар барысы д тен табигать балалары. лык әкияте «Ак бүре»гә неп, яшь рәссам катлаул гармонияле композиция Шуңа күрә һәр сызык, һә урынында. Ак бүре бар кешелеккә терекле Табигать-Ана күзаллана.

Тәҗрибә туплаган сае буяуларының палитрасы слəргә саранлана бара төсе сүзен аз буяулар бе керергә омтыла. Безнең — «Кыскалыкта — оста гән гыйбарә бар бит. Кы күрсезлек, ихласлык һә тә, Тәңре тарафыннан талант Әлфиягә тамаш бөтен яуларга ярдәм ит

Буяулар дөньясы, му ньясы кебек үк, бөтен ха аңлашыла. Моңа Шәрык батыш мәдәниятләрене рәвештә үрелеп баруы итә. Әлфия картиналары рның милли тойгылары дөнияте телендә яңгыр мның үзенчәлекле аша тылсым белән әрт рык сулышын, аның мо шигъриятен ишетәсең.

Динә Ә

Г.Ибраһимов исем әдәбият һәм тарих

● **Рәссам Әлфия Иль «Күл буенда», «Канатл тиналары.**

«Күңелемнән ефәкләргә төрәм лә мин сезне...»

Алдымда кәгазьләре саргаеп беткән, күз яшьләренә чыланып хәрефләре җебегән йөзгә якын хат. Барысын да йөрәге аша уздырган кешегә аларны бер тында укып бетерү мөмкин түгел. Наз, мәхәббәт, сагыш, хәсрәт тулы юллардан кан саркый. Үз фаҗигасен, башкаена ишелеп төшкән афәтне онытып, ирен югалткан, балаларыннан аерылган ана нарасыйларын кайгырта, алар мәшәкате белән яши. Аның үз язмышын — үләсен дә, каласын да җәлладлар хәл итсә дә, ач-ялангач яшәсә дә, Фатыйма хатларында «минем өчен борчылмагыз, хәлем әйбәт», дип яза. Ана балаларының ни ашаганын, кайда яшәгәннәрен, нәрсә кигәннәрен белми — шуңа үрсәләнә.

Укымышлы, зыялы, эшчән Вәлиевләр гаиләсен утыз җиденче елларда тәмам котырган Сталин террорының гигант тегермәче изгән, тузан бөртегенә әйләндергән. Ничектер Бөек Җиңү турында сүз чыккач, әңгәмәдәшем, 4 нче гимназия каршындагы сәнгать мәктәбе директоры Илкәй Каюм кызы Садыйкова бик моңсуланып калды.

— 9 май безгә зур кайгы китергән көн, — диде ул. — Тик аның Бөек Җиңүгә катнашы юк. Ул көнне 1938 елны безнең әтине халык дошманы дип атканнар. Бу хакта әле алты ел элек кенә белдек.

«Вәлиев Каюм Гыйбадулла улы, туган елы — 1896. 1919 елдан партия әгъзасы. 1937 елның сентябрь аенда, Татарстан китап сәүдәсе директоры булып эшләгән чакта «социаль хәлен яшергәне, кулак әтисенә булышканы, халык дошманнары белән элемтәсе» өчен партия сафларыннан чыгарылып, ТАССР НКВДсы органнары тарафыннан кулга алына. 1938 елның 9 маенда СССР Верховный Суды Хәрби коллегиясенең күчмә сессиясе тарафыннан атарга хөкем ителә, һәм хөкем карары шул ук көнне җиренә җиткерелә.

1956 елның декабрендә Вәлиев К.Г. эше, җинаять составы булмау сәбәпле, туктатыла. 1988 елның 29 декабрендә КПСС өлкә комитеты бюросы карары нигезендә партиядә торгызылды» дигән белешмә алдык. Әтиебезнең язмышы 50 ел узгач кына ачыкланды. Иң гаҗәпкә калдырганы — «җинаять составы булмау сәбәпле, Вәлиев К.Г. эше туктатыла» дигән сүзләр булды. Үзен атып үтергәч, эшен туктатудан кемгә ни файда?! Ярый инде, йөз аклыгы өчен әтиебез өстеннән хурлык тамгасы алынды.

... Ул көннәрне әле дә хәтерлим. Әти борчылып эштән кайтты, кичтән бик елады. «Бүген партбилетымны алдылар, тиздән үземне дә алып китәрләр инде», — диде. Төнлә сискәнеп уянып киттем: әни минем аска җәелгән киезне ала икән. Йомшак, дөя йоныннан ясалган киез әти белән төрмәгә китте.

«Социаль чыгышы»на килгәндә, әти ишле гаиләдә үскән. Гыйбадулла бабай авылда тегермән тоткан, ун баланың барысы да тегермәндә эшләгән. Утызынчы елларда урта хәлле, эшчән гаиләләрне кулаклаштыру шаукымы әтиебезне дә, әниебезне дә харап итте. (Камчы очы безгә дә тиде — комсомолга алмый тинтерәттеләр). Әнине 1938 елның 13 маенда, әтине атканнан соң ук кулга алдылар һәм «халык дошманы» хатыны булган өчен 8 елга хөкем иттеләр. Без Надия апа белән урамда калдык. Әни киткәннең икенче көнендә үк мине приютка алырга килделәр. Апам җиңемә чытырдап ябышты да: «Бирмим сеңлемне, бирмим, үзем тәрбиялим мин аны», — дип тыпырдый-тыпырдый елады. Без өйдә икәү генә калдык, аннары әнинең сеңлесе Хөршидә апа үзләренә алып китте. Мине бабай, үсә төшкәч, апа тәрбияләде.

Үзе исән чагында әни: «Укыгыз, кеше булыгыз», дип хат саен яза иде. Үле хәбәре килгәч, тешем-тырнагым белән музыкага ябыштым, әни васыятен үтәргә тырыштым. Музыка училищесын тәмамладым, инде 40 ел педагоглык стажым бар. 2 нче музыка мәктәбендә генә дә 25 ел эшләдем. Ә апама, кызганыч ки, укырга туры килмәде. Ул мине укытып-тәрбияләр өчен үз-үзен аямады.

Хөрмәтле укучы! Сезгә Фатыйма Вәлиеваның төрмәдән балаларына язган берничә хатын тәкъдим итәбез.

Ст.Сегежа. 27 гыйнвар, 1941 ел.

Сөекле кызларым Надия һәм Илкәй! Бүген сездән хат алдым, тик нигәдер датасын куярга оныткансыз.

Илкәем, күз нурым! Синең почеркың хаттан-хатка яхшыра бара. Рәхмәт, кызым, әниеңне онытмаганың, сөендергәнең өчен. Киләчәктә дә хатларыңны ешрак яз, атна саен яз. Мәктәптә эшләрең ничек бара, кемнәр белән дуслашасың? Кызым, син мине гафу ит инде. Шушы көнгә кадәр сезгә дип җыйган посылканы җибәрә алганым юк. Әлегә бездән посылка җибәреп булмый, тик бу вакытлыча гына. Рөхсәт булу белән җибәрермен, ямә. Тиздән Гайшә апа янына аның туганы Хәят апа килергә тиеш, бәлки шуның артыннан җибәреп булыр. Мин сезгә 4 метр ситсы, оекпар, рейтузлар, кульяулыклар, Илкәйгә чиккән кофта әзерләп куйдым. Надия, күптән түгел синең өчен Гайшә апаның өй адресына 50 сум акча җибәрдем, туфли алганда кушып җибәрерсең. Иш янына куш булыр.

Күңелемнән ефәкләргә төрәм лә мин сезне, өрмәгән җирләргә утыртмыйм да бит, гөлкәйләрем!.. Бернәрсәгә дә мохтаҗ итмәс идем, хәлемнән килми, мөмкинлекләр чикле, сез ерак!..

Наҗиянең карточкасын алдым, сөбханалла, бәбие тупырдап тора. Кулыма алып шапылдатып сөяселәрем килде, айныгач, шыксыз камераны күреп елаплар җибәрдем. Нарасый шул яшеннән ятим калган... Мәҗит булса, кулыннан төшермәс иде. Наҗиягә сәлам әйтегез. Үзен дә, нарасыен да сакласын. Ул балаларны үстерергә ай-һай күп көч кирәк булачак әле. Гомумән, бөтен туганнарны сагындым, фотоларын җибәрсеннәр иде. Күпме сорыйм, җибәрүчеләр аз. Үзем элекке эшемдә эшлим. Монда бик каты салкыннар булды. Җылыда эшләгәч, мин алай бик сизмәдем. Итеккә олтан салдырдым, аяклар җылыда. Башка бөркәнергә генә шәл юк. Без монда күбәү, бер-беребезгә ярдәм итәбез, шәлне дә чиратлашып бәйлибез. Гайшә апа, Сара, мин — өчебез бер гаилә кебек тату яшибез. Дуслар булмаса, сезне сагынып күптән диванага сабышыр идем инде. Сезне күрмәгәнгә өч ел бит инде, өч ел!.. Бер төнгә дә калдырырга курка идем бит мин сезне, Наҗия кызым. Укуыңны ташларга туры килсә, бик кызганыч инде: икенче яртыеллыкка түләүне туганнар күтәрешмәс микән? Бәлки Рабига апа, Хөршидләр булышыр? Ел ярым укуың җилгә оча бит. Хөршид посылка җыя, дип язган идең, посылка җибәрәсе урынга уку өчен түләгез. Мин берүзем, ничек тә түзәрмен.

Туганым җиңгине бер күреп сөйләшсәм, азга гына булса да кайгысын җиңеләйтер идем.

Кызым, багалмам, тешләрегез сәламәтме? Илкәйнең тешләрен дә, үзеңнекен дә вакытында дәваларга тырыш. Надия, абыйга әйт әле, итекләрегезгә олтан салсын. Әни язган, диген. Күн табанлы яхшы фетр итекләр күпме тора? Бәяләре бик кыйммәт булмаса, Гайшә апаның сеңлесе сатып алып бирер иде.

Сау булыгыз. Сезне бик сагынып, күзләрегездән үбеп калам.

P.S. Мөкәррәмә язган бу хатны җәһәт кенә илтеп бирегез, ямә!

15 август, 1939 ел.

Надиям һәм Илкәем! Иң беренче сүзем шул: минем өчен борчылып, елап күзләрегезне бетермәгез. Мин әйбәт яшим. Сез — үсеп килүче яшь буын, яшьтәшләрегез белән бергә шаярыгыз, уйнагыз, көлегез. Авырлыкларны да яшь буын кешеләречә, коммунистларча җиңәргә өйрәнегез, без бит бөек Совет илендә яшибез. Әти-әниегез белән бергә вакыттагыча хис итегез.

Надиям, алтыным! Син, рабфакка укырга кердем, дип язган идең. Бик үтенеп сорыйм, укы, тырышып укы, кызым. Уку синең якты киләчәгеңә юл ачар. Үзеңә дуслар сайлаганда сак бул: яхшылар әйбәт юлга өндәр, начарлары тайгак юлга сөйрәр. Әле үзең генә түгел, сеңлең Илкәй дә бар бит. Син аңа әти дә, әни дә, апа да хәзер, мөстәкыйль тормыш итә башлыйсың.. Илкәйнең укуын һәрдаим күзәтеп тор, ямә, кызым. Ул музыкага йөриме, хатыңда яз. Сезгә кемнәр булыша? Илкәйнең пальтосы тузган иде, ничекләр кыш чыктыгыз? Кайда яшәдегез? Наҗиянең хәлләре ничек, бәби таптымы әле, кеме бар? Абый ничек яши? Кызым, миңа иң соңгы фотогызны җибәрегез әле, бик сагындым!.. Уку елын нинди билгеләргә тәмамладыгыз? Бабагыз кайда?

Кызым! Син инде дәү үстең, минем кара крепдешин күлмәкне үзеңә рәтләп ки. Әтиегезнең күлмәкләреннән Илкәйгә дә тектер. Туганнарга әйт әле: әгәр булдыра алсалар, миңа азык-төлек посылкасы җибәрергә ярый. Кәгазь, конверт һәм маркалар да җибәрсеннәр. Элек салган посылкагызны, хатыгызны алдым, рәхмәт яусын. Уку елын уңышлы тәмамлавы белән котлап, Илкәйгә түбәтәй чиккән идем, җае чыгу белән җибәрермен.

Хатларыгызны атна саен языгыз, менә хәзер сездән килгән хатлар гына яшәтә. Сезне уйламаган көнем, сәгатем юк, нәни кошчыкларым. Сездән башка миңа бик кыен, шулай да тиздән күрешербез, дип юанам. Күзләрегездән үбеп, кочып калучы әниегез дип белерсез.

14 май, 1942 ел.

Надиям, Илкәем! Бүген миннән бәхетлерәк берәр кеше бар микән? Илүсәдән открытка алдым һәм, Надия, синең өйгә кайтканыңны белдем. Надия, Илкәй, миңа бит өч айга бер тапкыр гына хат язарга рөхсәт бар, хат килгәнне көтеп ятмагыз, үзегез языгыз!

Ничекләр яшисез? Надия, кайда эшлисең, барысын да языгыз. Илкәй, син бишенче класска күчтеңме, кызым? Нинди билгеләр белән күчтең? Музыка мәктәбен тәмамладыңмы? Авырмыйсыңмы? Абый өйдәме, кайда эшли? Туганым-җиңги сәламәтме? Нигә миңа хат язмыйлар. Аларга, балаларына, туганнарның барчасына күп итеп сәлам әйтегез. Һәрберсенә аерым-аерым хат яза алмыйм.

Кызым, бәгърем, минем өчен борчылып ятмагыз. Пекарняда мөдир булып эшлим, берүзем бер бүлмә. Эшчеләр мондагылар, сегежанықылар.

Кызым, сезгә хат язып утырганда яныма Мөкәррәмә килеп басты менә һәм сиңа үтенеч белдерә: син аның сеңлесе янына барып, балаларының кайда икәнлеген белеш әле, ямә. Ул үзе берничә хат язды инде, бер җавап та юк. Мин сезнең өчен ничек өзгәләнсәм, ул да шулай балалары өчен яна, көя. Аның адресы минекечә. Эшли, авырмый, әйбәт кенә яши. Аның өчен борчылып ятмасыннар. Сеңлесенең адресы: Чернышевский урамы, 8 нче йорт, 13 нче фатир, Беглова-Фәйзрахманова Мөнәвәрә.

Бездә яз инде. Тирә-юнь ямь-яшел. Күке аваз сала, дала сандугачы сайрый — үзәкләрне өзә. Очып кына кайтыр идем кана... Читлек эчендәге кошлар оча да, сайрый да алмый шул.

Әти кайда эшли, аның сәламәтлеге ничек, миннән күп итеп сәлам әйтегез. Кызым, безнең фатирда хәзер кемнәр яши? Салих, Мәрьямнәрнең хәле ничек?

Гөлкәйләрем! Бу 4 ел эчендә киемнәрегез теткәләнеп беткәндер инде. Ничекләр юнәтәсез? Һич күз алдына китерә алмыйм. Мин берүзем, көҗүнни кием, көҗүнни аш, ә сез ничек көн күрәсез? Шулкадәр сагынам, шулкадәр сагынам, кайчаннар күрешербез икән?! Менә бүген 14 нче май, төп-төгәл 4 ел калды. Балаларым, минем өчен борчылмагыз, мин ничек тә түзәрмен. Сезне уйлап йөрәгем телгәләнә, эчем тулы сагыш. Үзегезне саклагыз, авырмагыз. Сезне үбеп, кочып, чәчләрегездән сыйпап, бер күрергә зар булып калучы әниегез дип белерсез. Ходай кушса, бәлки тиздән күрешербез әле!..

Тагын бер елдан Фатыйма Вәлиеваны, тырышып эшләвен искә алып, азат итәләр, әмма аңа балалары янына Казанга кайтырга рөхсәт булмый. Халык дошманы хатынына яшәү урыны итеп Фрунзе шәһәрен билгелиләр. Юлда үпкәләре шешеп, ул бер станциядә үлеп кала. Балалары әниләренең үлеме хакында ул яткан больницадан хат килгәч кенә беләләр.

Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА.

Фатыйма һәм Каюм Вәлиевләрне (сулда) дуслары Фаина һәм Борис Яндашевскийлар белән күрәсез. Тәтеш, 1925 ел.

Мәдәни җомга

Әлеге дә баягы

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ, филология фәннәре кандидаты

Татар этнонимын кемнәр таккан?

Татар халкының этнонимы буенча фәнни әдәбиятта һәм көндәлек матбугат битләрендә күпсанлы материаллар басылды. Бу проблеманың чишелеше белгечләрнең татар этник тарихына мөнәсәбәте белән бәйле.

Бүгенге көндә татар этнонимына карата , нигездә, ике караш яшәп килә.

Беренчесе: татар этнонимы турыдан-туры төрки татарлардан килә.

Икенчесе: әлеге этноним татар-монголлар белән бәйле, һәм безгә аны урыс халкы көчләп таккан, безгә бу исемнән баш тартып, «болгар» булып аталырга кирәк, дигән фикер.



Безнең дәвердә татарда гына түгел, урыста да этногенез, ягъни халыкның килеп чыгышы турындагы фәнне бер мизгеллек процесс дип аңлаучы кешеләр фәнни дәрәҗәләре югары булганнар арасында да җитәрлек. Ә инде үзләренең сәяси амбицияләрен, гәрчә квалификацияле тарихчы булмасалар да, абсолют дөрес тарихи хакыйкать дип игълан итүче галимнәр дә бар. Шулай ук дөрес этник тарих буенча эшләп килүчеләр дә юк түгел.

Мин бу мәкаләмдә хәзерге вазгыятьтә татар этногенезы буенча яшәп килгән төрле концепцияләрне тәнкыйть итү кебек файдасыз эшкә керешмичә, үзем туплаган мәгълүматларга таянып, карашымны белдерүне кирәк таптым. Мәгълүматларны түбәндәге төркемнәргә бүлеп күрсәтергә мөмкин.

I. Шәҗәрәләребез

Татар нәсел шәҗәрәләре арасында безнең нәсел «болгар» дип язылган бер генә документ та юк. Андый материалларда аерым нәселнең бабалары Болгар шәһәреннән (Аксак Тимер һөҗүме вакытында) күчеп килгән дигән хәбәрләр генә очрый. Биләр шәһәреннән чыгучы кыргыз-казак нәселләре Татар Танае тирәсенә килеп утыралар, Кырымнан, Нугай урдасыннан таралган нәселләр бар. Бу хәбәрләр XIY гасыр ахырына, ягъни Алтын Урда дәверенә карыйлар. Күченеп килгән татар-мишәр нәселләре тарихы XYI гасырдан башлана.

Бу уңайдан безгә тарихчыларыбыз игътибарыннан еш кына читтә кала торган урыс елъязмасы мәгълүматларына күз салып үтү дә кирәк булыр. Ул чыганаклар Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тарихчылары тарафыннан төзелгән хрестоматиядән алындылар. Куелган проблемага бәйле фактлар турында безнең өчен кызыклы булган XIY гасыр урыс чыганаклары Алтын Урданың Болгар олысы халкы турында ниләр язып калдырганнар соң?

1360 елда урыс кенәзләре хәзерге Чистай каласы янындагы Җүкәтау шәһәрен алганда хәлләр болайрак була: «придоша в Жукотин и множество татар побиша и богатства их взяша, и зато разбойничества христиане пограблены были в Болгарах от татар». (Источники по истории Татарстана. Казань, 1993, 8 стр.). Димәк, Җүкәтау һәм Болгар шәһәрендә 1360 елда татарлар яшәгән.

Урыс елъязмасы 1395 елда Казанда татарлар яшәгәнне күрсәтә (әлеге китапның 10 нчы бите). Монда бер урында да болгар халкы телгә алынмый, фәкать Болгар, Җүкәтау, Казан шәһәрләре кенәзләре булуы хакында сүз бара.

Идел буйларындагы татар халкына исемне урыслар такканмы, әллә алар үз исемнәре белән йөргәннәрме?

Көнбатыш Европадан килгән сәяхәтчеләр Алтын Урда халкы этнонимын, урыс теленнән алмыйча, «татар» дип санаганнар (мәсәлән, XY гасыр Венеция сәяхәтчеләре Барбаро, Контарини һ.б.).

XIY-XYI гасырларда Көнбатыш Европа белгечләре сызган карталарда Идел, Дон, Кырым җирләрендә болгар халкы күренми — фәкать Болгар шәһәре һәм татар халкы күрсәтелә.

Бу дәверләрдә Болгар шәһәре Алтын Урданың бер олыс үзәге буларак яши һәм аны Аксак Тимер 1395-1398 елларда җимергәндә чыгып китүчеләр дә татарлар була.

XYII гасырдагы Кырым ханы Җанибик Гәрәй (1610-1623, 1627-1629 елларда идарә иткән) үзенең ярлыгында дәүләтенең халкы арасында татарларны саный: «Олуг Урда — олуг йортның, вә тәхте Крыймның, вә сансыз күп татарның, вә сагыйшсыз нугайның, вә тат била таукачның, вә тагъ ара чиркәсенең олуг падишаһы...» (Х.Фаесханов. Краткая учебная грамматика татарского языка. СПБ, 1862)

Татар язучысы һәм галиме Ризаэтдин бине Фәхретдиннең Башкортстан Фәннәр академиясендә саклана торган архивының 15 нче томы, 2 нче битендә мондый бер документ бар:

«1757 сәнәдә, гыйнварның 17 сендә, Уфа әязенең, Нугай юлының Үрмәк Мәң илүнең башкорт вәкиле Әскәр Юлымбәт углы үземезнең уртак йиремез халайык арасында итагатемез берлә, татар язувы берлә биргән йиремезне, булган заманымызда...»

XYIII гасыр урыс тарихчысы Петр Рычковның «История Оренбургская (1730-1750)» исемле китабында (1896 ел) бер татар тарихы турында мондый сүзләр бар:

«В малой Татарии, то есть, близ Крыма, показал он Кадрясь из татарской истории...» (69 бит).

Башкортстан ягыннан табылган бер иске шәҗәрәдән: «... шәһәре Казандан, татар халкыннан хатын алмыштыр» (Башкирские шежере. Уфа, 1960, 78 с.)

Ә мондый чыганаклар шактый.

II. Татарның үз кулыннан чыккан документлар

XYII-XIX гасыр документларында татарның үз милләтен бернинди читтән басымсыз «татар», ә телен «татар теле» дип атау күренешләре очрый. Шулардан ике үрнәкне китереп узабыз.

№ 1

Тарих йите мең дә ике йөз өченче ел (1695 ел — М.Ә.) декабрьнең унөченче көне илән указ олуг Газыйм падишаһ хәзрәте — олуг кенәз Петр Алексеевич, барча олуг вә кечек, ак падишаһ Россия йортын үзе тоткучы, үзе биләүче, указ куәте белән Казан өязенең Рәҗәб авылы татарлары югарыда язылган җирләрне сукалау һәм печәнен чабу өчен укадиелар (угодиелар) илән биләргә олуг падишаһ хәзрәтенең бердән ясак илән тармакка; ягъни түләмәккә бу замандагы аңлатуны Казанга түләргә яздым. (Мәрҗани Шиһабетдин. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан, 1989, 203 бит).

№ 2

1994 елның июлендә археографик экспедиция вакытында Татарстанның Әтнә төбәге, Олы Мәңгәр авылында табылган кулъязмалар арасында берсе хәтердә калган. Анда 1826 елда, Кушлавыч авылында падишаһ Николай указы «татарчага күчерелде» дип гарәп хәрефләре белән язылган. Ул хәзер Казанда Татарстан Фәннәр академиясе мирасханәсендә саклана.

III. Дастаннар

Татар дастаннарында болгар этнонимы юк, ә менә татар этнонимы очрый. Мәсәлән:

1.
«Идегәй» дастаны
(Идегәй. Казан, 1988)
116 б. Сансыз татар урдасы бар,

Алтын егач тәхетем бар.
128 б. Халкы ханнан әркә инде,
Татарың белән Нугаең...
129 б. Татарның тулы йортыннан...

2.
«Чура батыр» дастаны
(Чура батыр, Казан, 1993)
59 б.Кара көндә, кыенда,
Татар атына юл бирәп,
Танавыннан кан килеп
Тырпаеп торса, күрерсез!

3.
«Таһир белән Зөһрә» дастаны.
(Кулъязма)
И татарлар, татарлар...
(Мирасханә: 80 кол. 49 эш).

4.
«Хәерниса бәете».
(Татар поэзиясе антологиясе. Казан, 1956, 34 бит).
Татар егете, рус кызы
Бер-берсен сөештеләр.

5.
«Асабай» җыры (румын татарларында).
Татар ашы пешерәп, ат суярмын асабай.

IY. Татар кулъязма календарьлары

1. Татарстанның Азнакай төбәге, Митрәй авылыннан табылган кулъязма календарь, 1786 ел. (Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты мирасханәсе, 39 кол, № 2337, 8а бит). Сәретан аеның 26 көне, 1786. Татар хисабы берлә чиллә керде.

2. Татарстанның Саба төбәге, Өтернес авылы кулъязма календаре (Мирасханә, 99 кол. 1 тасвир, № 215 эш. 1802 елны төзелгән). «Татар хисабы илә», диелгән.

Y. Сүзлекләр

1. «Төрекчә-гарәпчә ике сүзлек төзүче, Каһирәдәге «Әшрәфия» мәдрәсәсе укытучысы Салих мулла, «татар теле» дигән терминны кулланышка кертеп, «Әбү-Хәйян сүзлеге татар телен чагылдыра», — дигән фикерне әйтә. 1477 елдан әүвәл төзелгән».

Нәҗиб Ә. Татар әдәбиятының һәм әдәби теленең кайбер онытылган язма истәлекләре турында... — Совет әдәбияты, 1957, № 12, (86 б.).

2. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты мирасханәсе, 39 кол, 39 эш шифры белән XIX гасырның беренче яртыларында төзелгән ике томлык «Төрек-татар-фарсы-гарәп» телләре сүзлеге саклана.

XYIII-XIX гасыр башларында яшәгән татар галимнәре Хәлфиннәр зур күләмдә «Урысча-татарча сүзлек» төзиләр, татар теле грамматикасы язып, нәшер итәләр. Соңыннан да XIX-XX гасырлардагы барлык сүзлекләребездә татар теле турында гына сүз бара.

Үсемлек атамалары җәһәтеннән дә сүзлекләрдә кызыклы фактлар бар. Мәсәлән, диалектологик сүзлектә «татар чаганы» дигән сүз теркәлгән (Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969, 604 б.).

Касыйм якларыннан Себер кырларына (Кара диңгез буйлары, Төньяк Кавказ якларындагыларын әйткән дә юк) күпме авылларның исеме татар этнонимы кушылып ясалган: Татарбай (Касыйм районы), Татар Борнае, Татар Борнашы, Татар Булчие, Татар Димскәе, Татар Икшермәсе, Татар Танае һ.б. Башкортстан һәм Татарстанда дистәләрчә татар авылларының атамалары шуның мисалы. Бер генә урында да «Болгар Борнае», «Болгар Борнашы» кебек атамалар күренми. Бүгенге Татарстандагы Болгар, Кызыл Болгар исемле авыллар 1922 елдан соң гына оештырылдылар һәм аларның атамалары бу еллардагы тарихи әдәбият тәэсире белән генә кушылганнар. Алайга калса, Татарстанда бу елларда Чыңгыз, Сәмәрканд, Бохара, Бакчасарай исемле татар авыллары да барлыкка килде. Димәк, Болгар исемен алган бу авыллар этнонимнан түгел, Алтын Урданың олыс үзәге Болгар шәһәре исеменнән алынганнар. Кайберәүләр Болгаер исемле авыл атамасында болгар исеме күрергә теләсәләр, ләкин бу бит бары Әбелхәер исемле гарәптән кергән кеше исеменең татар теле законнарына җайлаштырылган бер төре генә.

Татар кулъязмаларында очрый торган әл-Болгари тәхәллүсе дә этнонимны аңлатмый. Ул бары тик татар авторларының җирле административ географик өлкәгә нисбәтән күрсәтүче бер чара гына. Чөнки әл-Бохари, әл-Дагыстани, әт-Төркестани, әл-Кырыми, әл-Болхи һ.б. кебек тәхәллүсләр шуның мисалы. Бу җәһәттән Муса Бигиевнең тәхәллүсе кызыклы, ул үзенең әсәрләрен чит илдә (Мисырда) Муса бине Җарулла әр-Руси, әт-Татари, әр-Растуфдуни дип авторлыгын күрсәткән. Шагыйрь Мифтахетдин Акмулланың тәхәллүсе исә әл-Башкорди. Бу тәхәллүс белән ул яшәгән урынының башкорт җирләре белән бәйле икәнлеген күрсәтә.

Тәхәллүсләрнең барысы да географик төшенчәне генә белдерә, ә этнонимны түгел.

YI. Борынгы әдәби истәлекләр

Бездә кайберәүләр, Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр үзенең әсәрендә татар этнонимына каршы булган, димәкче булалар (бу аеруча археолог А.Х.Халиков монографиясендә чагыла). Мөхәммәдьяр әсәренең эчтәлегенә кермичә, аның нинди тарихи дәвердә яшәгәнен исәпкә ал-

мыйча, үзеңнең хыялыңа фактны жигү объективлык була алмый. Шагыйрь татар ханнары Мөхәммәд Әмингә, Сафа Гәрәйгә дәүләт башлыклары итеп карый. Шул ук вакытта Казан ханлыгына дошманлык кылып йөрүче Шаһгали ханга да аның мөнәсәбәте булмаган, дип кем әйтә. Шагыйрь әсәрендә татарга мөнәсәбәт этнонимнан бигрәк, йомышлы сословиегә, ягъни Мәскәүгә хезмәт итүчеләргә карый. Мөхәммәдьяр аның исемен әйтмәсә дә, әсәрендәге гыйбрәтле хикәядә бер образны «явыз татар» итеп тасвирлый. Шунлыктан шагыйрьнең бу дорфалыгын Касыймда һәм Мәскәүдә онытмаганнар, 1549 елда Казаннан тылмач булып баргач, Мөхәммәдьярны Мәскәүдә кулга алалар. Нугай урдасы хакимнәре Иван Грозныйдан аны үзләренә бирүне сорыйлар.

Татар әдәбияты тарихында халык этнонимына кизәнгән кеше булмады. Урта гасыр татар әдәбияты ядкаре Кылыч бине Саядның «Дастаны Бабахан» әсәрендә татар ханы, татар шәһәре турында сүз бара. Таһир белән Зөһрә мәхәббәтенә багышланган бу әсәрдә Таһир — татар дип әйтелә.

Әлбәттә, урыс золымы, милли изү татар этнонимының саклanышына зыян китерде. Татар халкы Исламга тагын да ныграк береkте. Ә Ислам дине милли үзенчәлекләрне саклауны күз алдында тотмый иде. Шунлыктан «Сорау-җавап» диалогларында: «Милләтең кем?» — дию гә, татар-мөселман «Ибраһим милләтеннән», — дип җавап бирергә тиеш булды. Бу фикер тарафдарларына Татарстан радиосы журналистлары кайвакыт микрофонны да «ышаныл» тапшыралар. Мәсәлән, 1994 елның 13 июнендә иртәнге тапшыруда бәреү, шапылдатып: «Милләтем — Ибраһим милләте», дип җавап биреп торды. Димәк, бу кеше яһүди халкының вәкиле була.

YII. Яңа татар әдәбияты

XX гасырга кергәндә татарның классик әдипләре үзләрен татар милләтчеләре итеп күрсәттеләр.

Габдулла Тукай:

Җырлап торам, торган җирем
тар булса да,
Курыкмыйм сөйгән халкым
бу татар булса да...

Дәрдмәнд:

1) Урысча күп сүзең,
азы татарча,
Белалмыйм, кем син —
урысмы, татармы?
Ничектер белмәдек
исме шәрифең
Хөсәнме, юкса Иванмы,
Макармы?..

2) Татарлыкта татар углы
татармын,
Татар түгел димә —
башың ватармын.

Мәҗит Гафури:

Йә, татар! Тиз син дә уян —
Мөнкариз булмас борын...

Гаяз Исхакый, татар язмышы өчен борчылып, «Инкыйраз» әсәрен иҗат итте.

Галимҗан Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» повестен язды, һәм ул татар этнонимын ныклаган кешеләрнең берсе иде.

Фатих Әмирханның татарлыгы һәр әсәреннән күренә.

Шагыйрь Сәйфи Кудаш 1918 елда «Татар теләге» исемле шигырьләрен бастырып чыгарды. Бу шагыйрь гомере буе татарлыктан ваз кичмәде һәм шуның өчен Уфада җәбер күреп яшәде.

Инде югарыда бәян ителгәннәрдән бер нәтиҗә ясыйк.

Аерым галимнәрнең һәм аларга сукырларча иярүчеләрнең, этнонимыбыз татар түгел, аны безгә Мәскәү, урыслар көчләп такты, — дигән фикерләре бер тәнкыйтьне дә күтәрми.

Татар халкының үзе һәм урыстан гайре халыкларның калдырган документлары милләтебезнең этнонимы күп гасырлар буе үзатама булып килгәнлекне раслыйлар. Татар этнонимына каршы килеп, аны үзгәртергә йөрүчеләр милләтебезгә каршы җинаять, балаларына хыянәт кылучылар белән бер.

ОНЫТЫЛМАС ОЧРАШУЛАР

Гадел Кутуй белән бергә чаклар...

Мин Гадел Кутуй белән аның гомеренең соңгы айларында — фронтта бергә булдым. Кутуй белән аралашкан ул чаклар минем өчен, бер яктан, зур бәхет, сөенеч булса, икенче яктан, минем күңелемдә гомерем буена сызыла килгән юксыну, сагыну һәм онытылмас сагышлы мизгелләр дә. Татар халкының батыр улларыннан берсе, трибун шагыйрь, нечкә күңелле әдип, ялкынлы журналист һәм яуда батыр сугышчысы Гадел Кутуйның безнең арабыздан китүенә илле ел тулды.

Язмыш мине сугышның беренче в.. нәреннән үк фронт штабы политидарәсенең экспедициясе белән бәйләде. Экспедиция начальнигының урынбасары булдым. Бер үк вакытта политидарә мине фронт газетасы «Кызыл Армия» редакциясе каршында үзенең вәкиле итеп билгеләде.

1944 нче елның көзе. Без инде Польша җирендә. Г.К.Жуков командалык иткән 1 нче Белоруссия фронты — Берлин юнәлешендә. «Кызыл Армия» газетасы урнашкан махсус поезд Сетко станциясе янында урманда тора. Бу фронт газетасы каршында берничә телдә газеталар чыгып килде. Алар арасында үзбәк һәм казах телләрендәге газеталар да бар иде. 1944 елның язында бередә татар телендә дә газета чыгу хәл ителде. Кадрлар тупланды. «Кызыл Армия» газетасының мөхәррире булып Ярулла Ярмәкиев килде. Гариф Галиев, Кыям Хисмәтуллин — хәрби мөхәррирләр, Ибраһим Гази — тәрҗемәче, фоторепортер булып Зәкәрия Әхмәров билгеләнде. Татар газетасына тагы бер кеше килергә тиеш иде.

11 сентябрьгә карыш кичтә редакциягә Мәскәүдән Г.Кутуй килеп төште. Гариф Галиевне эзләп табып, алар икәү бергә төн үткәрәләр. Иртән ашханәдән чыгып килгәндә Гариф Галиев мине Гадел Кутуй белән таныштырды. Вакытында ялкынлы чыгышлары белән тамашачыларны дулкынландырган, В.Маяковский белән бергә Казанда шигырьләрен укыган һәм үлемсез «Тапшырылмаган хатлар»ны язган кеше белән кулга-кул бирешеп күрешү минем өчен зур вакыйга иде.

Г.Кутуй тиз арада редакциянең үз кешесе булып китте. Әдәпле, тирән белемле, яхшы мөгамәләдәге бу кешене бары да бик якын күрде. Ул ябык, басынкы һәм аңарда нинди дә булса төшенкелек чаткысы дип аңларга мөмкин булган халәтне дә тоярга мөмкин иде. «Кызыл Армия» газетасы мөхәррире Н.Потапов Кутуйны аеруча якын итте, бик тиз арада аны офицер дәрәҗәсенә күтәртте. Хәрби хәбәрче Кутуйның һөҗүм вакытларында сугышчылар белән бергә алгы сызыкта булуы турында редакциягә хәбәр килгәч, Н.Потапов аңа киләчәктә сакланыбрак йөрергә киңәш итте.

Командировкадан кайткач, Кутуй эшкә чума иде. Газеталарда аның бер-бер артлы мәкаләләре, очерклары, шигырьләре басылып торды... Кичләрендә без бергәләп чәй эчә торган булдык. Моны нигездә Гариф Галиев оештырып алып бара иде. Кутуй белән бергә булган вакытлар турында мин «Совет әдәбияты» журналында (1958, № 11), «Социалистик Татарстан»да (1963, 15 декабрь; 1975, 17 август), «Татарстан яшьләре»ндә (1983, 1 декабрь) һәм «Гадел Кутуй турында истәлекләр» (1984) китабында хатирәләремне бастырдым. Аларда аерым моментлар киңрәк сөйләнә. Шундыйлардан Кутуйның «Сагыну» нәсере һәм соңгы әсәре — «Хәнҗәр» хикәясе өстендә ничек эшләгәнлеге, фронт газеталарында төрле кушамат-тәхәллүс белән язганлыгы да әйтелә. Шунлыктан, биредә сүзне озынга сузмыйча, тик кайбер якларны гына күз алдыннан кичерәм...

Г.Кутуй 1944 елның ахыры — 1945 елның башында Лодзь воеводасы юнәлешендә барган һөҗүмнәрдә 2 нче танк армиясе составында алгы сызыкта катнаша. Шунда ул үзенә суык тидерә. Март башында гына командировкадан кайтып төшә. Редакция инде Польшаның Познань шәһәрендә стационар типографиядә урнашкан була. Татар газетасы хезмәткәрләре Петрово Жняка урамындагы 40 нчы йортның 25 нче зур бүлмәсендә яши. Март ахырларында барлык хәбәрчеләр алгы сызыкка китте. Берлинны штурмлау өчен соңгы авыр һөҗүмнәргә әзерлек бара иде. Тәрҗемәче И.Гази белән Я.Ярмәкиев кенә редакциядә калды. Кутуйны командировкага барудан врачлар тыйды. Ул моңа бик борчылды, әмма эшләвен өзлексез дәвам итте. Мин аның янына еш кына керәм, бергәләп чәй эчүләрне дәвам итәбез. Апрель урталарында Кутуйны Познань шәһәрендәге госпитальгә салдылар. 18 апрельдә редакция Одердан 30 чакрымдагы Топпер станциясе янында урнашты. 22 апрельдә мин редакция эшләре белән Познаньга очтым, андагы йомышларны бетергәч, Г.Кутуй яткан госпитальгә ашыктым. Бакча эчендәге йортның озын коридоры буйлап баргач, 7 нче палатаның ишеген ачтым. Анда ак киемнән булган берничә яралы арасында Кутуй гына буйлы халаттан, аркасын берничә мендәргә терәгән килеш башын тезләренә салып утыра иде. Без кочаклашып күрештек, башкалар тынып калды. Күзләрдән мөлдерәп чыккан яшьләр икебезнең дә бит буйлап агып төште. Хәл-әхвәлләрне сорашкач, Кутуй җанланып китте. Без бакчага чыгып, баскыч янындагы эскәмиягә утырдык, рәхәтләнеп сөйләштек.

Безнең янга берничә мәртәбә шәфкать туташы килеп китте. Мин моның сәбәбен соңыннан гына аңладым. Ул Кутуйның хәлен белергә килгән икән. Без урыннан кузгалдык. Гадельша бик хәлсез иде, үзе атлап керә алмады. Ул ике кулын минем иңбашларыма салды, мин аны биленнән алып палатага илттем. Ул тагын да мендәрләргә терәлеп, тезләрен чәнчеп утырды, без кочаклашып аерылыштык... Озын коридор буйлап баскычка чыккач, мин баскан килеш тынып калдым... Шул вакытны сөекле Тукаебызның Клячкин шифаханәсендә мендәренә сөялеп утырган рәсеме күз алдыма килеп басты... Үзәгем өзелеп китте. Яңадан Кутуй янына кердем, без тагын да кочаклашып елаштык. Бу — Гадел Кутуй белән саубуллашуның иң изге, тетрәндергеч һәм мәңге онытылмаслык соңгы мизгелләре булган икән...

Шакир АБИЛОВ,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

КИТАП КҮҢЕЛ ҮСТЕРӘ

Тарихи хәтеребез һәйкәле



Соңгы вакытларда гына Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган хезмәтләр арасында үзләренең нәфис тышлыклары белән үк күз явын ала торганнары бар. Шуларның берсе, исеме дә җисеменә туры килгәнә, «Казан ханнары»* дип атала һәм бөек галимебез Ризаэтдин бине Фәхретдин (1859-1936) каләменә бурычлы. Хезмәтне сәнгати яктан зәвыклы, кулга соралып торырдай итеп әзерләүгә аталы-уллы рәссамнар Рушан белән Рем Шәмсетдиновлар зур көч куйган. Шул ук сүзне китапка тиешле рух өрү җәһәтеннән нәшрият мөхәррире Солтан Шәмси хакында да әйтергә мөмкин. Өстәвенә, язучы-мөхәррир әлеге китапны, бигрәк тә аның искәрмәләр өлешен, «Казан — ханлык мәркәзе» дигән кызыклы гына күзәтүе белән дә тулыландырган.

Мәгълүм ки, Р.Фәхретдин үзенең әсәрләрен гарәп имлясында, шул заманның фәнни-әдәби телен гарәп, фарсы, гомумтөрки алынмалар белән баетып, чор таләбе кысаларында иҗат иткән. Әлеге китапка кергән мәкаләләрен ул үз редакциясендә Ырынбурда нәшер ителгән «Шура» («Киңәш») журналының 1908-1909 ел саннарында бастырган. Аяныч ки, шуннан бирле бу хезмәтләргә кабат дөнья күрү насыйп булмады, татар халкының берничә буыны бу искитмәле язмалардан, андагы гыйбрәтләрдән нәүмиз булып кала килде.

Шунысы да бар, классик галимебез «Шура»дагы әлеге мәкаләләрен «Мәшһүр адәмнәр вә олуг хадисәләр» (хадисә — вакыйга) дигән гомуми баш астында урнаштырган. «Казан ханнары» дигән атама исә ошбу китапны басмага әзерләүче тарафыннан шартлы рәвештә бирелгән икән.

Хезмәтне әлеге шәкелдә вөҗүдкә китерүче, төп гамәлгә куючы турында да әйтергә вакыт җиткәндер. Әйе, бу зат — гыйбрәтле тарихи язмалары белән җәмәгатьчелеккә инде шактый киң танылып өлгергән тынгысыз галимебез Равил Әмирхан. Кайбер күренекле тарихчыларның әсәрләрен ул аерым китаплар итеп әзерләп чыгарды, үзенең дә күләмле хезмәтләре төрле басмаханәләрдә әледән-әле нәшер ителеп тора.

Без сүз алып бара торган «Казан ханнары» китабын төзү, гарәп язулы текстны бүгенге алфавитка күчереп эшкәртү, хәтта ки аерым урыннарын тәрҗемә итү, искәрмә-аңлатмаларны һәм кереш мәкаләне язу да тулаем аның кулы белән эшләнгән.

Әлбәттә, әсәрне (бигрәк тә ул гасыр башына хас булса) матбугатка әзерләү механик бер гамәл түгел. Мисалы күз алдыбызда. Чөнки төзүче «Галимнәр галиме» дигән күләмле мәкаләсе белән Риза Казыйның гаҗәп киңкырлы эшчәнлегенә әтрафлы бәя биргән, һәр мәкаләдән соң урнаштырылган искәрмәләре белән Ризаэтдин Фәхретдиннең мәгълүматларын нык киңәйткән, нәтиҗәләрен тирәнәйткән, күп вакыйгаларның асылын яңа чыганаклар нигезендә аңлатуга, яктыртуга ирешкән. Бу гамәлләр үзләре генә дә Р.Әмирханның әзерлекле, эзләнүчән, киң колачлы тарихчы-галим булуына дәлил. Искәрмәләрдән күренгәнчә, Равил әфәнде Р.Фәхретдин язмаларын тирәнтен өйрәнеп, тәрҗемә кылып, эшкәртеп кенә калмаган, бәлки аларны шәрехләгәндә бихисап өстәмә әдәбияттан иҗади файдаланган. Бу яктан аеруча шунысы хуплауга лаек: Равил Әмирхан элеккә һәм бүгенге татар тарихчыларының гына түгел (Ш.Мәрҗани, Һ.Атласи, Ә.-З.Вәлиди, С.Алишев), мәсьәләгә мөмкин кадәр объектив килү йөзеннән мәшһүр урыс тарихчыларының да (П.И.Рычков, Н.М.Карамзин, К.Ф.Фукс, С.М.Соловьев, М.Г.Худяков, Н.И.Воробьев) хезмәтләренә нык таянган, дәлилләр эзләп, еш кына аларга мөрәҗәгать иткән.

Бүгенге укучыларыбыз, тарих сөючеләребез өчен самими тәстә шатланмый мөмкин түгел. Ниһаять, алар өлешенә дә гадел информация дигән көмеш тиде сыман. Әйтерең бармы, дистәләгән еллар «әйләнеш»тә булган рәсми-империячел дәреслекләрдә дөньякүләм шөһрәт казанган ханнарның гамәлләренә генә түгел, исемнәренә дә урын бирелми килде, бирелгәндә дә, эшчәнлекләренә үтә тискәре, котсыз-чирканыч мәгънә салынды. Гади укучы зиһенендә бу азамат ирләр вә бикәләр дәвере томан белән әретелгән, чынбарлыктан бөтенләй читләшкән «хан заманы» дигән ярыммифик төшенчәгә әйләнеп калган, әкияти бер төсмер алган иде. Китапны әзерләүче Равил Әмирхан һиммәте белән солтанәтле хакимнәрнең шанлы гасыры гүяки яңа, тылсымлы гәүдәләнеш таба, тарихи хәтер дигән мөкатдәс төшенчәгә якты бер нур иңә. Һәрбер ханны, әйтерсең ле, тотып-капшап карау, эш-фигыльләрен гаделлек бизмәненә салып үлчәү мөмкинлеге туа.

Китап белән танышып чыгу шундыйрак фикергә дә этәрми калмый. Мондый төр язмаларны басмага әзерләгәндә төзүченең үз гомани булуы ачыклана. Равил әфәнденең инануынча, татар халкының үткәнен мөмкин кадәр ачык күзаллау, тикшерү, тасвир кылу һәм аңа үлчәмле бәя бирү өчен әүвәл классик дәрәҗәдәге тарихчыларыбызның әсәрләрен тәфсилләп өйрәнү, шуннан соң гына «ачылган Америка»ны ачарга азапланмыйча, яңа сүз әйтү юлын тоту шарт икән.

Инде бер моментка аерым басым ясап үтик. Соңгы елларда Татарстан китап нәшрияты электән килгән игелекле традицияләренә яңа сулыш бирде, заман таләбен сизгер тоемлавын раслап, тарихи продукциягә йөз белән борылды. Ул гына да түгел, тарихи проблемалар «казанында кайнаган» авторларга илтифатын торган саен арттыра, шуның белән аларга иҗади канат үстерүгә, рухи егәрләре артуга булышлык итә.

Кыскасы, укучыларыбызны ихлас сөендергән, җәмәгатьчелек йөрәгенә туры юл тапкан, гыйбрәтле тарихи мирасыбызны пропагандалаган игелекле традиция уңышлы дәвам итсен. Тарихи хәтер бездән шуны таләп итә.

Рәсим КАДЕРМӘТИ.

* **Ризаэтдин Фәхретдин. «Казан ханнары». Татарстан китап нәшрияты, 1995, 181 бит.**

Агымсу агар, үз юлын табар...



Соңгы елларда безнең әдәбиятта сатира-юмор жанрында ныклап торып эшләүче, иҗат итүче авторларыбыз ике-өч кешедән артмады. Шигъриятта Гамил Афзал булса, прозада Фәнзаман Баттал иде.

Берничә ел элек алар янына Зөлфәт Хәким исеме дә өстәлде. Ул үзенең көчле сатирик икәнлеген инде газета-журнал битләрендә басылып чыккан әсәрләре белән раслаган иде. Аның әлеге жанрны сайлавы, бу жанрда иҗат итүе үзе бер тәвәккәллек, кыюлык, минемчә. Чыннан да, зур осталыкны, талантлылыкны таләп иткән бу жанрда Зөлфәт Хәким үз юлын, үз стилен, үз укучысын тапты.

Ул кыска-кыска хикәяләр белән генә чикләнеп калмады, татар укучысы инде күптән күрмәгән зур күләмле сатирик әсәрләр дә язды.

Зөлфәт Хәким исеме вакытлы матбугат битләрендә күптән күренсә дә, театрларда әсәрләре куелып, тамашачының уңай бәясенә лаек булса да, аның әлегә кадәр саллы, матур китабы басылып чыкканы юк иде. Һәм менә, Аллаһыга шөкер, сатирик роман һәм повестьлар кергән ул китап дөнья күрде.*

Әсәрләрдә сүз бүгенге көн проблемалары, әхлак, экология, кеше һәм табигать, кешеләр арасындагы тирән психологик кичерешләр турында бара. Һәм, әлбәттә инде, алар барысы да авторның үзенә генә хас булган үткен сатира-юмор, кызыклы чагыштырулар белән бергә үрелеп бирелә. Беренче җөмләләрдән үк, укучыны әсәрендәге вакыйгаларга бөтереп алып кереп китә Зөлфәт. Ул үз укучысын да, шул минутта ук, әсәрдә катнашучы геройларның берсенә әверелдерә. Бу аның иң уңышлы якларыннан берседер, мөгаен. Әсәрләрне авторның образ һәм портретларны, күренешләрне никадәр оста бирүенә сокланып, елмаеп, башны селкеп, тел шартлатып сөенеп укыйсың.

Әкиятләребездә булган персонажларны, элементларны кушып яки булмаса нигез итеп алып, аларны тормышыбыздагы чынбарлык белән бергә бәйли белү, чыннан да, зур осталык сорыйдыр. Һәм шулар аша безнең бүгенге тормышыбыздагы пычраклыкларны, наданлыкны, комсызлыкны-хөсетлекне күрсәтә алу — Зөлфәт Хәкимнең иҗатына менә шул сыйфат хас.

Китапка кергән «Курку» повесте психологик кичерешләргә корылган. Бер караганда безгә гадәти генә булып тоелган күренешләрне, тормыштагы вакыйгаларны автор фәлсәфи яктан ачып бирә. Ул кешеләрдәге курку дигән төшенчә-халәтне фәлсәфи категория итеп кабул итә дә, аның төп асылын ачарга омтыла. Укучы бу повестьны укыганда, әйткәнебезчә, үзенә күптән таныш булган нәрсәләрнең фәлсәфәсен күрә, танып ала. Билгеле инде, автор ярдәмендә таный. Минемчә, әлеге повесть Зөлфәт Хәкимнең сатирик автор гына булып калмыйча, бәлки тирән фикерле философ икәнлеген дә раслый.

Соңгы сүз итеп, әлеге китапка — озын гомер, авторга иҗади уңышлар теләп, яңадан-яңа әсәрләрен көтеп калыйк.

Илдар ХӨСӘНОВ,
Татарстан китап нәшрияты мөхәррире.

* **Зөлфәт Хәким. «Агымсуда ни булмас». Татарстан китап нәшрияты, 1995, 246 бит.**

Төрек солтаны кайда яшәгән?

Юлъязмалар һәм сәяхәтнамәләр татар әдәбиятына элек-электән хас сыйфат. Бу үзенчәлекле жанрның күп гасырлык тарихы бар. Габдерәхим Утыз-Имәни, Шиһабетдин Мәрҗәни, Заһир Бигиев, Фатих Кәрими исемнәрен хәтердә яңартсак, әдәбиятка килгән Миргазыян Юныс, Мөхәммәт Мәһдиев, Тәүфыйк Әйди кебек әдипләребез иҗатында да сәяхәтнамә рәвешендә язылган матур-сөйкемле әсәрләребез барын күрербез. Әле күптән түгел генә «КАМАЗ» китап нәшриятында Ирек Диндаровның да «Төркиягә сәяхәт»* исемле китабы дөнья күрде.

Бу китап ике өлештән тора. Беренчесендә китапка исем биргән юлъязма урын алган булса, икенчесенә исә авторның хикәя, нәсер, парчалары тупланган.

Сәяхәтнамәләрне, гадәттә, укучы яратып укый. Чөнки бу жанрга тынгысыз күңелле, иренмәс җаннар гына мөрәҗәгать итә; икенчедән, андый әсәрләр укучыга бик күп кызыклы мәгълүмат, хәбәрдарлык, белем алып килә, аңа яңа дөньяларны ача.

Сәяхәтнамәләр чынбарлыкны тулы чагылдырулары белән әһәмиятле. Язмалардагы күтәренке, романтик рух та бик табигый кабул ителә. Гомергә аяк басмаган, хыялларда гына яшәгән тарафларга барып чык та, күтәренке хисләрдән азат бул ди! Ирек Диндаров, бу җәһәттән дә, язма әдәбиятыбыздагы сәяхәтнамәләр рухына хилафлык китерми. Әсәр җыйнак кына новеллалардан тора.

И.Диндаров төрек кардәшләребез иленә «Төрек дөньясы» президенты Туран Язган чакыруы буенча сәфәр чыккан. Автор Татарстан белән Төркия арасындагы бәйләнешләрнең моңарчы зәгыйфь булып килгәнлеген искәртә, бу хәлнең төп сәбәпләрен ачып салырга омтыла. Инде моңа сәбәпче булган системаның җимерелүенә дә шактый еллар үтеп бара, әмма төрек-татар багланышлары хакында төпле хезмәтне күргән юк. «Соңгы елларда Төркиядә йөреп кайткан Казан журналистлары да, язучылары да истә калырлык әсәрләр тудырмадылар», — дип уфтана автор. (Монда авторны «төзәтеп» китсәк тә урынлы булыр. Соңгы вакытларда бу өлкәдә язучы Тәүфыйк Әйдинең эшчәнлегенә күз йомсак, хаклы булмас иде). И.Диндаров, беренче чиратта, булдыра алганча, Төркиягә кагылышлы «ак тап»ларны бетерүгә үзеннән өлеш кертергә омтыла.

Төркия — бай тарихлы ил. Әлегә бай тарихны ниндирәк дәрәҗәдә белебез икән? Автор, шуны истә тотып, безнең өчен бик бай тарихи мәгълүматлар китерә. Алар кызыклы да, мавыктыргыч та. Шанлы төрек кардәшләребез өчен үзеннән-үзе горурланып куясың. Менә бит, дөньяда бердәнбер мөстәкыйль төрки дәүләт булып та яши беләләр, тарихларын да саклап кала алганнар. Автор, үзе дә сизмәстән, мәгърифәтчелек эшенә бирелеп китә. Бу — китапның телгә алырлык хасияте, авторның уңышы дип бәяләнергә хаклы.

Инде бүгенге көннәргә килсәк, автор күзәтүенчә, Төркия — Рәсәйдән килгән «кырыктартмачылар»ның иң яраткан иле. Мал арзан, өйрәнгән кешегә ара да ул кадәр ерак түгел. Бар да кайт, кәтүмкәңне асып. «Әле кайчандыр Рәсәй газеталары надан, караңгы, артта калган ил», дип хурланган Төркиягә бүген, хаҗга баргандай, меңләгән «кырыктартмачы» агыла, йөге-йөге белән мал ташый. Үз илендә кешечә яшәр өчен мөмкинлек булмагач, читкә китми ни хәл итәсең? Бу мескенлектән кайчан котылырбыз — анысын бер Аллаһ кына белә», — дип яза автор. Хәер, Рәсәй ягыннан сәүдәгәрләр генә агылмый икән Эгей яры буена. Сары чәчле фахишәләр дә үз иткән куе кара мыеклы төрек егетләрен. Бусы мөселман дөньясына килешми дә, тик ни хәл итәсең, нәфес фәрештәләрне дә аздырыр, ди бит.

Төркиягә барып та, андагы татар авылын күрми китү гөнаһ булыр иде. Сәяхәтнамә дә, әсәр буларак, күп нәрсә югалтыр иде. Сәяхәтчеләребезне, бәхетләренә, татарлар яши торган Гөрсу авылына алып барганнар. «Нинди син татар авылы?.. Әмма, гаҗәпкә каршы, җомга көн булуга карамастан, урамда җан әсәре күренмәде. Хәтта авылларының аерылгысыз җан иярәре — сизгер этләр дә әллә кая китеп югалганнар, каз каңгылдаган авазлар да ишетелми. Тирә-якны сөер тынлык баскан иде». Бу юлларны укыгач, тыннар кысылып куя. Сүз бит моннан йөз еллар элек безнең яклардан, гаҗәеп бай табигатьле, яшел җәйле, ак буранлы кышларны калдырып киткән, Төркия мәмләкәтендә таулы-ташлы, сазламыклы җирләргә килеп урнашкан татар мөһаҗирләре хакында бара. Авыл җан саклый, әмма яшьләр шәһәр ягын карый, тәрекләшә баралар. Кая барсаң да кара сакалың артыңнан калмый, диләр бит. Төрекләр безнең дин кардәшләребез дә, әмма аларның дин тотуында, безнең күзлектән караганда, кайбер «авышлыклар» да бар икән. Әйтик, Гөрсу мәчетендә җомга намазы укып чыккач, мәхәллә ирләре, мулла белән бергәләшеп сөйләшә-сөйләшә, тәмәке тартып-«сигара эчеп» кәефләнәләр. Тәмәке тартучы мулла анда гадәти күренеш. Юк, безнең бабайлар моңа кул куймаслар иде.

Китапның икенче бүлегендә Ирек Диндаров нәсер остасы буларак ачыла. Нәсерләр үтә дә лирик тел белән язылганнар, шигъри, тирән хисле булулары белән аерылып торалар. Бигрәк тә «Туйбикә чишмәсе», «Уяну», «Изге ай», «Азатлык турында баллада» дип исемләнгән нәсерләрдә кичерешләр табигый һәм шул ук вакытта катлаулы да. Аларны укыгач, әдәбият ишегән язу куәсе ташып торган авторның шакуын күреп куанасың.

Фаил ӨМӨК.

* **Ирек Диндаров. «Төркиягә сәяхәт». Чаллы, «КАМАЗ» нәшрияты, 1995 ел, 144 бит.**

Атналык манзара TV

Дүшәмбе

14 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00--8.00 «Чулпан» информацион программасы. 17.30 Мультфильм. 17.40 Балалар өчен фильм: «В тридевятом царстве». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.40 «Түгәрәк өстәл». Реформалар программасы: ул нинди булыр? 20.20 «Әлли-бәлли-бәү». 20.35 «Тулган ай» яктысында. Азнакай районының «Авангард» акционерлык җәмгыяте рәисе Рудис Сәлахов. 21.05 «Кичке уеннар». Татарстан Дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры. 21.35 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильмнар: «Королева красоты», «Люблю петь». 7.30, 19.00 — «КиноМеню». 8.00,21.10 — «Эфирда — музыка». 8.20 Сериал: «Соседи» (Австралия). 6 нчы серия. 8.40 «100 градус». 9.10 Нәфис фильм: «Каникулы Кроша». 1 нче серия. 10.25 «Эшмәкәрлек — санннарда». 11.00 Спутникпы телевидение. 17.00 Документаль фильм: «Режиссер Иосиф Хейфиц». 17.45 «Мәскәү темасына вариацияләр». 17.55 «Сергей Есенин. Катнашу». 18.50 Мультфильм: «Жирафа и очки». 19.30 «Видеомода». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 22.50 — «Шәһәр». Информацион программа. 20.45 «Телеэкспресс». 21.25 Пьер Ришар һәм Жерар Депардье «Папаши» кинокомедиясендә. 23.15 «Red Wave тәкъдим итә»: Пинк Флойд.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.45 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал «Тропиканка». 10.10 «Могҗизалар кыры». 11.00 «Кеше һәм закон». 11.30 Мультфильм: «Охотник». 11.35 Чечен балалары. 12.20 Эфирда — «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.30 Телесериал: «Жизнь Клима Самгина».14.05 Мультсериал: «КОАПП». 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 15.45 Авторалли: Париж—Мәскәү—Пекин. 16.00 Мультсериал: «Отверженные». 16.25 «Йолдызлар сәгате». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.30 «Рэп». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Пик сәгате». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Әгәр...» В.Познер алып бара. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.45 Реклама. 21.50 Тапшырулар программасы. 21.55 Өлег Ефремов һәм Людмила Зайцева «Здравствуй и прощай» фильмында 23.35 «Спортның җиде көне». Футбол. 0.15 «Вакыйга».

«РОССИЯ»

7.30 Эшлекле кешеләр вакыты. 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25, 16.00 — Тапшырулар программасы. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 Юбиляр фильмотекасыннан. О.Табаков «Красавец мужчина» фильмында. 10.55 Телегазета. 11.05 Милиция хроникасы. 11.45 Мариинск театры «йолдызлары» концерты. 11.45 Ура, каникуллар! Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.15, 17.20 — «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — Көндезге мәгълүмат-анализ бирү программасы. «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 Мульти-пульти. «Малышок и черная маска». 17.50 Документаль фильм: «Жил-был великий писатель». 18.05 Сезнең партнер. «Россиянең тимер юллары». 18.20 «Алыргамы — алмаскамы». 18.30 «露Коткару-911». 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Дүшәмбе саен детектив. Нәфис фильм: «Последний враг» (Бөекбритания). 1 нче кисәк. 21.40 Репортер. 22.00 «Бизәүсез». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Төнге сериал. Нәфис фильм: «Сент-Экзюпери. Последнее задание» (Франция). 1 нче серия.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.40 Такмаклар. 11.15 «Коллекционерлар». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.15 В.Виноградов фильмнары. «В.Высоцкий. Песни-монологи». 13.30 Штраус музыкасына фильм-балет: «Дон Жуан». 13.50, 15.55 — «Музыка мизгеле». 13.55 Тапшырулар тартмасы. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Кино йорты. Мэрилл Стрип, Никита Михалков, Артур Хиллер һәм башкалар. 15.30, 19.30, 22.40 — «ТВ мәгълүматлары». 15.40 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.55 Телеэкранда детектив Нәфис фильм: «Алый рассвет». 17.35 Тарихи альманах. 18.10 «Мәхәббәт җырлары». Мария Кодряну җырлый. 18 40 «Буй-буйлы музыка. Ауринко — солнышко». 19.00, 23.05 — Тапшырулар программасы. 19.05 «Телеблиц». 19.10 Балалар өчен кыска метражлы телефильм: «Пожар во флигеле». 19.48 Спорт яңалыклары. 19.55, 21.30 — О.Ерышев фильмы: «Лидия Русланова». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 21.00 Иминлек телехезмәте. 21.10 Шәһәр эшләре. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Яшел яктылык астында. 23.30 Музыкаль шоу. «Парадлар парады».

Сишәмбе

15 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.50 Мультфи. ьмнар. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Бер таңнан икенчесенә чаклы». Авылның бер көне. 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «Тукталыш». 20.25 Күп серияле нәфис фильм: «Тарзан» (Канада, Мексика, Франция). 4 нче һәм 5 нче серияләр. 21.15 Мансур Шиһаповның иҗат кичәсе. 22.15 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!». 7.10 Мультфильмнар: «Лиса Патрикеевна», «А у вас есть замки». 7.30, 20.20, 23.10 — «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 Телеэкспресс (14 август тапшыруын кабатлау). 8.20 Сериал: «Соседи». 7 нче серия. 8.40 «100 градус». 9.15 Нәфис фильм: «Каникулы Кроша». 2 нче серия. 10.20 «Кино яңалыклары». 10.45 Спутникпы телевидение. 17.00 Нәфис фильм: «Джентльмены удачи». 18.25 Документаль фильм: «Юлия Солнцева». 19.20 «Көрән аю яры». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.40 «Спортревю». 20.55 «Телеэкспресс». 21.05 «Коммерция әйләнмәсе». 21.40 Нәфис фильм премьерасы: «Грехи» (АКШ). 1 нче серия. 23.35 «Red Wave тәкъдим итә»: Элис Купер.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.30 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Әгәр». В.Познер. 10.50 Көлкеле манзара. Е.Петросян алып бара. 11.35 «Ел әйләнәсендә — яшелчә бакчасы». 12.20 Эфирда — «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.30 Телесериал: «Жизнь Клима Самгина». 7 нче серия. 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 «Кара, тыңла». 16.20 «Тутый кош артыннан». 16.40 Марафон-15. 17.00 «Кыска яңалыклар». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Джем». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18 20 Телесериал: «Тропиканка». 19 10 «Пик сәгате». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы нәниләр». 21.50 Тапшырулар программасы 21.55 Хәтердә калган фильмнар. «Небесный тихоход» (Ленфильм). 23.20 «Беренче куллардан». 23.30 «Ялта—Мәскәү—транзит-95» эстрада җырлары. Яшь башкаручыларының X Халыкара телевизион конкурсы 1 нче тур. 1.20 Авторалли: Париж-Мәскәү-Пекин.

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00 20.00 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25, 16.00 — Тапшырулар программасы. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8 35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк кирәк ..» 10 55 «Телегазета». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 Лариса Дмитриева башкаруында романслар. 11.45 Ура, каникуллар! Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.15 17 20 — «Яңа тармак». 12.30, 14 20 — Көндезге мәгълүмат-анализлау программасы. «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Өмет стартлары». 16.45 «Ай тотучы». 17.50 Карарга ашыгыгыз! Нәфис фильм: «Бегство с Юпитера». 9 нче серия 18 15 Әдәби-публицистик цикл: «Россия. Мәхәббәттә аңлашу». 15 нче фильм. 18.45 «Сәүдә йорты». «Ле Монти». 19.00 «Беркем дә онытылмаган». 19.10 «Л» клубы. 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телеэкран премьерасы Нәфис фильм: «Мечты на задворках» (АКШ . 22 25 Хәтерем театры. Ю.Визбор. В.Смехов программасы. 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел». 23.40 «ЭКС». Криминаль хәбәрләр экраны. 23.50 Төнге сериал. Нәфис фильм: «Сент-Экзюпери. Последнее задание» (Франция). 2 нче серия.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8 15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 10.00 «Төш юрау». 10.48 «Кумирлар». 11.15 «Аукцион». 12 10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны». 13 15 Яшел яктылык астында. 13.35 Телефильм: «Петровский портрет». 13.50, 15.50, 19.00 — «Музыка мизгеле». 13.55, 18.55, 23.05 — Тапшырулар программасы. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 «Изге утраулар». 15.15 Юрий Гуляев җырлый. 15.30, 19.30, 22.40 — «ТВ — мәгълүматлары». 15.40 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.55 Нәфис фильм: «Мерседес» (Франция). 17.40 Ирина Богачева җырлый. 18.10 «Бөтен Россия буйлап». 18.35 «Әкият арты әкият». «Розабелла и тролль». 1 нче кисәк. 19.05 «Телеблиц». 19.10 Нәфис фильм: «Человек слова». 19.45 Спорт яңалыклары. 19.55 Виктор Цой истәлегенә. Концерт. 20.45 «Иминлек телехезмәте». 21.00 Юмористик программа: «Телисеңме? Кара...» 21.40 Кино йорты. Джина Лолобриджида, Максимилиан Шелл, Булат Акуджава һәм башкалар...» 21.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Телеэкранда детектив: «Три ненастных дня».

Чәршәмбе

16 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 17.55 Балалар өчен фильм: «Сказка о купеческой дочери и таинственном цветке». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Архитектурага сәяхәтләр». Казан бизәкләре. 20.05 «Әлли-бәлли-бәү». 20.15 «Очрашулар». Язучы Әмирхан Еники. 20.50 «Яшьлек эзләре». Яр Чаллы эстрада группасы концерты. 21.25 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильмнар: «Говорят о погоде», «Кошачий котовник». 7.30, 20.20, 0.30 — «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 Телеэкспресс (15 август тапшыруын кабатлау). 8.20 Сериал: «Соседи». 8 нче серия. 8.45 «100 градус». 9.15 «Грация». 9.55 Нәфис фильм: «Каникулы Кроша». 3 нче серия.11.10 Спутникпы телевидение. 17.00 «Юрий Соломин. Югалтылганнар аша узу». 18.00 «Без мәзәк кешеләр идек». 1-нче, 2 нче кисәк. 19.25 «Поза». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 Телеэкспресс. 21.05 «Enter club». 21.35 «Свои люди». 22.10 Нәфис фильм: «Грехи». 2 нче һәм 3 нче серияләр.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.15 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Тема». 10.50 «Хайваннар дөньясында». 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Жизнь Клима Самгина». 14.00 Мультсериал: «КОАПП». 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 15.45 Авторалли: «Париж -Мәскәү—Пекин». 16.00 Күңелле нота-лар. 16.20 «Ник һәм нигә?» 16.50 «Фэн-клуб». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Тип-тоник». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Пик сәгате». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 Җәмәгать телевидениесендә суперспорт. Махсус чыгарылыш 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Футбол Европа чемпионатының сайлап алу матчы. Финляндия- Россия. 23.50 «Ялта—Мәскәү транзит-95» яшь эстрада җырларын башкаручыларның X Халыкара телевизион конкурсы. 2 нче тур.

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25, 16.00 — Тапшырулар программасы. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк.» 8.55 «XX гасыр кадрда һәм кадр артында». Луис Бунюэль. 9.40 «Төп мизгел». 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 Санкт-Петербург балеты «Сиреневый сад». 11.40 Телегазета. 11.45 Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.15, 17.20 — «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — Көндезге мәгълүмат-анализлау программасы «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Кем ягы?» 17.50 Нәфис фильм: «Бегство с Юпитера» (Австралия). 10 нчы серия. 18.20 «Беркем дә онытылмаган». 18.25 «Карьера». 18.55 «Видеошигърият». В.Маяковский. 19.05 Халява партиясе. 19.25 «Үз уены». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 Михаил Боярский доминосы. 22.05 Губернаторлар клубы. 22.45 Киноафиша. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «Тулган ай».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Такмаклар». 11.15 «Аукцион». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «ТВ — мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.15 «Ауринко-кояш». 13.35 Балалар өчен нәфис фильм: «Пожар во флигеле». 13.50, 15.50, 19.00 — «Музыка мизгеле». 13.55, 18.55, 23.05 — Тапшырулар программасы. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 О.Бородина катнашында телефильм: «Здравствуй, Ольга! Хэлло, Ольга!» 15.30, 19.30, 22.40 — «ТВ мәгълүматлары». 15.40 Бакчачыларга киңәшләр. 15.55 Нәфис фильм: «Три ненастных дня». 17.50 Тарихи альманах. 18.30 «Әкият артыннан әкият». «Розабелла и тролль». 19.05 «Телеблиц». 19.10 Телефильм: «Кузьма Петров-Водкин». 19.48 Спорт яңалыклары. 19.55 «Ретро». А.П.Чехов. Нәфис телефильм: «На большой дороге». 21.05 Иминлек телехезмәте 21.15 Хәтердәге җырлар. 21.30 «Блеф-клуб». 22.05 Мариинск балеты бүген һәм иртәгә. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 «Гыйбадәтханә». 23.40 Нәфис телефильм: «Жермена и Бенжамен» (Франция).

Пәнҗешәмбе

17 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00--8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.00 «Чулпан йолдыз калыкканда». Чулпан Әхмәтҗанова. 18.20 «Профсоюзлар: үзгәрү вакыты». 18.50 «ГАИ» мәгълүматлары. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Хөкүмәт сәгате». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «Яшел камин янында». ТР Дәүләт Советы Рәисе В.Н.Лихачев. 21.35 «Арча егетләре» ансамбле җырлый. 22.00 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильмнар: «Утенок Даффи и яйцеголовый», «Благоухающий котик». 7.30, 20.20, 23.00 — «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 Телеэкспресс (16 август тапшыруын кабатлау). 8.20 Телесериал: «Соседи». 9 нчы серия. 8.40 Тележурнал: «01». 9.10 Нәфис фильм: «Каникулы Кроша». 4 нче серия. 10.20 «Иске әйберләр турында яңалыклар». 10.45 Спутникпы телевидение. 17.00 Нәфис фильм: «Птицы» (Һиндстан). 1 нче серия. 18.00 Мультфильмнар: «Сказка о двух кисках», «У меня нет шляпы». 18.15 «Видеогид». 18.35 Телесериал: «Саломея». 19.30 «Проскар — коткаручы». 19.40 «Кыюлар һәм матурлар». 20.10 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә. 20.45 «Телеэкспресс». 21.05 «Коммерция әйләнмәсе». 21.30 Нәфис фильм: «Грехи». 4 нче серия. 23.25 «Red Wave» тәкъдим итә: China Black.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.35 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 Эдвард Радзинский. «Театраль роман». 10.50 «Сәяхәтчеләр клубы». 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Жизнь Клима Самгина». 14.05 Мультсериал: «КОАПП». 3 нче фильм. 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 «Мультитроллия». 16.20 «Золушкада кунакта». 16.40 Компьютер-холл. 17.00 «Бик кыска яңалыклар». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята». 17.30 «... 16 яшькәчә һәм өлкәнрәкләр өчен тапшыру». 18..00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Пик сәгате». 19.35 «Лотто-миллион». 20.05 «Югалганны эзләгәндә». Ц Леандр. Г.Скороходов алып бара. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.45 Реклама. 21.50 Тапшырулар программасы. 21.55 «Кино гасыры». «Сидящий одесную» (Италия). 0.00 «Мәскәү-Кремль». 0.20 Париж — Мәскәү — Пекин авторалли.

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.20 Реклама. 8.25 Тапшырулар программасы. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 Антреприза «Яшьләр театрына 15 яшь». 9.40 «Төп мизгел». 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 «Телегазета». 11.20 Документаль фильм: «Братья Третьяковы». 11.40 Ура, каникуллар! Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.10 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.00 Тапшырулар программасы. 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Төрле төстәге призма». 17.20 Яңа тармак. «Яхшылык эшлә». 17.50 Клип-антракт. Л.Черникова. 17.55 Карарга ашыгыгыз! Нәфис фильм: «Бегство с Юпитера». 11 нче серия. 18.20 «Минем сугыш». К.Смирнов. 18.50 «Эксповидео». 19.05 «Алты сутый». 19.25 «Барлык кешеләр өчен музыка. 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Үз үзеңә режиссер». 22.05 «Тикшерүләр бюросы». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 Хроно. Авто һәм мотоспорт дөньясында. 0.15 «ЭКС». Криминаль хәбәрләр экраны.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 10.15 «Төш юрау». 11.15 «Аукцион». 11.45 «Тәҗрибә». 12.15 «Спартак». 12.40 «Кунак». 13.00 «ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.15 Балалар өчен нәфис телефильм: «Человек слова». 13.35 Телефильм: «Кузьма Петров-Водкин». 13.50, 15.50 — «Музыка мизгеле». 13.55, 19.00, 23.05 — Тапшырулар программасы. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Кино йорты: театр һәм кино йолдызы Сергей Маковецкий. 15.30, 19.30, 22.40 — «ТВ мәгълүматлары». 15.40 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.55 «Көз» киноканалы. Нәфис фильм: «Демидовы». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 18.30 «Бөтен Россия буйлап». 18.40 «Буй-буй музыка». 19.10 «Ул безнең йөрәкләрне саклар». 19.48 Спорт яңалыклары. 19.55 «Яңгыр». Иван Бунин хикәяләре буенча телеспектакль. Режиссер В.Латышев. 20.55 Иминлек телехезмәте. 21.05 Ура, комедия! Нәфис фильм: «Миллион в брачной корзине». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Наобум: журналист Андрей Константинов. 23.35 Нәфис фильм: «Жермена и Бенжамен». 10 нчы серия.

ҖОМГА

18 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.50 Мультфильм. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Видеоспорт». 19.45 «Урак өсте». 20.05 «Әлли-бәлли-бәү». 20.20 «Ислам чакыруы». 20.30 «Җомга көн кич белән». Альманах. 21.10 Әлфирә Тимершина җырлый. 21.25 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильмнар: «Дикий заяц», «Большой ух». 7.30, 20.20, 22.30 — «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 «Телеэкспресс». (17 август тапшыруын кабатлау). 8.20 Сериал: «Соседи». 10 нчы серия. 8.45 Документаль фильм: «Пушкин и Пущин». 1 нче һәм 2 нче кисәкләр. 9.55 «Палитра»: Пуссен. Елның дүрт фасылы. 10.25 Таврия турында хатирәләр. 10.50 «Спутникль телевидение». 16.15 Балаларга фильм: «Рыжий, честный, влюбленный». 17.30 Нәфис фильм: «Птицы». 2 нче серия. 18.50 Телесериал: «Саломея». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 Телеэкспресс. 21.05 «Суперспорт». 21.25 Сериал: «Сирены» (АКШ). 22.55 Ричард Гир һәм Джоди Фостер «Соммерсби» нәфис фильмында.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.20 - - Яңалыклар. 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Югалганны эзләгәндә». Ц.Леанд. Г.Скороходов алып бара. 10.50 «Иртәнге йолдыз». 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда - - дәүләтара «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Жизнь Клима Самгина». 10 нчы серия. 14.05 Мультсериал: «КОАПП». 4 нче фильм. 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 15.45 Автоparалли: «Париж - - Мәскәү — Пекин». 16.00 Балалар өчен телесериал: «Белый клык». 16.25 «Орфей йолдызлыгы». 16.35 «Яңа чынбарлык». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 «Рок-дәрес». 18.00, 21.00 - - «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Кыргый кыр». 19.25 «Кеше һәм закон». 19.55 «Могҗизалар кыры». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 Тапшырулар программасы. 21.55 Телесериал: «Бангкок Хилтон». 4 нче серия. 22.50 «Караш». 23.45 «Ялта - - Мәскәү — транзит-95» яшь эстрада җырларын башкаручыларның X Халыкара телевизион конкурсы. 3 нче тур.

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 - - «Хәбәрләр». 8.25 Тапшырулар программасы. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Үтә яшерен». 9.45 «Телегазета». 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 «Музыкаль экспромт». 11.30 «Ле Монти» сәүдә йорты. 11.45 Ура, каникуллар! Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.00 Тапшырулар программасы. 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Көнгерә». 16.50 «Ай тотучы». 17.20 Яңа тармак. «Чиксезлекне эзләгәндә». 17.50 Җомга саен Дисней. Нәфис фильм: «Зорро». 13 нче һәм 14 нче серияләр. 18.45 «Популяр булмаган тема». 19.00 «Кайнар уңлык». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 Су спорты төрләре. Европа чемпионаты. Венадан тапшыру. 22.05 «К-2» күрсәтә: «Поцелуй в диафрагму». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 Төнге сеанс. Нәфис фильм: «Чужое лицо» (Япония).

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 «Балалар өчен». 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.38 «Кумирлар». 10.45 Такмаклар. 11.15 «Коллекционерлар». 11.45 «Тәҗрибә». 12.10 Джаз. 12.40 «Кунак». 13.00 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.15 «Ул безнең йөрәкләрне саклар». 13.35 Телефильм: «Статуи над городом». 13.50, 15.50 — «Музыка мизгеле». 13.55 Тапшырулар программасы. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 «Гласом моим...» Композитор Д.Бортнянский иҗаты турында телефильм. 15.30, 19.30, 22.40 — ТВ мәгълүматлары. 15.40 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.55 Ура, комедия! Нәфис фильм: «Миллион в брачной корзине». 17.30 ТВ мәгълүматлары — Европа калейдоскопы. 18.00, 19.00 — Музыка мизгеле. 18.05 «Бәллүр ачкыч». Музыкаль клиплар фестивале. 18.25 Документаль фильм: «Южная Африка: природа в наследство». 18.35 Балалар телевидениесе. «Антре». Цирк программасы. 18.55 Тапшырулар программасы. 19.05 Теleблиц. 19.10 Телефильм: «Созвучие». 19.48 Спорт яңалыклары. 19.55 Ретро. Нәфис фильм: «Театральные истории». 20.45 Иминлек телехезмәте. 21.00 Фильмоскоп. Нәфис фильм: «Эскадрон». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Чит ил киносы антологиясе. Нәфис фильм: «Агентство Квин и компания».

ШИМБӘ

19 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «Татарстан». 19.30 Телефильм: «Чудесные башмачки». 19.40 «Мизгел». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «Алтын көшел». Авыл эшчәннәре өчен тапшыру. 20.50 Киноның 50 еллыгына. Нәфис фильм: «Ностальгия». 22.50 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.15, 10.40 Эфирда - - музыка. 7.30 «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 Телеэкспресс (18 август тапшыруын кабатлау). Узган атна тапшырулары. 8.10 «Коммерция әйләнмәсе» (18 август көнендәге тапшыруны кабатлау). 8.35 «Видеомода». 8.55 «Поза». 9.25 «700 нче клуб». «Җаваплар». 9.55 «Үз кешеләр». 10.30 «Спорт-ревю». 10.50 Нәфис фильм: «Вечера на хуторе близ Диканьки». 11.55 «Дениска-Денис». 12.25 Дөнья киносы классигы: «Кабинет доктора Калигари» (Германия). 13.35 Фильм-концерт: «Жванецкий Карнеги Холлда». 14.50 Балаларга фильм: «Рыжий, честный, влюбленный». 2 нче серия. 16.05 Телесериал: «Тропическая жара». 17.00 Телесериал: «Детективы на полставки». 18.00 «Барысын да белергә телим». 18.10 Мультфильм: «Пес в сапогах». 18.30 «Битлек-шоу». Көрәш кырында җиңел. 19.00 «Исәнмесез!». 21.00 «Мавыгулар дөньясы». 21.30 Сериал: «Сирены» (АКШ). 22.25 Нәфис фильм: «К-9» («Собачья работа»).

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 8.45 «Пастырь сүзе». Митрополит Кирилл. 9.00, 15.00, 0.35 - - Яңалыклар. 9.20 «Лего-го». 9.50 Балаларга фильм: «Секреты моего лета». 10.35 «Иртәнге почта». 11.00 «Татлы». 11.15 «Сәламәтлек». «Үзеңә-үзең булыш». 11.50 «Авыл сәгате». 12.20 «Бомонд». 12.40 «Актерлар һәм язмышлар». Л.Смирнова «Женитьба Бальзаминова» нәфис фильмында. 14.25 «Көзге». 15.20 «Зур узышлар». 15.40 «Алтын кадр». Ираклий Андроников. 16.25 «Хайваннар дөньясында». 17.05 «Бәхетле очрак». 18.00, 21.00 - - «Вакыт». 18.20 Мультфильм: «Мотылек». 18.30 Екатеринбургтан тапшыру: «Циркны һәркем ярата». 19.00 Нәфис фильм: «Начало». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 Тапшырулар программасы. 21.55 Телесериал: «Бангкок Хилтон» (Австралия). 5 нче серия. 22.45 «Ялта - - Мәскәү-Транзит-95» яшь эстрада җырларын башкаручыларның X Халыкара телевизион конкурсы. 0.15 Автоparалли: Париж-Мәскәү-Пекин.

«РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.20 Тапшырулар программасы. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Шөреп»тән башлап. 8.45 «Онытылган көн». 9.00 «Шәп авыл». «Урыс хатын-кызы». 9.30 «Пилигрим». 10.15 Кипрас Мажейка. «Янәшәләр». 10.30 «Ватандашлар» (Памир). 11.15 «Оттырылган җиңү». 11.30 Нәфис фильм: «Москва слезам не верит». 14.20 «Де факто». 14.35 Нәфис фильм: «Мегрэ путешествует». 15.25 «Клип-антракт». Юлиан. 15.30 «Тайна животных» телесериалыннан документаль фильм: «Мир высоких гор» (Бөекбритания). 16.25 «Алтын шпор». 16.55 Футбол. Россия чемпионаты. «Динамо» (М) — «Торпедо» (М). «Динамо» стадионыннан трансляция. 18.55 «Аншлаг һәм Ко». 20.25 Су спорты. Европа чемпионаты. Венадан тапшыру. 21.25 Телеэкран премьерасы. «Игра по-крупному». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «А» программасы. 0.40 «Төнге сөйләшү». 0.45 Өлкәннәр өчен мультфильм: «Декамерон».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.30 «Христос — бөтен дөньяда». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан — туры». 10.00 И.Бунин хикәяләре буенча телеспектакль: «Дождь». 10.55 Телефильм: «Созвучие». 11.10, 18.05, 22.55 — Тапшырулар программасы. 11.15 Нәфис фильм: «Принц и нищий». 12.30 «Минем музыка». И.Шведова. 13.00 «Теледоктор». 13.30 Пушкин заманындагы балетлар. 14.30 «Көз» киноканалы. Нәфис фильм: «Сильва». 16.00 Объектив. «Минем канатлы Россиям», «Һаман югарыга һәм югарыга». 16.50 Балалар фольклор коллективлары чыгышы. 17.35 «Балаларга җәнлекләр турында». 18.10 Телефильм: «Загадка пирамид» (Франция). 19.05 «Теleблиц». 19.10 Экспресс-кино. 19.30, 22.40 — ТВ мәгълүматлары. 19.50 Г.Ибсен. Телеспектакль: «Привидения». 21.35 «Оранж-ТВ». «Теләмәсәң карама» телеканалы тәкъдим итә: «Исемсез; Шартлаткыч». 22.20 Теле-граф. 23.00 Телеэкранда детектив: «Мафия бессмертна!» 0.30 «Алкышлап!». В.Малежик.

ЯКШӘМБЕ

20 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «ТОП» (атналык телекүзәтү). 19.35 «Автокалейдоскоп». 19.50 «Программа-2». 20.05 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 20.15 «Әлли-бәлли-бәү». 20.25 М.Маликова. «Оҗмах балалары». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле. 22.15 «Җәйге бакчада». Эстрада концерты. 22.50 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

8.00, 12.05, 16.45 — Эфирда - - музыка. 8.10 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау). Узган атна тапшырулары. 10.00 Коммерция әйләнмәсе (17 август тапшыруын кабатлау). 10.25 «Видеогид». 10.45 «Мавыгулар дөньясы». 11.15 «Суперспорт». 11.35 «Enter club». 12.15 Нәфис фильм: «Вий». 13.30 Мультфильм: «Оттого, что в кузнеце не было гвоздя». 13.40 Дөнья киносы классикасы. «Тетка Чарлея» (АКШ). 15.00 Музыкаль программа: «Лайма Вайкуле». 15.35 «Эшмәкәрлек - - сафарда». 16.05 «Сезнең адвокат». 16.15 Red Wave тәкъдим итә. 17.00 Телесериал: «Тропическая жара». 18.00 «Табигать серләре». 18.15 Телесериал: «Детективы на полставки». 19.15 «Битлек-шоу». «Пикникта». 19.45 «КиноМеню». 20.15 «Җирле вакыт». Информацион программа. 20.45 Нәфис фильм: «Звуки музыки». 23.40 «Исәнмесез!» (19 август тапшыруын кабатлау).

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 9.00, 15.00, 0.25 - Яңалыклар. 9.20 «Иртә таңнан». 9.50 Мультфильмнар: «Как гусенок на лису охотился», «Таинственная пропажа». 10.10 «Бар да өйдә чакта». 10.40 «Бәллүр башмак». 11.30 «Россиягә хезмәт итәм». «Полигон». 12.00 Тележурнал: «Бөтендөнья географиясе». 12.50 «Бөтен Россия». «Исәнмесез». 13.15 «Салават күпере», халык иҗаты турындагы телепрограммаларның X Халыкара фестивале. «Фолк-метр» (Сербия). 13.45 «50 ел элек бу көннәрдә». 14.00 «Ап-ачык, акылга сыймаслык». 14.40 Автоparалли: Париж-Мәскәү-Пекин. 15.20 «Мариинскида променад». 16.10 «Сәяхәтчеләр клубы». 17.05 «Европага тәрәзә». Д.Кисилев алып бара. 17.35 Мультсериал: «Приключения капитана Врунгеля». 18.00 «Вакыт». 18.20 «Күзгә-күз». А.Любимов алып бара. 18.40 Бокс. Майк Тайсонның кайтуы. 20.00 Сильвестр Сталлоне «Взаперти» триллерында (АКШ, 1989 ел). 22.55 Тапшырулар программасы. 23.00 Телесериал: «Бангкок Хилтон». 6 нчы серия. 23.50 «Бер күрүдә ярату».

«РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 - - Хәбәрләр. 8.20 Тапшырулар программасы. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Беренче дубль». 8.45 «Алтын ачкыч». 9.00 Мульти-пульти: «Песочные часы». 9.10 «Футболга чикләр юк». 10.55 «Хәерле иртә, Европа». 10.25 «Аты, баты...» 10.55 «Консолидация». 11.00 «Рус лотосы». 11.45 «Тапшырулар тартмасы». 12.00 Россиянең телевизион театры. Э.Томпсон. «Алтын күлдә». 14.20 «Кисеп бетерә алмаслык». 14.35 Нәфис фильм: «Мегрэ путешествует». 15.25 «Беренче нөсхә». 15.35 Әдәби-публицистик программа: «Веди». 16.05 «На-Настальгия». 18.00 Диснейның тылсымлы дөньясы. «Русалочка», «Новые приключения Винни Пуха». 18.55 «Джентльмен-шоу». 19.25 «Ксюшада кунакта». 20.25 Су спорты. Европа чемпионаты. Венадан тапшыру. 21.20, 23.40 - - Нәфис фильм: «Игра по-крупному» (АКШ). 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 1.15 Төнге дилижанс.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.05 «Бу сезнең көнегез». 7.30 «Шифалы сүз». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан - - туры». 10.00 Телеканалда детектив: «Мафия бессмертна». 11.30, 18.50, 21.50 - Тапшырулар программасы. 11.35 Телефильм: «Два капитана». 12.00 «Якшәмбе лабиринты». 13.10 В.Виноградов фильмнары: «Площадь декабристов». 13.45 «5 канал телепрограммалары анонсы». 14.00 Никитиннар катнашында телефильм: «Времена не выбирают». 14.30 Классика-5. Балет «Красная шапочка». 15.30 «Депутатларга сүз бирәбез». 16.00 Ю.Нагибин хикәясе буенча әдәби композиция: «Заступница». 17.25 Россиянең һава флоты көненә карата. 18.00, 19.00 - - Футбол. Россия чемпионаты. «Зенит» (СПБ) - - «Дружба» (Майкоп). 1 нче һәм 2 нче таймнар. 18.45 «Паутиныч яшәгән җирдә». 18.55 «Музыка мизгеле». 19.45 «ТВ мәгълүматлары». 20.05 «Зур зал турында хатирәләр». И.Андроников сөйли. 21.30 «Ретро». «Песняры» белән 20 минут». 21.55 Безнең кино. Нәфис фильм: «Вива, Кастро». 23.40 Рок риваятьләре: Боб Марли.

ДҮШӘМБЕ, 14 АВГУСТ

6.00, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 Иртәнге дулкында. 6.45, 20.45 — Татарча өйрәнәбез. 6.50, 7.58, 20.53 - Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.00 Информацион-музыкаль программа. 7.45, 20.53 — Тапшырулар программасы. 8.00, 18.30, 21.00 - - Радио-1. 17.45 «Уйныйбыз да, җырлыйбыз да». 19.45 Һәвәскәр башкаручылар концерты.

СИШӘМБЕ, 15 АВГУСТ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.30 - Һава торышы. 6.55, 7.50 --- Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.30 - Тапшырулар программасы. 8.00, 14.30, 18.30, 21.45 - Радио-1. 12.25 14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Башкортстан артистлары концерты. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Юллар чатында» информацион программасы. 13.45 «Турылап-туры элемтә». 17.45 «Яшьлек» студиясе. 19.45 Композитор Р.Яхин әсәрләре. 20.35 Баулы районы хезмәтчәннәренә багышланган информацион-музыкаль программа.

ЧӘРШӘМБЕ, 16 АВГУСТ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Татарстан дулкынында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.53 - - Һава торышы. 6.55, 7.50 -- Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.53 - Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 21.00 Радио-1. 12.25 13.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Концерт. «Без Татарстан җирендә яшибез». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Кеше һәм закон». 19.45 Сораулар буенча концерт.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 17 АВГУСТ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 - Һава торышы. 6.55, 7.50 - Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 20.45 Радио-1. 12.25 14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 «Балалар җырлый». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 19.45 Татар композиторларының камера музыкасы.

ҖОМГА, 18 АВГУСТ

6.00 «Балкыш». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 --- Һава торышы. 6.55, 7.50 - - Белдерүләр. 7.00, 13.05, 19.15 - - «Соңгы хәбәрләр». 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 - - Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 20.45 Радио-1. 12.25 13.30 - «Көн үзәге» информацион нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Ш.Маннанов һәм Н.Хисамов шигырьләренә язылган җырлар. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Чишмәләр» (чуваш теленда). 19.45 «Музыкаль очрашулар».

ШИМБӘ, 19 АВГУСТ

6.00, 7.00 - Соңгы хәбәрләр. 6.15 Авыл эшчәннәре өчен концерт. 6.58, 7.58, 14.30 - - Һава торышы. 7.15 Иртәнге концерт. 7.45, 14.30 -- Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00, 11.00, 14.35 - - Радио-1. 8.15 «Мәсьәләгә бер карашь». 8.30 «Көмеш кыңгырау». 9.00 «Әдәби укулар». Г.Исхакый. «Локман Мудрый». 9.30 Х.Әюп шигырьләре. Укый И.Әхмәтҗан. 10.10 Ә.Еники. «Бала». Радиопостановка. 10.30 «Тапышу». 11.45 «Карләшлеккә чикләр юк». 12.15 Татар халык көйләре. 13.10 Яңалыклар эстафетасы. 13.30 «Яшьлек» студиясе. 14.00 «Сезнең хакта һәм сезнең өчен».

ЯКШӘМБЕ, 20 АВГУСТ

7.00, 7.58, 13.40 -- Һава торышы. 7.0[illegible] «Хәерле иртә!» 7.45, 13.40 -- Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.0[illegible] «Идел белән Урал арасында». Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы. 9.00 «Табигать дуслары». 9.30 «С[illegible] веренитет: нәтиҗәләр, хәл ителмәгән мәсьәләләр». Түгәрәк өстәл артында әңгәмә. 11.45 Зеленодольск музыка мәктәбе укучылары уйный. 12.15 «Тел күрке - сүз». 12.45 Ял концерты. 13.45 «Татарстан дулкынында». 14.15 Ә.Рәшит[illegible] «Әни». Радиопостановка. 15.40 Радио-1.



Горький музеенда — татар әдипләре

Казанда бөек урыс язучысы Максим Горький музеенда татар әдипләре иҗатына, аларның тормышына, эшчәнлегенә зур урын бирелүе тамаша кылучыларны һич тә гаҗәпләндерми торгандыр. Чөнки бу дуслык, бердәмлек, татулык мөнәсәбәтләре татар һәм урыс язучылары арасында күп еллар элек салынган. Дуслык үскән, ныгыган һәм тарих битләренә керәп калырлык мираска әверелгән.

Бер төн эчендә М.Горькийның «Давыл хәбәрчесе»н тәрҗемә иткән һәм язучының Казанга килүенә бүләк әзерләгән Гадел Кутуй истәлекләренә, шәхси әйберләренә музейда урын түрдән булу әлеге дуслыкка, иҗади хезмәттәшлеккә күркәм мисал. Г.Кутуйның «Хәнҗәр» кулъязмасы, рәсми язулары, бүләкләре, фотосурәтләре музейны баетып, тулыландырып тора.

Кави Нәҗми, Хәсән Туфан, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Галимҗан Ибраһимов һәм башка әдипләребезнең истәлекләре, әсәрләре, Татар дәүләт академия театрының Горький әсәрләрен сәхнәләштерүе һәм репертуарында еллар буена саклавы күп еллык багланышлар хакында сөйли. Татар тамашачысы 30 нчы елларда ук урыс классигы әсәрләрен үз телендә тыңлау, карау бәхетенә ирешкән. Татар әдипләре осталыгы белән тәрҗемә ителгән әсәрләр укучының дөньяви карашын киңәйткән. Горькийның «Ана» романы, «Әрмә», «Тормыш төбендә» һәм башка әсәрләре кичекмәстән татар укучысына җиткерелгән. Чөнки татар язучылары М.Горькийны үзләренең якташ остазы итеп санаган. Язучы үзе дә татар халкын яраткан, хөрмәт иткән һәм әсәрләрендә истә калырлык образлар тудырган. Казан шәһәренә карата ул чын мәхәббәтен белдергән. Шушы сыйфатлар урыс язучысы һәм татар әдипләре арасында интернациональ дуслыкны ныгыткан, халыкларның бер-берсенә хөрмәтен үстергән.

Музей директоры Әлфия Тутаева сөйли:

— Хәзерге вакытта Татарстан белән Россия арасындагы хезмәттәшлек, имин мөнәсәбәтләр, мөгаен, күп еллар элек әнә шул бөек шәхесләр — Максим Горькийлар, Федор Шаляпиннар, Гадел Кутуйлар, Хәсән Туфаннар тарафыннан салынгандыр. Тарихны үзгәртеп язу мөмкин түгел. Калабызда андый кешеләрнең булуы, яшәве белән бары тик горурланырга кирәк.

Римда Федор Шаляпинның улы Федор Федорович белән очрашу өчен миңа татарча итеп: «Исәнмесез, мин Казаннан, татар, мөселман кызы булам», — дип әйтү дә җитте. Ул уналты ел буена Казанда гомер кичергән әтисенең якташлары турында җылы хатирәләр сөйләде, татар халкына олы хөрмәт белән каравы хакында әйтте. Миңа әлеге сүзләрне тыңлау, ишетү халкым өчен горурлану хисе тудырды.

Музейның уналты залында Горький язмышы аша туган як тормышы, гореф-гадәтләр, милли сыйфат, үзенчәлекләр, Казан — бирედә яшәгән шәхесләр иҗаты, татар һәм урыс әдәбияты дөньясы ачыла.

Илле биш елдан бирле музей яңадан-яңа күргәзмә әйберләр белән тулылана бара. Бу эшләрнә башкаруда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Флора Мирзина, Венера Дәүләтшина зур өлеш кертә. Алар егерме биш ел буе шушы музейда эшлиләр, эзләнәләр, табалар һәм аларны залларның берсенә урнаштыргач, музейга килүчеләрдән сөенеч алалар. Музей караучысы Полина Козлованың хезмәт юлы баштан ахырга кадәр Горький музее белән бәйләнгән. Ул 1951 елдан бирле тарихи мирас белән эшли, һәр әйбернең табылу тарихын белә һәм рәхәтләнеп сөйләп бирә.

М.Горький музее эшчәнлеге үткәннәр белән генә чикләнеп калмый, бүгенге дөнья сулышын да үз эченә ала. Һәм һәр мөмкинлекне кулдан ычкындырмаска тырыша. Ф.Шаляпин җәмгыяте ярдәме белән музейда Горькийның оныклары Пешковалар, Федор Шаляпинның оныгы Ирина Борисовна Шаляпина, шулай ук Казанда үткәрелә торган Шаляпин фестивалендә катнашучылар белән очрашулар уздырылган. Бирედә музыка яңгырый, истәлекләр яңартыла. Музей директоры Әлфия Тутаеваның Римга баруы да изге максаттан — Федор Федорович Шаляпинны Казанга кунакка чакыру ниятеннән була. Ул Татарстанга кайтырга, очрашырга вәгъдә итсә дә, күрешүләр насыйп булмый, Федор Федорович бер елдан соң дөнья куя.

Бөек урыс язучысы Максим Горький музеендагы җәүһәрләр безнең үткән тарихыбызны чагылдырып тора һәм киләчәктә дә татар һәм урыс халкының дустанә яшәвенә булышлык итәр.

Сәрмәдия СӨЛӘЙМАН.

● **Татар әдипләренә багышланган күргәзмә залындагы экспонатлар. Музей караучысы Полина Козлова.**



Гимназия нигезенә үлән үскән...

3 нче гимназия Казандагы 10 нчы мәктәп бинасының почмагында 5 ел инде өйдәш булып гомер кичерә. Аңа бина кирәклеге бәхәссез. Ата-аналар, җәмәгатьчелек вәкилләре төрле оешмаларга йөри торгач, ниһаять, боз кузгалды. 1994 елның гыйнвар-апрель айларында мин үзем генә дә республика, шәһәр, район оешмалары җитәкчеләреннән уннан артык җавап алдым. Алар, гимназия бинасы 1994 елның IY кварталында салына башлап, 1995—96 нчы уку елына ишекләре ачылачак, дип җавап бирделәр.

Шушы елның февралендә чыннан да гимназия бинасына нигез салу тантанасы булды. Анда Татарстан мәгариф министры В.Гайфуллин, Казан шәһәре мэры К.Исхаков, Идел буе районы җитәкчеләре катнашты. Ш.Мәрҗани мәчетенең баш имам хатибы фатиха биргәндә болай диде: «Татар гимназияләрен ачу мәчетләр төзүгә караганда да мөһимрәк. Чөнки мәчеткә юл ясле-бакчалардан, мәктәпләрдән башлана. Гыйлем гыйбадәткә караганда да артыграк, дигән пәйгамбәрләребез. Сабыйларыбыз күңеленә сабак белән бе- рге милли тәрбия дә салырга кирәк». Бу сүзләр җитәкчеләрнең дә күңелләрен кузгатырга тиеш иде кебек. Балаларыбыз алдагы уку елын яңа бинада каршылар, дигән җылы өмет белән таралды халык. Бу бинада гарәп, инглиз, төрек, урыс телен өйрәтү өчен махсус лингафон бүлмәләре, ике спорт залы һәм бассейн булачак, дип ышандырдылар җитәкчеләр. Әлеге тантанадан соң ярты ел узды. Гимназия нигезенә сугылган субайлар арасында хәзер үлән үсеп утыра. Төзелеш объектында бер генә дә җан иясе юк, дип әйтер идем дә, бер әбинең дару үләннәре җыеп йөргәнен күрдем. Мин аннан авыр уйлар белән кайтып киттем.

Безнең әтиләр бүрәнәләрне җилкәгә күтәреп ташып, ашау такы-токы заманда да бер ай эчендә мәктәп бинасын өлгерттеләр. Җәй көне төзүчеләр эшләмәде, бәлки кышын ашык-пошык өярләр. Әгәр аңа чират җитсә, тик өмет аз. Ә Горки төбәгендәге гимназия укучылары тилмереп үз биналары булуын көтәләр.

Хәбибрахман ҺАДИЕВ.
Казан.

«Концертыгыз өчен рәхмәт»

Төньяк Казагыстан өлкәсендә татар халкының күркәм бәйрәме — Сабан туе булып үтте. Анда җөмһүриятебезнең халык уен кораллары оркестры да катнашты. Шул уңайдан өлкәнең хакимият башлыгы В.Гартман Татарстан мәдәният министрына рәхмәт хаты җибәргән. Анда болай диелә: «Төньяк Казагыстанда яшәүчеләр исеменнән халык уен кораллары оркестрына, аның җитәкчесе Харис Нигъмәтҗановка, Татарстанның халык артисты Римма Ибраһимовага, «Татар җыры-93» фестивале лауреаты Рөстәм Закировка, Петропавел шәһәрендә уздырылган Сабан туенда катнашучыларга сөенеч-куаныч алып килгәннәре, осталыклары өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәбез. Бәйрәмдә катнашкан татарлар һәм башкортлар туган телләрендә яңгыраган җырларны тыңлап киенделәр, милли йола-гадәтләрнең бай булуын һәм яшәвен күреп шатландылар. Концерт программасы башка милләт кешеләренең дә мәхәббәтен яулады, милләтләрне үзара бәйләүче җеп булып әверелде.

Төбәкләребез арасындагы бердәмлек, дуслык, рухи аралашу һәм мәдәни багланышлар тагын да ныгыр һәм киңәер, яңа биеклекләргә күтәрелер, дип ышанабыз».

Гали ГАБДРАХМАНОВ,
республика халык иҗаты һәм мәдәни агарту эше буенча үзәк директоры.

ЙӨРӘКТӘН-ЙӨРӘККӘ

Бәрәкалла, «Сорнай»!

Сәнгать осталарына сүзегез булса, «Мәдени җомга» мөнбәренә рәхим итегез, дигән сүзләрегез күңелгә хуш килде. Бу мөмкинлектән файдаланып, әйтәсе сүземне җиткерим әле. «Дәвер озын, гомер аз», — дигән борынгылар. Яхшы сүзнең кадере — вакытында әйтелүдә. Ә сүзем «Сорнай» ансамбле турында. Аларны тамаша кылып, җырларын тыңлаганнан соң бер башка үсеп киткәндәй буласың.

Нәрсәсе белән шулай күңелне, җанны иркәли соң бу «Сорнай»? Менә шуны ачыклыйсы килә. Мөгаен, хикмәт җырның сүзләрендәдер:

Бер алманы бишкә бүләек,
Беребез өчен беребез үләек...

Заман сулышына бик туры килә торган сүзләр болар. Бер-беренә терәк була белгән, туганлык-кардәшлекне тирән аңлаган кешеләр өчен генә табылган, йөрәктән сызылып чыккан сүзләр бу.

Дикъкатьне аерата җәлеп иткәне — йөрәк сүзен саз телендә өздереп әйтүләредер. Бу сазга, бу сазны чиерткән кулларга җаным фида булсын, диясе килә. Кайчандыр бабаларыбыз дәртен аңлатырга яраган, әмма кулларыннан тартып алынган саздан чыгамы бу илаһи авазлар, әллә безнең күкрәктәнме?

«Сорнай» кызларына буйда, сында, Сәхипҗамаллыкта тиңнәр юктыр. Аларның кигән киемнәре дә үзенчә: изүләр каерып ачылмаган, итәк-җиңнәр кирәгеннән артык кыскармаган. Моңлы саз, моңлы йөз, затлы-зыялы киемнәр. Аларны тыңлау гына аз, — үз күзең белән күрергә кирәк! Алай дисәң, «Әнә шул сүзең» дигән җырларын радиодан яңгыраттылар. Әмма эфирда да әлеге моң, мәгънәле сүз, зыялылык — могҗиза булып кала. «Бәрәкалла, «Сорнай!» диясе килә.

Ә теләкләргә, тәкъдимгә килгәндә... Иншалла, «Сорнай» башкаруында халкыбызның «Баламишкин», «Алтын-көмеш» көйләрен дә (җыр түгел, көен!) ишетербез дигән өметтә калам. Бернинди гармунда да бу көйне дөрес итеп, бөтен нечкәлекләре белән уйнап булмыйдыр.

Бу — «Сорнай» кулыннан гына килә торган эштер!

Бәхетләр, уңышлар, озын гомерләр насыйп әйләсен «Сорнай»ыбызга!

Г.ТУКТАРОВ.
Биектау районы,
Биектау авылы.

ТАШ ЕЛАТЫРЛЫК СҮЗ

СОЦИАЛИЗМНЫҢ КАЙТУЫН КӨТӘЛӘРМЕ?

Сез бу рәсемдә күргән игълан Казанның йөрәгендә — Куйбышев мәйданы белән янәшә, 5, 12 нче трамвайларның соңгы тукталышындагы бинага куелган. Казанга, татарның башкаласына бу кадәр дә наданлык каян килә соң? Шәһәр мәгариф идарәсе, район мәгариф бүлеге хезмәткәрләренең бу эшче яшьләр мәктәбенә әллә аяк та басканнары юкмы? Йә булмаса, татарчалары шуның кадәр генәме? Җәмәгать, болай булмый бит, оятыны гына да ни тора?! Орфографик хата өстенә сәяси ялгышлык маңгаеңны тишәрлек. Татарстан исеменнән «Совет социалистик» дигән сүзләрне алып атканга биш былтыр бит инде. Әллә бу мәктәп җитәкчелеге социалистик җәмгыятьнең кире әйләнеп кайтуын көтәме? Мәктәп директоры Борис Яхонтов бу турыда ни уйлый икән?

АРЫСЛАН ЙОЛДЫЗЛЫГЫ АСТЫНДА ТУГАННАР

КОТЛЫЙБЫЗ!

11 август

БЕСПАЛОВ Виктор Иванович — кинорежиссер, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты.

ГАЛЯВИНСКИЙ Юрий Алексеевич — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының опера солисты, Татарстанның атказанган артисты.

14 август

БАТЫРКАЕВА Луиза Миңнегали кызы (Луиза Батыр-Болгари) — композитор.

15 август

БАБИН Михаил Викторович — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры оркестры артисты.

МИНГАЛИМОВ Рөстәм Гали улы (Рөстәм Мингалим) — шагыйрь һәм драматург, Татарстан Язучылар берлегенең әдәби киңәшчесе.

ФӘТТАХОВ Мәүҗет Нәҗип улы — Минзәлә Татар драма театры артисты.

16 август

МАЛИКОВ Әдип Малик улы — шагыйрь һәм прозаик.

17 август

ФЕДОТОВ Юрий Степанович — В.Качалов исемендәге Рус зур драма театры актеры, Татарстанның халык артисты.

АЛЕКСАНДРОВА Наталия Алексеевна — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының балет солисты.

КРОССВОРД

Барлык сүзләр дә «Т» хәрефеннән башлана



Горизонталь буенча: 4. Югославиянең сәяси һәм хөкүмәт эшлеклесе. 6. Татлы ашамлык. 8. Ат чабышларында отыш уены. 10. Нинди дә булса бертигез хәрәкәтнең һәрбер өлеше. 11. Мәшһүр сәясәтче, гражданнар сугышы елларында Кызыл Армиянең һәм илнең оборонасын оештыручыларның берсе. 12. Җәтмәдә яки кармак төбендәге батыргыч. 13. Олы кыз кардәш, апа. 15. Кыздырып-майлап пешергәндә кулланыла торган, агач сапка утыртылган тимер каптыргычлы җайланма. 16. Казандагы завод. 18. Безнең якларда киң таралган яфраклы агачның зур булып үсә торган төре, өянке. 19. Гадәттә бию көйләренә башкарыла торган кыска җыр, куплет. 20. Көньяк Уралда, Башкортстанда һәм Татарстанның көнчыгыш районнарында яши торган этнографик төркем. 21. Тәрҗемәче. 22. Үз-үзеңне тота алу, ныклык, сабырлык. 24. Ак әнис. 25. Шартлаткыч матдә. 26. Оешкан куе яки каты масса. 28. Азыктамырлы үсемлек. 30. Йорт кошы. 31. Адриатик диңгез буендагы шәһәр. 34. Тиз башкарыла торган итальян халык биюе. 35. Өч тавышка яки өч инструментка көйләнгән музыкаль әсәр. 36. Кече калибрлы кораллардан атарга өйрәнү өчен махсус бина яки бүлмә. 37. Литвадагы шәһәр, туризм үзәге.

Вертикаль буенча: 1. Борын куышлыгының лайлалы ярысы ялкынсыну. 2. Артсыз диван. 3. Танылган хәрби эшлекле, Советлар Союзы Маршалы. 5. Клавишалы музыка кораллары өчен җитез уйнала торган пьеса. 6. Диңгез балыгы, треска. 7. Ризыкка яки эчемлеккә салына торган борыч, канәфер, керән кебек ачы яки хуш исле әйберләр. 9. БДБгә кергән илнең башкаласы. 10. Суднодан торып балык тоту өчен эшләнгән капчык сыман зур җәтмә. 12. Кар, ашлык кебек нәрсәләрне этеп күчерү өчен көйләнгән такта җайланма. 13. Ат җиккәндә бер очы чанага яки арбаның алгы күчәренә беркетелә торган колга. 14. Мех тиреле җәнлек. 15. Үлән арасында яши торган көрәнсу-җирән төстәге йөгерек кош. 17. Корабльнең түбәнге палубасы белән түбә арасында механизмнар урнаштыру яки йөк тутыру өчен махсус бушлык. 18. Авыл хуҗалыгы машинасы. 20. Дүрт бармак киңлегенә, ягъни 72 миллиметрга тигез үлчәү берәмлеге. 23. Җиңү, максатка ирешү куанычы. 25. Матдәнең яки җисемнең җылыну дәрәҗәсе. 27. Тукылган материя. 29. Үсемлекләрне суыктан саклап үстерү өчен җылы корылма. 30. Байкал — Амур магистрале башланган станция. 32. Сәнгатьнең бер төре. 33. Солидол маеның элекке атамасы. 34. Фильмдагы язу.

Төзүчесе Фоат ХӘСӘНОВ.
Чистай шәһәре.

Бу санда Р.МӨХӘММӘТҖАНОВ (1 нче бит), Ә.ШӘФИГУЛЛИН төшергән һәм авторларның шәхси архивыннан алынган фотолар, Р.ХӘСӘНШИН, А.ҮТӘГӘНОВ рәсемнәре файдаланылды.

Мәдәни ҖОМГА

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-06-76 — баш мөхәррир урынбасары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары;
32-66-22 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге;
32-59-22 — әдәбият бүлеге;
32-57-48 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге;
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге;
32-59-55 — халык тормышы, рухиятне яклау;
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-59-22 — рәссамнар;
32-69-36 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

Газетада басылган язмаларны, фотографияләрне файдаланганда, шулай ук өземтәләр китергәндә, «Мәдәни җомга»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен заказлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәләк ярдәмә күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
609403 МФО 285586
в Бауманском отд. ПСБ

Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 429 нчы таныклык белән теркәлде

Индекс — 54129

Редакция адресы: 420503, Казан, Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре уңаеннан 49-36-62 номерлы телефон буенча шалтыратырга

Газета редакциянең компьютер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4453